ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ  МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫН ТОРМЫШКА АШЫРУДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫНА ФӘННИ-МЕТОДИК ЯРДӘМ

КАЗАН
2015

**УДК 372. 8**
**ББК 74. 261. 4**
**Ф 32**

**Проект җитәкчеләре:**
**Р.Г. Хәмитов,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент
**Л.Ф. Салихова,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты укыту-методик эшләр буенча проректоры, педагогика фәннәре кандидаты

**Төзүчеләр:**
**Р.Б. Камаева,** Казан федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
**А.Х. Мөхәммәтҗанова,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты милли мәгариф лабораториясе мөдире, КФУ АФ доценты, филология фәннәре кандидаты

Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 110 б.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә. Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр куя. Укытучылар бу яңарышларны тормышка ашыруда төп рольне башкаралар. Бу уку-укыту әсбабы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Хезмәттә уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләргә, укытуның интерактив алымнарына кыскача күзәтү ясалган һәм аларны дәресләрдә куллану тәҗрибәсе күрсәтелгән; яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында татар теле һәм әдәбияты укытуның кайбер мәсьәләләре ачыкланган.

©ТРМҮИ, 2015

## ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ СҮЗ**....................................................................................4

**I БҮЛЕК. ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЯҢА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР**....................................................................5

**1.1. Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр**.................................................................**8**

1.1.1. Белем бирүнең компьютер технологияләре............8

1.1.2.Үстерешле укыту технологиясе..............................16

1.1.3. Проектлар технологиясе........................................18

1.1.4. Программалаштырылган укыту.............................28

**1.2. Укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр**........................................................................34

1.2.1. Уен технологиясе.....................................................34

1.2.2. Аралашуга өйрәтү технологиясе............................42

**1.3. Уку-укыту процессында интегральләштерү** ...........61

**1.4. Укыту процессында кейс методын куллану**............81

**II БҮЛЕК. ЭЛЕКТИВ КУРС ПРОГРАММАЛАРЫ**............87

**2.1. Әдәплелек – матур гадәт**............................................87

**2. 2. Нәсел тарихын өйрәнү**................................................91

**III БҮЛЕК. ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРДА УНИВЕРСАЛЬ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ** ..........................94

**Кулланылган әдәбият**.......................................................108

# КЕРЕШ СҮЗ

Укыту-тәрбия системасын яңарту – яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләү дигән сүз. Мәктәпләрнең бүгенге бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарларны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү.

Укыту-тәрбиянең бүгенге көндәге уңышы укытучының бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып-белү процессы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәнүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле. Әйләнә-тирәне, кешелек дөньясын өйрәнү һәм аны укучыга дөрес аңлату, укучыны тормышка яраклаштыру – укытучылар алдына куелган мөһим бурыч.

Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы да артты. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә. Хәзерге чорда укытучы күптөрле мәгълүматлар чолганышы эчендә калды. Алар алдында яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып аны үзләштерү зарурлыгы туды.

Бу уку-укыту ярдәмлеге татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә заманча технологияләрне, интерактив алымнарны куллану тәҗрибәсенә нигезләнеп төзелгән.

*Беренче бүлектә* уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләргә һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләргә, интерактив алымнарга гомуми күзәтү ясалды, төп үзенчәлекләре, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә куллануның уңышлы яклары аерып күрсәтелде, дәресләрнең план-конспектлары бирелде.

*Икенче бүлектә* электив курслар турында белешмә, программалар төзү өчен үрнәкләр бирелде.

*Өченче бүлектә* яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында татар теле һәм әдәбияты укытуның кайбер мәсьәләләре яктыртылды.

# I БҮЛЕК.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЯҢА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә. Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр куя. Укытучылар бу яңарышларны тормышка ашыруда төп рольне башкаралар. Укыту-тәрбия системасын яңарту – яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләү дигән сүз. Мәктәпләрнең бүгенге бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарларны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү.

Укыту-тәрбиянең бүгенге көндәге уңышы укытучының бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып-белү процессы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәнүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле. Әйләнә-тирәне, кешелек дөньясын өйрәнү һәм аны укучыга дөрес аңлату, укучыны тормышка яраклаштыру – укытучылар алдына куелган мөһим бурыч.

Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы да артты. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә. Шулай да педагогикага яңалык башка фәннәргә һәм тармакларга караганда авыррак керә. Бу хәлнең сәбәбе, бәлки, кешене укыту-тәрбияләүнең гаять дәрәҗәдә авыр булуыннан киләдер. Кайбер яңалыклар киң күләмдә кулланылмау нәтиҗәсендә кире кагыла һәм бик тиз онытыла. Хәзерге чорда укытучы күптөрле мәгълүматлар чолганышы эчендә калды. Алар алдында яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып аны үзләштерү зарурлыгы туды.

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен алдан уйлап, башкарырга тиешле эшләрне системага салып кую

укыту-тәрбия процессында уңышка ирешергә ярдәм итә.

Татар теле һәм әдәбиятын яңа технологияләр аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү. Бүгенге көндә халык мәгарифе икътисадын, укыту техникасын һәм технологиясен, укытуны компьютерлаштыру мәсьәләләрен өйрәнү-тикшеренү эше киң җәелдә. Шуңа бәйле рәвештә *педагогик технология*, *педагогик техника* төшенчәләре дә актив кулланылышка керде.

Технология – (грек теленнән алынган сүз; *сәнгать, осталык* дигән мәгънәне белдерә) фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланылучы методлар, алымнар, ысуллар җыелмасы ул.

Нәрсә соң ул *педагогик технология*? АКШтагы Педагогик ассоциация һәм технологияләр берләшмәсе аңлатканча, *педагогик технология* укытуны, белемнәрне үзләштерүне, идея-фикерләрне, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Аларның бурычы – укыту процессын, яңалыклар кертеп, даими камилләштереп тору, яңа дәреслекләр, укыту өчен кинофильмнар, компьютерларга программалар һ.б. ярдәмлекләр төзү [7, 7-10].

*Педагогогик технология* төшенчәсенә күренекле педагог-галимнәрнең аңлатмалары төрлечә. Б.Г. Лихачев фикеренчә, педагогогик технология – укыту процессындагы махсус ысуллар, алымнар, психологик-педагогик юнәлешләр җыелмасы; ул – педагогик процессны оештыруның төп коралы. В.П. Беспалько педагогик технологияне “укыту процессын тормышка ашыруда эчтәлекле техника” дип саный. И.П. Волков бу терминны укытуның көтелгән нәтиҗәләрен тасвирлау процессы буларак карый. М.А.Чошанов белем бирү технологиясен дидактиканың состав өлеше дип билгели. Г.К.Селевко *педагогик технология* төшенчәсен өч аспектта карый: 1) фәнни: педагогик технология – педагогиканы белем бирү максатын, эчтәлеген, методларын өйрәнүче һәм педагогик процессларны проектлаучы өлеше; 2) процессуаль-тасвирлаулы: белем бирүдә көтелгән нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәк булган максат, эчтәлек, ысул һәм алымнардан

торган процессны тасвирлау; 3) процессуаль-тәэсирле: педагогик процессны гамәлгә ашыручы, “шәхси, инструменталь һәм педагогик-методологик чараларны хәрәкәтләндерү” [27, 2-13].

Шулай итеп, педагогик технология белем бирүнең иң уңышлы юлларын өйрәнүче фән буларак та, педагогик процесста кулланыла торган ысуллар, чаралар системасы буларак та, белем бирү процессы буларак та билгеләнә. Хәзерге заман таләпләренә туры килә торган белем бирү шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш сынауларына, фән нигезләрен ныклы үзләштерүгә әзерләүне күздә тота. Заманча технологияләр кулланып татар телен өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыру ул. Ул түбәндәге максатларны күздә тотып башкарыла: 1) татар телен өйрәнүгә кызыксындыру, теләк уяту; 2) укучыларның танып белү активлыгын арттыру; 3) телне өйрәнү өчен уңай шартлар булдыру; 4) укучыларның иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу.

Белем бирү технологияләре күп төрле. Шулай да алар арасында охшашлыклар күзәтелә. Максаты, эчтәлеге, кулланылган ысуллары, алымнары һәм чараларының охшашлыгы буенча технологияләрне берничә зур төркемгә берләштерергә мөмкин. Мәсәлән: укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр; уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр; уку материалын методик яктан камилләштерүгә, дидактик яктан үзгәртүгә нигезләнгән педагогик технологияләр; халык педагогикасына нигезләнгән педагогик технологияләр һ.б.

Соңгы елларда белем бирү системасында заманча технологияләрдән *уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр* (терәк схемалар кулланып, алга китеп укыту технологиясе, белем бирүнең компьютер технологияләре, үстерелешле укыту технологиясе, проектлар методы, концентрик белем бирү технологиясе) һәм *укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр* (уен технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, аралашуга өйрәтү технологиясе) уңышлы кулланыла.

Бу яңа технологияләрнең татар телен өйрәтүдә уңышлы, нәтиҗәле кулланылганнарына тирәнрәк тукталырбыз.

## 1.1.УКУ ПРОЦЕССЫН ОЕШТЫРУ ҺӘМ ИДАРӘ ИТҮНЕҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕНӘ НИГЕЗЛӘНГӘН ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләрнең иң мөһим шарты – өстәмә мәгълүмат чыганагы булуда.

### 1.1.1. БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ КОМПЬЮТЕР ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ

Хәзерге заманда компьютер технологияләре кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә үтеп керде. Бер генә белгечлекне дә, профессияне дә адардан башка күз алдына китереп булмый. Укытучы һөнәре дә төрле дәресләрдә компьютер технологияләрен нәтиҗәле куллануны күздә тота.

Дәресне заман таләпләренә туры килгән компьютерлар белән тәэмин итү – информацион технологияләрне гамәлгә куюда беренче шарт. Информацион технологияләрне укыту тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Тиешле белем бирү һәм алган күнекмәләрне кирәкле дәрәҗәдә үстерү өчен, заманча мәгълүмати технологияләрне дәрестә системалы һәм урынлы итеп файдалану зур әһәмияткә ия. Укытучылар мәгълүмати технологияләрне нәтиҗәле кулланып эш итәләр. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бу технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, алар – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив. Компьютер күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Компьютер куллану шулай ук укучыны дөрес язарга, дөрес укырга өйрәтә, сүзлек запасын баета. Компьютерның өстенлеге шунда: мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Компьютер ярдәмендә бик күп эшләр эшләп була: мультимедиа презентацияләре, төрле тестлар, схемалар һ.б. Мәсәлән,

презентацион программаларны төзегәндә, укытучы аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләрне кертә ала. Мондый программа белән танышканда, укучы үзен кино караучы итеп хис итә. Электрон презентацияләр даими кулланылганда гына уңай нәтиҗәләргә китерә. Презентация слайдлары яңа материалны аңлатканда да, белемнәрне актуальләштерү этабында да, белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру этапларында да уңышлы кулланылырга мөмкин. Материал фәннилек, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принципларына җавап бирерлек итеп сайланырга тиеш. Яңа теманы аңлатканда, презентация бирелешенең әһәмияте зур. Слайдларда рәсемнәр, схемалар, даталар, терминнарга аңлатмалар, кыскача тезислар язылырга мөмкин. Яңа тема аңлату дәресе тулаем слайд карап утыруга гына кайтып калырга тиеш түгел. Дәрес барышында башка эш төрләре дә актив кулланыла: дәреслек белән эш, тактага язу, сүзлекләр белән эшләү һ.б. Шулай итеп, презентация материалын күрсәтү башка эш төрләре белән үрелеп бара. Электрон презентацияләр төзү укчыларга өй эше итеп тә бирелергә мөмкин. Мондый эшләр башкару укучыларга үз фикерләрен төгәл, җыйнак итеп әйтеп бирергә мөмкинлек бирә.

Компьютерның мөһим бурычларыннан берсе булып күнегүләр системасын тормышка ашыруны тәэмин итү тора. Ул исә үз чиратында, уку процессын камилләштерергә, сөйләм материалын үзләштерүне җиңеләйтергә тиеш. Эш барышында укучы үзенең җавапларының дөреслеген дә тикшереп бара ала. Мәсәлән, түбәндәге күнегүләрне тәкъдим итәргә мөмкин:

1. Диалогик сөйләм телен үстерү өчен күнегүләр.

Сорау-җавап диалогы. Бу эш вакытында укучы сорауда чагылган тел материалына нигезләнеп, компьютердагы сорауларга җавап бирә.

Җавапны сайлап алу мөмкинлеге булган диалог. Сорауга дөрес җавапны укучы берничә варианттан сайлап ала.

Ирекле җавапка корылган диалог. Бу диалог төрле вариантлагы җаваплары булган компьютер программасы белән тәэмин ителә.

Текстта төшеп калган фразаларны язып бетерү күнегүләре. Компьютер аша текст тәкъдим ителә. Рус телендә бирелгән

сүзләрне татарчага тәрҗемә итеп, укучы текстта файдалана ала.

Диалог төзү өчен үрнәк тәкъдим итү яки тел ситуацияләрен бирү.

Монологик сөйләмне диалогик сөйләмгә әйләндереп язу.

2.Ишетеп аңлау өчен аудиотестлар, сөйләм күнегүләре.

3.Трансформацияләү күнегүләре.

Бирелгән җөмләләрнең, сүзтезмәләрнең урыннарын үзгәртеп бәйләнешле текст төзү.

Бирелгән текстта алмашлыкларны исемнәр белән алмаштырып язу.

Яңа сүзләр кулланып, текстны үзгәртеп язу һ.б.

Информацион технологияләрне укыту-тәрбия эшендә куллану укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты булып тора.

## Дәрестә электрон презентацияләр куллану

Дәресләргә презентацияләр әзерләгәндә түбәндәгеләрне истә тотарга кирәк:

1. Слайдларга языласы материалның эчтәлеге кыска, төгәл булырга тиеш. Зур текстланы аерым тезисларга бүлеп бирергә кирәк.

2. Слайдларга даталар языла; рәсемнәр, схемалар, таблицалар куела.

2. Анимация артык актив булмаска тиеш.

2. Фонга аерым игътибар бирергә кирәк. Сайлап алынган төсләр бер- берсенә туры килергә тиеш.

3. Атылып чыгу, бөтерелү, дулкын, спираль кебек эффектлар кулланылмасын.

## ТЕМА: РОБЕРТ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТОРМЫШҺӘМ ИҖАТ ЮЛЫН ӨЙРӘНҮНЕ ЙОМГАКЛАУ (ДӘРЕС-СӘЯХӘТ)

**Максат:** 1. Р.Миңнуллинның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүне йомгаклау, язучы иҗатының төп үзенчәлекләрен аерып чыгару өчен җирлек тудыру.

2. Укучыларның фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү, сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү.

3. Укучыларда Р.Миңнуллин иҗаты белән кызыксыну уяту.

**Дәресне җиһазлау**: Р.Миңнуллинның портреты, фоторәсемнәре, китаплары, магнитофон, сәяхәт картасы, компьютер; шагыйрьнең иҗатын, тормыш юлын чагылдырган электрон презентация.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

**1. Исәнләшү.**

– Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Бер-берегезгә карап елмаегыз. Шушы җылы мөгаләмәдә дәресне башлыйбыз.

**2. Теманы хәбәр итү.**

– Без Р.Миңнуллинның тормыш юлы белән таныштык. Аның шигырләрен өйрәндек. Ә бүген аның тормыш юлы һәм иҗаты буенча сәяхәт итәрбез. Дәрес ахырында нәтиҗәләр чыгарырбыз. Сәяхәткә кузгалдык, укучылар!

**III. Белемнәрне ныгыту.**

***1 нче слайд.*** *Шагыйрьнең биографиясен чагылдырган фоторәсемнәр.*

– 1 нче тукталыш “Туган як” дип атала. Бу тукталышта без Роберт Миңнуллинның тормыш юлын искә төшереп үтәбез *(1 укучы шагыйрьнең биографиясен сөйли, фоторәсемнәр күрсәтелә).*

***2 нче слайд.*** *Р.Миңнуллинның шигырь, әкият җыентыкларының фоторәсемнәре. Кыскача белешмә.*

– 2 нче тукталыш “ Китапханә” дип атала. Укучылар, сез Р. Миңнуллинның нинди китаплары белән таныш?

– “Көчтәнәч”, “Алма бабай”, “Талбишек”, “Дөньядагы иң

зур алма”, “Хәрефләр бәйрәме”.

– Р. Миңнуллинның “Күчтәнәч”җыентыгы татар халык иҗаты белән турыдан-туры бәйләнгән, килеп чыгышлары ягыннан фольклор жанрлары белән тыгыз мөнәсәбәттә торган жанр үрнәкләре шактый зур урын били. Шулар арасында: 7 сүз уйнату, 7 табышмак, 8 кечкенә әкият, 1аптыраткыч.

“Алма бабай” дигән шигырьләр, әкиятләр китабы эчтәлеге һәм тышкы күренеше ягыннан гаҗәеп матур эшләнгән. Тышлыгы нечкә зәвык белән бизәлгән. Беренче битендә: “Сезнең яраткан шагыйрегез Роберт Миңнуллин балаларга язган шигырьләре өчен Җәлил, Андерсен һәм Алиш бүләкләренә лаек булды”, – дип язылган. Шунда ук М. Җәлил, Г.Х. Андерсен һәм А.Алиш портретлары һәм Р. Миңнуллинның бер төркем сабый балалар белән бергә төшкән матур фоторәсеме урнаштырылган. Аны бизәү, тышкы кыяфәтен эчтәлегенә туры китерү өчен Фәридә Хәсьянова күп көч куйган. “Шигъри әлифба” бүлегендә урын алган 37 шигырьнең һәркайсы милли әлифбаның бер хәрефенә багышлана.

– 3 нче тукталыш “Шигъри тәлгәшләр” дип атала. Укучылар, без Р. Миңнуллинның күп шигырьләре белән таныштык. Аларның кайберләрен яттан өйрәндек. Әйдәгез, шуларны сөйләп алыйк (“Энекәш кирәк миңа”, “Батырлык эшләр идем”, “Белмиләр лә хәлемне”, “Торам менә елмаеп” һ.б.).

**Әңгәмә өчен сораулар:**

– Ни өчен бу шигырьне сайладың?

– Шигырьдә сиңа аеруча кайсы мизгелләр ошады?

– Күз алдыгызга нинди вакыйга, күренеш, кем килеп басты?

– Лирик герой урынында син булсаң, нишләр идең?

– Сезгә иптәшегезнең сөйләве ошадымы?

– “Энекәш кирәк миңа”, “Әни, мин көчек күрдем”, “Батырлык эшләр идем” һ.б. шигырьләрендәге шаянлык, нечкә юмор ярдәмендә шагыйрь нинди олы фикерләр әйтергә тели?

– Шагыйрь ялгызлыкның авыр хәл икәнен аңлатырга

тели.

– Бала тормышның рәхимсезлеге белән очраша. Шуны төзәтергә тырыша, ләкин моның өчен аңа олыларның ярдәме кирәк.

– Дөрес, укучылар, Р. Миңнуллин бала фикерләве аркылы олыларга эндәшә, аларны кисәтә. Баланың уйлары җитди булса да, олыларда ул елмаю тудыра. Бу шигырьләрдә авторның нечкә юморга ия булуы, бала психологиясен яхшы белүе күренә.

– 4 тукталыш – “Тапкырлар иле”. Хәзер мин сезгә табышмаклар әйтәм, сез җавапларын әйтеп тактадагы кроссвордка урнаштыра барырсыз. Әгәр дөрес чишсәгез, уртадагы шакмаклар эчендә бер малайның исеме килеп чыгар. Һәр табышмак җавабына туры килгән шигырьләрне сәнгатьле итеп укырбыз.

***3 нче слайд.*** *Кроссворд.*

1. Үзе ямь-яшел,
Тәнеңне аннан ерак яшер. (Кычыткан. “Талбишек”, 454 бит).

2. Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый. ( Карлыгач. “Алма бабай”, 93 бит).

3. Сумка тотып керәләр,
Белем төяп чыгалар. ( Мәктәп. “Күчтәнәч”, 154 бит).

4. Һичберкайчан сөйләшми ул,
Ләкин һәркем аңлый телен,
Олы дими, кече дими,
Бирә ул безгә белем. ( Китап. “Күчтәнәч”, 96 бит).
Кешеләр нидән көлә? ( Кызык. “Күчтәнәч”, 121 бит).

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | Ы | Ч | Ы | Т | К | **А** | Н | | | | |
| | | | К | А | Р | **Л** | Ы | Г | А | Ч | |
| | | | | | | **М** | Ә | К | Т | Ә | П |
| | | | К | И | Т | **А** | П | | | | |
| | | | | К | Ы | **З** | Ы | К | | | |

(Вертикаль буенча Алмаз исеме чыга)

– Сәяхәтебезне дәвам итәбез. 5 нче тукталыш – “Җырлар

мәйданчыгы” (*укучылар Р. Миңнуллин сүзләренә язылган җыр исемнәрен һәм башкаручыларын укыйлар*).

***4 нче слайд.*** *Р. Миңнуллин сүзләренә язылган җыр исемнәре һәм башкаручылары.*

1.“Әнкәй”, Сара Садыйкова музыкасы, Зөһрә Сәхәбиева башкара.

2.“Әни кирәк”, Мәсхүдә Шәмсетдинова музыкасы, “Бәхетле булыгыз”, Резедә Әхиярова музыкасы, Римма Ибраһимова башкара.

3.“Әйдәгез биибез”, Гали Ильясов музыкасы, Асаф Вәлиев башкара.

4.“Яратыгыз”, Резедә Әхиярова музыкасы, Венера Ганиева башкара.

(*Укучылар магнитофоннан “Әни кирәк”, “Әнкәй” җырларын тыңлыйлар*).

– Сәяхәтебезне дәвам итәбез. 6 нчы тукталыш – “Мактау тактасы”(*укучылар Р.Миңнуллинга бирелгән мактаулы исемнәрне атыйлар*).

***5 нче слайд.*** *Р.Миңнуллинга бирелгән мактаулы исемнәр.*

1.Муса Җәлил исемендәге премия (1982 ел);

2.Абдулла Алиш исемендәге премия, Г.Х. Андерсен исемендәге халыкара Мактау дипломы (1994 ел);

3.Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе ( 1998 ел).

– Безнең сәяхәтебез тәмам. Сезгә сәяхәт ошадымы? Ә хәзер тест эшләп алабыз.

**IV. Белемнәрне тикшерү**.

***6 нчы слайд.*** *Тест.*

**I вариант.**

1. Р. Миңнуллинның туган елы:

а) 1932;

б) 1948;

в) 1954.

2. Шагыйрьнең балаларының исемнәре:

а) Илдар, Гөлназ;

б) Рөстәм, Язилә;

в) Алмаз, Таңсылу.

3. Р. Миңнуллинның туган ягы:
а) Башкортстан;
б) Үзбәкстан;
в) Татарстан.
4. Бу юллар шагыйрьнең кайсы шигыреннән алынган?
*Диңгез матур,*
*Сүз дә юк.*
*Мондый диңгез*
*Бездә юк.*
а) “Мәктәп”;
б) “Батырлык эшләр идем”;
в) “Кайтыйк ла үзебезгә”.
5. Бу өзек кайсы шигырьнең тәрҗемәсе?
*Мы гостей бы пригласили,*
*Целый пир бы закатили.*
*Начались бы шутки, смех,*
*Хватит яблока на всех.*
а) “Әниемә ял кирәк”;
б) “Кояш алмасы”;
в) “Очасым килә”.

**II вариант.**

1. Р.Миңнуллинның туган ягында нинди елга ага?
а) Идел;
б) Чулман;
в) Сөн.
2. Кайсы китап Р. Миңнуллинныкы?
а) “Гөлбакча”;
б) “Күчтәнәч”;
в) “Кирлемән”.
3. Р. Миңнуллин сүзләренә язылган “Талбишек” җырын кем башкара?
а) Илнар Сәйфиев;
б) Илдар Әхмәтов;
в) Илназ Сафиуллин.
4. Бу юллар шагыйрьнең кайсы шигыреннән алынган?
Мине белсә, ул үзе дә

*Сокланып туймас иде.*
*Минем алда берәүне дә*
*Алдарга кыймас иде.*
а) “Күчтәнәч”;
б) “Хәйләкәр малай”;
в) “Туган илнең улы мин”.
5. Бу өзек кайсы шигырьнең тәрҗемәсе?
*Ворбьишки, не кричите!*
*Тише, листья, не шумите!*
*Тише, кошка, не урчи,*
*В кухне плюшкой не бренчи.*
а) “Әниемә ял кирәк”;
б) “Кояш алмасы”;
в) “Очасым килә”.
**7 нче слайд.** Тест җаваплары.
*(Укучылар бер-берсенең эшләрен тикшерәләр, билгеләр куялар).*
**V. Йомгаклау.**
1. Нәтиҗә ясау.

– Шулай итеп, укучылар, без балаларның яраткан шагыйре, өлкәннәрнең якын дусты, бик күп җырлар авторы Р. Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштык. Куандыра, көлдерә, уйландыра Роберт Миңнуллин үзенең укучысын. Сөйкемле, олылар кебек булырга, тизрәк үсәргә, олыгаерга, күбрәк белергә, булдырырга тырышып, дөнья белән танышып йөрүче геройлар яши Роберт Миңнуллин шигъриятендә. Шигырь юллары якты эз салып, күңелдә уелып калалар.

2. Билгеләр кую.
**VI. Өй эше бирү.**

– Р. Миңнулинның шигырьләрендәге бер геройның рәсемен ясарга, характеристика бирергә.

## 1.1.2. ҮСТЕРЕШЛЕ УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

XIX йөзнең беренче яртысында чит ил педагоглары И.Г.Пестолоцци, А.Дистервег, рус галим-педагоглары К.Д.Ушинский, Л.С. Выготский тарафыннан үстерешле укыту

технологиясенә нигез салына. Аның нигезен укучыларның танып белү мөмкинлеген активлаштыру һәм үстерү тәшкил итә. Үстерешле белем бирү теориясе Л.В. Занков, Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдов һ.б. педагогларның хезмәтләрендә алга таба эшкәртелде. Хәзерге вакытта үстерешле укыту буенча берничә технология эшләнгән. Л.В. Занков технологиясе шәхесне төрле яклап үстерүне күздә тота, Д.Б. Эльконин – В.В.Давыдов технологиясе акыл эшчәнлеге үсешен алга куя, иҗади үсеш технологиясенең төп шарты – психологик уңай халәт тудыру. Проблемалы-үстерелешле белем бирү методларын эшләүгә М.И. Мәхмүтов зур өлеш кертте. Ул үз хезмәтләрендә укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләре үсешендә бу методның нәтиҗәле булуын раслады.

Дәресне иҗади үсеш технологиясе нигезендә үткәрүнең иң мөһим шарты – уку эшчәнлеген төркемнәрдә алып бару. “Үсеш (развитие) бары тик аралашу нәтиҗәсендә генә була ала”, – дип язды академик В.Давыдов. Ә профессор Ә.Рәхимов исә үз остазының фикерен “Аралашуга бары тик балалар эшчәнлеген төркемнәрдә оештырып алап барганда гына ирешеп була”, – дип куәтли.

Дәресләрне төркемнәрдә алып баруның өстенлеге турында профессор К.Волков болай ди: “Иң мөһиме – баланың белем алу белән кызыксынуы кинәт көчәя башлый, аңа уңай мөнәсәбәт урнаша. Төркемнәрдә эшләгәндә балаларның 2,1 проценты гына игътибарын читкә юнәлтә.

Эшлекле аралаша белү – төркем әгъзалары арасында килеп туган каршылыкларны җиңәргә өйрәнү дигән сүз. Бу мәсьәләләрне фронталь яисә индивидуаль эш вакытында хәл итеп булмаганлыгы беркемдә дә шик тудырмый” [32, 76].

Психологлар әйтүенчә, төркемнең иң күбе алты кешедән торуы максатка ярашлы. Төркемнәр укучыларның теләген искә алып төзелә, шулай ук балалар арасындагы мөнәсәбәтләр дә игътибарга алына. Тәҗрибә шуны күрсәтә: бергәләп эшләү вакытында нейтраль мөнәсәбәтләр бик күп очракта уңайга әверелә. Бу исә төркемнәрдә эшләүнең өстенлеген дәлилләүче мисал булып тора. Укучыларның уку эшчәнлеген төркемнәрдә оештырып алып бару укытучыдан түземлелек таләп итә. Укытучы баланың җавабын бүлдерергә тиеш түгел.

Дәрестә һәр бирем үтәлгәннән соң, укучыларга үз-үзләренә бәя куярга тәкъдим ителә. Балаларның күпчелеге, гадәттә, үз-үзенә югары бәя куярга ашыкмый. Әгәр кирәк булса, бәя кую өчен төркем җитәкчесе яки укытучының фикере нигез итеп алына.

Дәрес этаплары. Дәреснең беренче этабында кулланылачак белемнәрне искә төшерүдән башлана. Эшне кабатлау рәвешендә төркемнәрдә үткәрергә мөмкин. Бу очракта белмәгәннәргә дә белергә мөмкинлек бар. Икенче этап – уку мәсьәләсен кую. Дәреснең бу өлеше өйрәнеләчәк мәсьәләнең кирәклеген дәлилләүгә багышлана. Берничә сорау куела. Бирелгән җавапларында укучылар дәрестә нәрсә белән шөгыльләнәчәкләрен ачыклыйлар, чишеләсе мәсьәләне дөрес аңлаулары өчен үзләренә билге куялар. Өченче этап – уку мәсьәләсен чишү. Куелган мәсьәлә аерым, гади уку биремнәренә бүлгәләп башкарыла. Һәр бирем үстерешлелек функциясен үти. Һәр бирем билгеле бер адым булып тора. Һәрбер адым саен укытучы сорау куя, уйланырга вакыт бирә, җаваплар тыңлана, нәтиҗә ясала, башкарган эшкә бәя бирелә. Әгәр бала эшчәнлеге даими бәяләнеп бармаса, ул проблема үзенең мөстәкыйльлеген югалта. Бәяне кичектермичә кую – нәтиҗәле укытуның икенче шарты. Дүртенче этап – рефлексия. Дәреснең бу этабында укучы дәрестә нәрсә эшләгәненә, ничек эшләгәненә нәтиҗә ясый. Бишенче этап – белемнәрне формалаштыру, үзбәя, үзконтроль. Бәя кую уку мәсьәләсен кисәкләргә бүлеп өйрәнүдән җыелган билгеләргә нигезләнә. Алтынчы этап – өйгә эш бирү. Өй эше кимендә өч вариантттан торырга тиеш. Балаларга сайлап алу хокукы бирелә.

### 1.1.3. ПРОЕКТЛАР ТЕХНОЛОГИЯСЕ

Укучыларның дөньяны танып белү мөмкинлекләрен, акыл эшчәнлеге мөстәкыйльлеген үстерүдә проектлар методы зур урын алып тора. Бу метод белән оештырылган педагогик процесска түбәндәге сыйфатлар хас:

1. Укучылар эшчәнлеге тормыш тәҗрибәсенә, җәмгыять яшәешенә бәйле проблемаларны хәл итүгә буйсына.

2. Проектлар мәҗбүри рәвештә уңай нәтиҗәләр бирә, ягъ-

ни кешегә, җәмгыятькә файда китерә, тискәре нәтиҗәле проектлар эшләнми.

3. Проект темасын билгеләүдә укучының теләге, кызыксыну өлкәсе исәпкә алына.

4. Проект эшләү этаплары һәм нәтиҗә бирү формалары укучылар тарафыннан үзара киңәшләшеп билгеләнә.

5. Проектлау күмәк рәвештә төркемнәрдә алып барыла.

6. Проектлау барышында төркемнәр һәм һәр укучы үз эшчәнлегенә нәтиҗә ясый.

7. Катлаулы мәсьәләләр буенча фикер алышу оештырыла.

8. Проектлау процессы билгеле бер тәртипкә буйсына, ул укучылар тарафыннан төзелә. [27, 2-13].

Проект эшен башкарганда укучылар өстәмә чыганаклар эзләргә, табылган мәгълүматларны кулланырга өйрәнәләр, аралашу күнекмәләрен үстерәләр, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерәләр, төркемнәрдә эшләргә өйрәнәләр, аларда җаваплылык хисе, үз-үзенә ышаныч формалаша.

Проектлар методы бер яки берничә фән эчтәлегенә нигезләнергә мөмкин. Татар теленнән проект эшләгәндә татар әдәбияты, тарих, экология, география, биология, музыка белән бәйләнеш була ала. Проектлау укучыларның мөстәкыйль эше булса да укытучы җитәкчелегеннән башка уңышлы була алмый. Проект эшләүнең төп этаплары түбәндәгеләр: *проектлау биремен эшләү, проект эшен башкару, нәтиҗә ясау, ягьни гомумиләштерү, проектлар яклау.*

*Проектлау биремен эшләү*. Укучыларга берничә проект темасы тәкъдим ителә, үтәү шартлары билгеләнә, максат ачыклана, эш планы төзелә.

*Проект эшен башкару.* Эш барышында укытучы укучыларга юнәлеш бирә, эш сыйфатына, вакытында үтәүгә контрольлек итә, тиешле төзәтмәләр кертү зарурлыгын күрсәтүче ситуацияләр тудыра.

Гомумиләштерү этабы. Бу этапта укучылар фикерләренең дөреслеген, нигезлелеген бәхәсләрдә, әңгәмәләрдә билгелиләр, бергәләп эшлиләр. Берничә төркем булганда, үзара контрольлек итәләр, экспертиза үткәрәләр, рецензия алалар.

Проектны яклау – төп этап. Бу сыйныф укучылары алдында үтә. Яклау барышында проектның камиллеге һәм кимчелекләре ачылырга, сыйфатына бәя бирелергә тиеш.

Проектлау методын кулланганда укытучы һәм укучыларның аралашуы, хезмәттәшлек итүе үзенчәлекле төс ала: укытучы укучыларның эшчәнлеге белән генә түгел, аларның бергәләп эшләве, фикер алышуы, карар кабул итүе белән дә идарә итәргә тиеш. Бу укытучыдан балаларның аралашу культурасына аеруча игътибар итүне таләп итә. Проектлау методы бары тик укытучы һәм укучы эшчәнлеген тиешле бәйләнештә алып барганда гына югары нәтиҗәләр бирә.

**Проектлау барышында укытучы һәм укучылар эшчәнлеге**

1. Проект биремен әзерләү.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
|---|---|
| Проект темасын сайлау, укытучы белән киңәшү, өстәмә мәгълүмат алу. Максатларны билгеләү | Күзәтүләр үткәрү. Укучыларның кызыксыну өлкәләрен өйрәнү. Темаларны билгеләү һәм укучыларга тәкъдим итү. Эшнең максатын билгеләүдә укучыларга ярдәм итү |

2. Планлаштыру.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
|---|---|
| Эш планын төзү. Бурычларны билгеләү. Укытучы ярдәмендә проект планын камилләштерү. Төркемнәргә берләшү. Эшләрне бүлешү | Проектлау тәртибе белән таныштыру. Укучылар эшләгән планнарны тикшерү, тәкъдимнәр кертү. Һәр укучының вазифасын билгеләү |

3. Эзләнү-тикшеренү.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
|---|---|
| Мәгълүмат туплау. Фәнни әдәбият, матбугат материалларына анализ ясау | Күзәтү, киңәшләр бирү. Алынган мәгълүматларны системалаштырырга өйрәтү, төзәтмәләр кертү |

4. Анализ ясау, гомумиләштерү.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
| --- | --- |
| Тупланган мәгълүматны анализлау, нәтиҗәләрне гомумиләштерү | Күзәтү, киңәшләр бирү |

5. Проектны яклауга әзерләү.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
| --- | --- |
| Проектны куелган таләпләргә куеп эшләү. Чыгыш текстын язу, кирәкле материалларны, техник чараларны әзерләү | Проект яклау тәртибен аңлату. Чыгыш ясау, бәхәсләшү этикеты белән таныштыру |

6. Проект яклау.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
| --- | --- |
| Чыгыш ясау. Фикер алышуда катнашу | Проект яклау барышына контрольлек итү. Фикер алышуларның тиешле юнәлешен тәэмин итү. Тыңлаучылар белән беррәттән сораулар бирү |

7. Проектны бәяләү.

| Укучылар эшчәнлеге | Укытучы эшчәнлеге |
| --- | --- |
| Тәкъдимнәр нигезендә проектка төзәтмәләр кертү. Үзбәя кую. Билге кую өчен укытучыга тапшыру | Проектны камилләштерү белән җитәкчелек итү. Киңәшләр бирү. Проектларга бәя бирү, билге кую |

Проектлар технологиясе рус балаларына татар теле һәм әдәбиятын укыту да да уңышлы кулланылырга мөмкин. “Бәйрәмнәр” темасына сөйләм телен үстерү дәресләре барлык сыйныф укучылары белән дә алып барыла. Аны төрле формада үткәрергә мөмкин. Проектлар технологиясен куллану – укучыларда сөйләм телен үстерү белән беррәттән укучыларны мөстәкыйль эшчәнлеккә өйрәтүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә дә нәтиҗәле алым.

## ИҖАДИ ПРОЕКТЛАРНЫ ЯКЛАУ ДӘРЕСЕ

**Дәреснең темасы:** “Бәйрәмнәр” темасы буенча иҗади проектларны яклау.

**Дәреснең тибы:** Сөйләм телен үстерү.

**Максат:**

1. Өйрәнелгән лексиканы сөйләмдә активлаштыру.

2. Укучыларның сөйләм телен баету, мөстәкыйль эшли белү, төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен камилләштерү.

3. Укучыларда игътибарлылык, ихтирамлылык сыйфатларын тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Рәсемнәр, карточкалар, магнитофон, кошлар тавышлары язмасы, компьютер, проектор.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

*(Исәнләшү, дәреснең максатын җиткерү).*

Бар күңеллелек дөньяда, бар бер ямь бүген
Бәйрәм бүген! Бәйрәм бүген! Бәйрәм бүген!

– Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Бүген бездә зур бәйрәм! Безгә бик күп кунаклар килде. Дәресне башлап җибәрәбез.

*(Татар теленең аңлатмалы сүзлеге буенча* бәйрәм *сүзенең мәгънәсе аңлатыла*).

**Бәйрәм**.

1. Йола буенча үткәрелә торган күңел ачып ял итү көннәре.

2. Зур шатлык, куаныч, тантана.

3. Истәлекле вакыйга хөрмәтенә билгеләнгән тантаналы көн.

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**

*(Алдагы дәрестә үткәннәрне кабатлау максатыннан викторина үткәрелә).*

Викторина.

1. Бәйрәмнәрне шартлы рәвештә нинди төрләргә бүләргә мөмкин? (*Календарь бәйрәмнәре, балачак бәйрәмнәре, гаилә бәйрәмнәре, һөнәри бәйрәмнәр, табигать бәйрәмнәре, йола бәйрәмнәре, дини бәйрәмнәр*).

2. Бирелгән карточкаларда күрсәтелгән числолар буенча

бәйрәм исемнәрен атагыз (*Укытучы карточкалар күрсәтә, укучылар җавапларын әйтәләр*).

1 сентябрь – ... (*Белем бәйрәме*), 8 март – ... (*Халыкара хатын-кызлар көне*), 23 февраль – ... (*Ватанны саклаучылар көне*), 7 май – ... (*Радио көне*), 9 май – ... (*Бөек Җиңү көне*) һ.б.

3. Исемнәре буенча бәйрәмнәрнең нинди төргә керүен әйтегез.

Кошлар бәйрәме – ... (*табигать бәйрәме).*

Туган көн бәйрәме – ... .

Корбан бәйрәме – ... .

Укытучылар бәйрәме – ... .

Яңа ел бәйрәме – ... .

4. Бәйрәмнәргә багышланган нинди шигырьләр беләсез? (Ә.Кари “Кыш бабай бүләге”, Э.Шәрифуллина “Чиккән сөлге”, Х.Шакиров “Хуш килдең, беренче сентябрь”, Ә.Исхак “Укытучы”, Р.Миңнуллин “Балачак бәйрәмнәре”, “Чыршы әйләнәсендә”, С.Сөләйманова “Әниләр бәйрәме”, М.Хөсәен “Сабан туе”, Җ.Тәрҗеманов “Бабай туган көн” һ.б.

5. Бәйрәмнәргә багышланган нинди җырлар беләсез? (Татар халык көе, М.Садри сүзләре “Сабан туе җыры”; Р.Абдуллин көе, Р.Вәлиев сүзләре “Кар кызы”; татар халык җыры “Туй җыры”; З.Хәбибуллин көе, Җ.Тәрҗеманов сүзләре “Яңа ел чыршысы”; А.Ключарев көе, Г.Зәйнәшева сүзләре “Туган җирем – Татарстан”; Р.Андреев көе, Р.Рәкыйпов сүзләре “Мин яратам сине, Татарстан”; И.Хисамов көе, Э.Мөэминова сүзләре “Укытучыма”, Р.Хәсәнов көе, Ш.Галиев сүзләре “Кыңгыраулы мәктәп еллары”; И.Закиров көе, Р.Миңнуллин сүзләре “Әнкәмнең догалары” һ.б.)

**III. Проектларны яклау.**

*(Укучылар үзләре әзерләгән “Яңа ел бәйрәме” проектын яклап чыгышлар ясыйлар).*

**1 нче укучы.** Без Яңа ел бәйрәмен иң күңелле бәйрәмнәрнең берсе дип саныйбыз. Шуңа күрә проект темасы итеп бу бәйрәмне сайладык. Яңа ел бәйрәме ул – үткән елга йомгак ясау, киләсе елны каршы алу. Хәзер без сезгә үзебезне эшләребезне тәкъдим итәрбез. Проект эшенең планы белән таныш булыгыз. (*Экранда эш планы яктыртыла)*. 1.Яңа елны каршылау. 2. Яңа ел кичәсе

өчен костюмнар һәм битлекләрне презентацияләү. 3.Яңа ел табыны өчен меню тәкъдим итү. 4. Котлау хатлары, чакыру кәгазьлре белән таныштыру. 5. Яңа ел тамашасыннан өзек. Сәхнәләштерү.

**2 нче укучы.** Мин сезне Яңа елны каршылау тарихы белән таныштырырмын.

Яңа елны 1 нче гыйнвардан Рим императоры Юлий Цезарь указы белән каршылый башлаганнар. Ә Россиядә Яңа елны 1 нче гыйнварга рус патшасы Петр I күчергән. Петр I гә кадәр безнең илебездә Яңа ел бәйрәменә яшел чыршы бизәү гадәте булмаган. 1700 нче елда беренче тапкыр Яңа елны чыршы белән каршылаганнар.

Кышкы салкыннарның беренче атнасында төрки халыкларда Нардуган бәйрәме үткәрәләр. Ул декабрь ахырыннан 5 нче гыйнварга кадәр дәвам итә. Нардуган – борынгыдан килгән бәйрәм, Яңа елны каршылау бәйрәме. *Нар* сүзе *кояш* дигәнне аңлата. Димәк, *кояш туган*. Яңа ел туган көн. Бу бәйрәмдә кешеләр йөзләрен яшереп киенәләр. Өйдән-өйгә йөреп, бер-берсен бәйрәм белән котлыйлар, такмаклар әйтәләр, бииләр, шаяралар.

**3 нче укучы.** Планетабызның башка почмакларында Яңа елны ничек каршылыйлар соң?

Италиядә Яңа елда өйдәге барлык иске әйберләрне чыгарып ташлыйлар икән.

Венгрия, Германия, Австрия кебек илләрдә Яңа ел табынына кечкенә дуңгыз кыздырып куялар. Ул илләрдә дуңгыз иң бәхетле хайван санала. Ә өстәлгә кош ите куярга ярамый. Бәхет очып китмәсен.

Болгария – розалар иле. Бу илдә Яңа ел төнендә кешеләр бер-берсенә ачылыр-ачылмас роза чәчәге бүләк итәләр.

Бирмада Яңа ел елның иң кызу чагына туры килә. Анда Яңа елда су сибешәләр, шулай бер-берсен котлыйлар.

**4 нче укучы.** Мин сезне чыршы сайлау һәм озак вакыт яшел тоту кагыйдәләре белән таныштырам. 1.Чыршының кәүсәсенә игътибар итегез. Әгәр ул коры булса, чыршы энәләре тиз коела. 2. Чыршыны салкын урамнан өйгә алып керергә ярамый, башта салкынча урында тотарга кирәк. 3. Чыршыны озак саклау өчен, 1л суга 1 аспирин, берничә шикәр эретеп, шул суны 1 чиләк комга

салалар. Аннан соң шул комга чыршыны утыртырга кирәк.

**5 нче укучы.** Без сезгә Яңа ел кичәсе өчен костюмнар һәм маскалар тәкъдим итәбез. (*Бүлмәгә бәйрәм костюмнарыннан укучылар керә. Экранда яңа ел костюмнары күрсәтелә. Кыш бабай, Кар кызы костюмнары һәм елларга бәйле рәвештә сайлап алынган костюмнар: күсе, елан, песи, әтәч, кәҗә һ.б. Һәрбер костюмга куучылар характеристика бирәләр*). Яңа ел бәйрәмендә иң мөһим кунаклар Кыш бабай белән Кар кызы. Кыш бабай – батырлык, ә Кар кызы нәфислек символы булып тора. Шуңа күрә костюм сайлаганда, без аларның характерларын, тышкы кыяфәтләрен истә тотарга тиеш.

**6 нче укучы. Кыш бабай костюмы.** Костюмда иң мөһиме – сакал. Ул йомшак мамыктан ясала. Озынлыгы 30 см чамасы була. Сакал кабартыла, чөнки Кыш бабайның сакалы – аның визиткасы. Матур сакаллы Кыш бабай гына балаларга табигый, “чын” булып күренә ала. Костюмның икенче мөһим өлеше – Кыш бабайның таягы. Гади таяк алабыз, аны ак тукыма белән тышлыйбыз. Таякны ялтыравыклар белән бизибез. Ялтыравык күп булса, таяк “тылсымлырак” күренә. Кыш бабайның кулы ачык булырга тиеш түгел. Шуңа күрә бияләйләр әзерлибез. Бияләй Кыш бабайның туны белән бер төстә була. Кыш бабайның тунына кызыл бәрхет тукыма алабыз. Якасына, җиң очларына ак бәрхеттән манжет тегәбез, ялтыравыклы кар бөртекләре ябыштырабыз. Аякка ак итекләр киелә.

**Кар кызы костюмы.** Бу костюм өчен зәңгәр ефәк тукыма алабыз. Якасына, җиңенә һәм итәгенә ак ефәктән манжет тегәбез. Тунга кар бөртекләре ябыштырабыз. Башына таҗ ясыйбыз. Аягына ак чигүле читек киелә.

**7 нчы укучы. Ат костюмы.** Костюм өчен ике кешелек бөркәнгеч тегәбез. 2 пар итек, ат битлеге сатып алабыз.

**Елан костюмы.** Аның өчен сарылы-яшелле ефәк тукыма алабыз. Күлмәкне арттан озын итеп тегәргә кирәк. Еланның телен, нечкә таякка кызыл тасма ябыштырып, кулына тоттырабыз.

**Песи костюмы.** Песи – хәйләкәр хайван. Бу костюмнан күренеп торырга тиеш. Костюм өчен кызгылт-сары бәрхет тукыма алабыз. Аякларына көрән аяк киеме, ә кулларына перчатка әзерлибез. Песи битлеге ясыйбыз.

**Әтәч костюмы.** Әтәчнең матурлыгы аның костюмында да чагыла. Аның костюмы ачык төсле тукымалардан гына тегелә. Башына кызыл бәрхеттән кикрик куела, ә борыны картоннан ясала. Койрык өчен башта тимер чыбыктан форма ясала, аннан соң төрле төстәге тукымалар белән бизәлә. Аягына озын аяк киеме алына.

(*Укучылар барлык костюмнарга характеристика биреп чыгалар*).

**8 нче укучы.** Яңа ел табыны өчен меню.

**9 нчы укучы.** (*Яңа ел котлулары һәм бәйрәмгә чакыру кәгазьләре эчтәлеге белән таныштыра. Котлау хатларының, чакыру кәгазьләренең бизәлү үрнәкләре слайдларда күрсәтелә*).

| | |
|---|---|
| Чакыру кәгазе<br>Кадерле укытучылар,<br>әти-әниләр!<br>Сезне 30 декабрьдә “Кар кызы бәйрәмгә чакыра” дигән<br>яңа ел тамашасына чакырабыз.<br>Үткәрү урыны:<br>мәктәпнең мәҗлесләр залы.<br>Башлана: 18 сәгатьтә.<br>Рәхим итегез!<br>9-11сыйныф укучылары. | Котлау хаты<br>Кадерле дуслар!<br>Сезне бәйрәм бәйрәм белән тәбрик итәбез.<br>Сезгә Яңа елда яңа уңышлар,<br>бәхет-шатлыклар телибез!<br>Яңа еллар килсен бәхет алып,<br>Яңа еллар килсен елмаеп.<br>Күңелләрдә мәңге шатлык булсын,<br>Яшәмәгез, дуслар моңаеп.<br>Кыш бабай, Кар кызы. |

**IV. Яңа ел тамашасыннан өзек тәкъдим итү.**

**1 нче укучы.** Хөрмәтле дуслар! Иске елны озатырга, Яңа елны каршы алырга Кыш бабай белән Кар кызы килеп җитәргә тиеш (*шул вакытта фонограммада кыңгырау чыңы, тояк дөпелдәве, җил сызгырган тавышлар яңгырый*).

**2 нче укучы.** Ишетәсезме, дуслар, кар-бураннар туздырып, кыңгыраулы пар атларда Кыш бабай килә! (*Кыш бабай белән Кар кызы керәләр*).

**Кыш бабай.** Исәнмесез, кадерле дуслар, хөрмәтле кунаклар, балалар! Яңа ел бәйрәмегез күңелле узсын, өстәлләрегез түгәрәк булсын! Без Кар кызы белән тайгалар, тундралар үтеп басуларны кар бөртекләре белән бизәп, урманнарны ак юрганга төреп, сезнең бәйрәмегезгә килдек. Ә бәйрәмегез матур! Чыршыгыз гүзәл!

**Кар кызы.**
Ап-ак карлы аланнарда
Биеп йөрдем мин.
Чыршыларга ак энҗеләр сибеп йөрдем мин.
Ак сакаллы, ак күңелле
Бабам белән без,
Җир өстенә аклык-пакьлек
Алып киләбез.

**Кыш бабай.** Без бәйрәмгә бик күп бүләкләр белән килдек.

**3 нче укучы.** Әйдәгез, дусларым, төрле уеннар уйнап, биеп-җырлап алыйк.

**Уеннар.**

**“Көйне тап” (**Өч яки биш кеше катнаша. Кем җырларның исемен дөрес әйтеп, күп очко җыя, шул – җиңүче).

**“Музыкаль урындык”.**

**Кыш бабай.** Дуслар сез бик күңелле ял итәсез икән. Мин дә сезнең белән ял иттем. Капчыгым да бушады, китәргә вакыт җитте. Киткәнче, мин сезне Яңа ел белән таныштырам. (*Хайван яки җәнлек костюмында Яңа ел керә*). Кадерле балалар, безнең китәр вакыт җитте. Сезгә Яңа ел яңа уңышлар, шатлык-бәхет алып килсен.

**Кар кызы.** Тормышыгызда шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, хуш исле чәчәкләр күп булсын! (*Кыш бабай белән бергәләп)* Хушыгыз, сау булыгыз!

(*Укучылар җыр җырлап, Кыш бабай белән Кар кызын озатып калалар*).

**IV. Йомгаклау. Кроссворд чишү.**

*(Дәрес материалы буенча укучыларга бер-берсенә сораулар бирергә тәкъдим ителә*).

– Укучылар, сез зур эш башкарып чыктыгыз. Сез Яңа ел бәйрәменең иң күңелле бәйрәм икәнен күрсәтә, дәлилли алдыгыз. Эшләнгән эшләрне “Бәйрәмнәр” папкасына туплап куярбыз.

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | Х | Б | | | | | | | | | |
| Х | Х | Х | 2. | | Ү | | | | | | | Х | Х | Х |
| Х | 3. | | | | Л | | | Х | Х | Х | Х | Х | Х | Х |
| Х | Х | Х | 4. | | Ә | | | | | Х | Х | Х | Х | Х |
| | | | | 5. | К | | | Х | Х | Х | Х | Х | Х | Х |

1. Йолдыз-йолдыз вак кына,
Челтәр-челтәр ак кына,
Өс киеменә куна,
Тәнгә кунса, су була. (*Кар бөртекләре*).
2.Кыш Бабайның балаларга бүләге. (*Кучтәнәч*).
3.Тышта җылы, саф һава.
Йә, әйт, нинди кар ява? (*Ябалак*).
4.Келт-келт итә, келт итә,
Яңа елның килгәнен
Һәркемгә хәбәр итә. (*Сәгать*).

– Укучылар, үзәктә чыккан сүзгә игътибар итегез әле. Әйе, бу *бүләк* сүзе. Без бер-беребезгә бүләкләр әзерләдек. (*Укучылар матур теләкләр әйтеп, бүләкләрен тапшыралар*).

**V. Билгеләр кую. Өй эше бирү.**

“Әгәр сездә Кыш бабайның тылсымлы таягы булса, ни эшләр идегез?” темасына хикәя язарга.

## 1.1.4. ПРОГРАММАЛАШТЫРЫЛГАН УКЫТУ

Программалаштырылган укыту теориясенә башлангычны Америка педагоглары һәм психологлары үзләренең тикшеренүләре белән нигез салдылар. Америка психологы Б.Ф.Скиннер укыту материалын үзләштерүнең уңышлылыгын тәэмин итү өчен аны зур булмаган кисәкләргә – этапларга бүлеп бирүне һәм һәр кисәкне үзләштерүне тикшереп баруны, ягъни туры программалаштыруны тәкъдим итте. Соңрак Н.Краудер тармаклы программалаштыруны эшләде.

Туры программалаштыру принцибы буенча укучы уку материалы өстендә эшләүне эзлекле рәвештә бер этаптан икенче этапка күчү формасында алып бара. Мондый очракта укучылар программаның этапларын рәттән эшкәртеп, бер юл белән баралар. Еш кына һәр этап рама эченә алына. Туры принцип белән төзелгән әсбаплар белән эшләгәндә, барлык укучылар бөтен материалны рәттән эшкәртәләр. Тармаклы принциптан файдаланганда, укучы уку материалының билгеле бер өлешен эшкәртә, җавапларның ни дәрәҗәдә дөрес булуыннан чыгып ул алдагы

эшкә күрсәтмәләр ала.

*Блоклы-модульле укыту* – программалаштырылган укытуның бер төре. Бу программаның уңай яклары түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Чагыштырмача зур вакыт аралыгында предмет белән тирәнтен шөгыльләнү.

2. Модульнең һәрбер өлешен тулы done бербөтен итеп кабул итү.

3. Алынган белемнәрне мөстәкыйль фикерләүдә куллану. Системалы рәвештә китап һәм башка информация белән эшләү күнекмәсе булдыру.

4. Белемнәрне тикшерүне даими алып бару.

5. Стресс халәтенең булмавы (чөнки билге алдагы этапларда гына алыначак).

Дәресләр түбәндәге максатларны күздә тотып бүленә:

1. Дәрес-лекция. Фәннилек, үзләштерә алу. Вакытның дөрес бүленеше. Материалның җентекләп әзерләнгән булуы. Укучының аңын дисциплинага буйсындыру максатыннан, лекциянең кыскача язылып баруын тәэмин итү. Язучы турында сөйләгәндә, аның шәхесен кайсы яктан күрсәтү мөһим.

2. Мөстәкыйль эзләнү дәресе. Белемне укучы үзлегеннән ала. Дәреслек һәм өстәмә чыганаклар белән мөстәкыйль эшли. Укытучы юнәлеш биреп кенә тора. Биремнәр конкрет булырга тиеш.

3. Практик дәрес. Текст өстендә эш. Төрле практик эшләр. Әңгәмә, сурәтләү чараларын тикшерү. Рольле биремнәр, катлаулы план төзү. Шигырьләр уку һәм анализлау.

4. Контроль дәрес.

## ДӘРЕСТӘ БЛОКЛЫ-МОДУЛЬЛЕ ТЕХНОЛОГИЯ КУЛЛАНУ

**Дәреснең темасы:** Һади Такташ. Шагыйрьнең биографиясе, иҗади мирасы.

**Максат:**

1. Шагыйрьнең тормыш юлы, шәхесе белән таныштыру. Иҗатының үзенчәлекләрен ачу.

2.Укучыларның дөньяга карашын формалаштыруга этәрү.

3. Һ. Такташ иҗатына кызыксыну уяту.

**Дәресне җиһазлау:** Шагыйрьнең портреты; төрле елларда чыккан җыентыкларыннан, фоторәсемнәреннән, истәлекләрдән, тәнкыйть материалларыннан күргәзмә; плакат.

**1 нче дәрес. Дәрес-лекция**

## Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

(*Дәреснең максаты, барышы белән таныштырыла. Төп фикерләрне дәфтәрләрдә теркәп барырга кирәклеге искәртелә*).

**II. Укытучы лекциясе.**

“Җир әйләнә. Вакытның кодрәтле агышын беркем туктата алмый кебек. Ә менә шигъри тылсымга ия булган Такташ заманының кабатланмас сынын шигърият теленә күчерү белән мизгелләрне туктата алган”, – дип язган Нил Юзиев. Нил Юзиев шагыйрь иҗатын, аның поэтикасын, татар шигъриятенә алып килгән яңалыгын өйрәнүгә мөһим өлеш керткән. Такташның туу ында да символик мәгънә бар. Яңа гасырның беренче көне, тәүге иртәсе 1901 ел, 1 гыйнвар.

Хәйрулла улы Һади элекке Тамбов губернасы Сыркыды авылында (Хәзерге Мордва республикасы Тарбеево районы) урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Һади башта үз авылындагы мәктәпкә йөри, аннан соң үзләреннән утыз чакрым ераклыктагы Пешлә мәдрәсәсендә укый һәм 1913 елда аны тәмамлап чыга. Монда ул әдәбият белән кызыксына башлый, җиде яшендә чыгарган такмагы да бар аның. “Соңга таба авыл җырчысы булып киттем, – дип искә ала шагыйрь. – Минем җырларны әле дә Сыркыдыда җырлыйлар бугай”.

Крестьянның әйбәт гадәте бар, ул баласын яшьтән үк һөнәргә өйрәтү ягын карый. 1915 елда Такташны әтисе, кардәш тиешле кешеләргә ияртеп, Урта Азиягә җибәрә. Алар бай кешеләр булсалар да, Һадины “йомышчы малай” итеп кенә файдаланалар. 1916 елда ул Бохарага күчеп китә, анда да шул ук хезмәтне үти. Әмма малайның укырга омтылышы зур була, ул үзлегеннән белемен арттырырга тырыша.

1918 елгы күтәрелештән соң, каты ээзәрлекләүләр башлангач, ул үз авылына кайтып китә, анда балалар укыта һәм

китапханәче булып эшли.

1920 елда Һади Такташ белемен арттыру нияте белән Оренбургта оештырылган сәяси курсларга укырга керә. Бу елларда иген уңмау сәбәпле Идел-Җаек буйларында яшәү шартлары кыенлашкач, дусларының тәкъдиме белән 1921 елның язында Ташкент шәһәренә күчә һәм “Белем йорты” журналының җаваплы секретаре булып эшли башлый. Монда шагыйрьнең иҗат офыклары ачыла.

Аның иҗат башламында гаять үзенчәлекле романтизм юнәлеше урын ала. Такташ романтизмының үзенчәлеге шәхеснең азатлыгын, аның чынбарлык белән каршылыкка кергән теләк-омтылышларын сурәтләүләрдән гыйбарәт. Шагыйрьнең романтик герое тыелгысыз дәрт, көчле теләк, чикләнмәгән омтылышы белән үз идеалына, иреккә бара. Чынбарлыктагы гаделсезлеккә, тарлыкка, караңгылыкка каршы көрәшкә чыккан ялгыз романтик герой – фәрештә. “Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт, монда үлем”, ди ул “Газраилләр” шигырендә. “Күктән сөрелгәннәр”(1918) шигырендә фәрештә инде җирдәге коллык, күз-яшьләрне бетерү өчен җанын бирә. Романтик герой эзләнүләренең кульминациясе – “Җир уллары” (1921) трагедиясендә. Ул – гомумкешелек проблемаларын урап алган җитди әсәрләренең куәтлесе. Яңага күчү дип аталган каршылыклы заманда Һ.Такташ та җир уллары трагедиясенә борчылып, җавап эзләгән фантаст шагыйрь. Хәятның дулкынлы хәрәкәтен сиземләтерлек дини-мифик сюжетның шартлы мөмкинлекләрен табып, вакыйгаларны тәэсирле сурәтли белүе белән шагыйрь безне фәлсәфи тирәнлеккә, тарихи борылышларның аеруча сикәлтәле, тигезсез барышы турындагы фикерләүгә этәрә.

Күп әсәрләрендә бер үк тема кабатланганауын искә алып, бу елларда Һ.Такташ иҗат иткән әсәрләрнең даими эчтәлеген тормыштан канәгатьсезлек тәшкил итә, дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Шундый авыр шартларда нәрсәгә өметләнеп яшәргә? Күңелне ничек тынычландырырга? Бу елларда язылган шигырьләрнең кайберсе шул сорауларга җавап эзләүгә – юануга багышлана.

Иң тәүге шигырьләрендә Такташ үзен гадәттән тыш бер

кеше итеп сурәтли. Үзенең бөтен дөнья кешеләрен елатырлык шигырьләр яза алачагына ышана. Юанычы шул “куркыныч” шигырьләре була. Үзенең бер мәкаләсендә әдип: “Бөтен дөньяга мәшһүр шагыйрь булырмын дип уйлый идем. Тора-бара... ул теләгемнең ерагая барганын сиздем”, – дип яза. Соңрак шагыйрь мәхәббәт турында яза башлый. “Антым” шигырендә “Түзә алмый канга, вәхшәткә, Мәхәббәт байрагын алдым” ди һәм шуның белән юануның башка төренә күчүен белдерә. Бер-бер артлы мәхәббәт турында “Таң кызы”, “Урман кызы”, “Зәңгәр күзләр” шигырьләрен яза. Аннары мәхәббәт темасы көрәш темасына алышына.

“Көрәшчеләр! Сезнең арагызга яшь бер егет килә”, – ди әдип “Такташ үлде”(1923) шигырендә. Иҗатындагы бу үзгәрешләрне шагыйрьнең бу вакытта укыган китапларыннан эзләргә кирәк. Бу чорда Һ.Такташ рус әдәбиятын яратып укый. Яшь егетне бигрәк тә бөек рус әдәбиятындагы мәхәббәт темасы кызыксындыруы бер дә гаҗәп түгел. Мәхәббәт Такташның үз әсәрләренә дә явызлыкка каршы торырлык матурлык булып килеп керә. Ләкин китаптан гына кергән мәхәббәт матурлыгы шагыйрьнең үзен дә канәгатьләндерми башлый.

Ә менә көрәш темасы тормышның үзеннән килә. Көрәшче булу теләге Такташта күп еллар буе эзләнүләрдән, газаплы эчке каршылыклардан соң туа. 1924 елдан соң язган әсәрләрендә шагыйрьнең дөньяга карашында җитди үзгәреш күренә. Шагыйрьгә илһам чишмәсе халык йөрәгеннән, аның авыр, мәшәкатьле тормышыннан килә. Шагыйрь халыкның бүгенге газабы белән вәгъдә ителгән матур киләчәк арасында бернинди бәйләнеш юклыгын сиземли. “Сыркыды авылы” шигыреннән башлап, әдип тормышның бүгенгесен матур киләчәктән аерып сурәтли башлый. Кайчандыр кешеләрнең бәхетле булачагына ышана. “Әйдә, энем” шигырендә “Җәен үсәр зәңгәр чәчәкләр”, ди. Ә “Нәни разбойник” шигырендә “Ерак калмый инде майга да, Яз ясарбыз салкын тайгада”, дип фикерен куәтли. “Киләчәккә хатлар”(1930-1931) поэмасында да шагыйрь “Коммунизм кыры күренә” дип кабатлый. Бу шигырендә дә ул кешеләрнең михнәте турында яза. Ләкин шагыйрь әсәрнең объектив эчтәлеге артына

субъектив эчтәлекне яшереп бирә алган. “Киләчәккә хатлар” – тәмамланмаган әсәр. Такташ аны ун хат итеп язарга уйлый. Тик әдипнең фаҗигале үлеме алдагы иҗат планнарын кисә, ул 1931 елның декабрендә Казанда вафат була.

“Әйтергә кирәк, Һади Такташны озату моңарчы күз күрмәгән дәрәҗәдә зур һәм тантаналы булып узды, – дип яза шагыйрьнең замандашы Әмирхан Еники. – Декабрь көне шактый салкын булуга карамастан, халых урамны бөтен иңе белән тутырып, язгы ташудай агылып барды. Бигрәк тә укучы яшьләр, студентлар күп иде. Такташ аларның иң сөекле шагыйре иде ул заманда”. Танылган драматург Риза Ишморат болай дип язды: “Уртача буйлы, дулкынланыбрак торган озын һәм саргылт чәчле, зәңгәр күзле Такташ олы йөрәкле, искиткеч ягымлы, чын мәгънәсендә кешелекле кеше иде. Тавышы да көр һәм нәфис. Үз шигырьләрен ул сәхнәдән таң калдырырлык оста, сүзләренең эчке мәгънәсен бөтен тирәнлеге белән тыңлаучыга җиткереп укый”.

Такташ үзе исән чакта аның 13 китабы дөнья күрә, аларның гомуми тиражы – 50 мең. 1931 елдан хәзерге көнгә кадәр 35 тән артык китабы басылып чыккан. Аларның тиражы 350 меңнән артык. Такташ әсәрләре башкорт, үзбәк, казакъ, кыргыз, украин, эстон, чуваш, мари, молдован телләренә, аерым әсәрләре уйгур, монгол, венгр телләренә тәрҗемә итеп басылган.

**III. Йомгаклау.**

Укучылар үзләре язып алган төп фикерләрне укыйлар. Укытучы дәресне йомгаклап, Такташ иҗатының үзенчәлекләрен укучыга җиткерә.

**2 нче дәрес. Укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге.**

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.**

**II. Укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге.**

1.Һ.Такташ турында истәлекләр уку, кайбер эпизодларны сөйләү.

2.Ф.Галимуллинның Һ.Такташ турында язмаларын конспектлау: “Шагыйрь иҗатының бөтенлеге”, (311-325 нче битләр). Биремнәрне үтәү: 1.Һ.Такташның романтик шагыйрь булуының

сәбәпләрен ачыкларга. 2.Шагыйрь ни өчен символлар куллана? Бу аңа ни өчен кирәк? 3.Ф. Бәйрәмованың “Атылган йолдыз” әсәре буенча укучылар чыгышы (*ике укучыга алдан ук реферат әзерләргә бирелә*).

**III. Йомгаклау.**

3нче дәрес. Практик дәрес.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру өлеше.**

**II. Практик эш.**

1. Ф.Сафинның “Саташып аткан таң” романыннан (115-120 битләр) Һ.Такташ турында язылганнарны уку.
2. Һ.Такташның шигырьләрен сәнгатьле уку.
3. Шагыйрьнең кайбер шигырьләрен анализлау (“Ертык бүрек”, “Кояш күктә шулай мәңге йөзәр”, “Болай... гади җыр гына”, “Такташ үлде” һ.б.)

**III. Йомгаклау, билгеләр кую.**

**Укытучы.** Шигырьләрендә Такташның ахыргача үзе булып калуына, ихласлыгына сокланмый мөмкин түгел. Чорның катлаулы тормышын, мең каршылыклардан торган көрәшен җырларга алынган шагыйрь тарафыннан бер карашка бөтенләй әһәмиятсез булып тоелган детальләр һәм фактлар гадәттән тыш уңышлы һәм зәвыклы файдаланыла. Шагыйрь яшәү һәм иҗат принципларына ахыргача тугрылыклы калган.

**V. Өй эше бирү.**

1. Һ.Такташның бер шигырен ятларга.
2. “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасын укырга.

## 1.2. УКУЧЫЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕН АКТИВЛАШТЫРУ ҺӘМ ИНТЕНСИВЛАШТЫРУГА ЮНӘЛТЕЛГӘН ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

### 1.2.1. Уен технологиясе

Кеше тормышында уен хезмәт, эш кебек үк әһәмиятле урын тота. Шуңа күрә дә кешене балачактан тәрбияләү, аның киләчәктәге эшчәнлегенә юл салу уен процессында башлана. Бала уенда нинди булса, үскәч, эшендә дә шундый ук була. Ае-

рым кешенең яшәү тарихын, ягъни аның эшчәнлеген һәм нинди шәхес булып җитүен балачактагы уенның алга таба үсеше, аның акрынлап эшчәнлеккә күчүе итеп карарга мөмкин.

Элекке заманнардан ук кешеләр уенны өлкәннәрнең тәҗрибәсен буыннан-буынга тапшыруда нәтиҗәле чара буларак файдаланганнар.

Уен – бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз бер өлеше. Тәрбия чарасы буларак, ул балаларның камилләшүенә, шәхес буларак формалашуына, үзгәрүенә этәргеч булып тора. Балага белем һәм тәрбия уен аркылы яхшырак бирелә. Ул уйнаган вакытта бик күп нәрсәләрне таный, үзенә күнекмәләр ала. Уен формасында оештырылган дәресләр фән белән кызыксынуны көчәйтә, баланың мөстәкыйльлеген үстерә.

Педагогика һәм психология өлкәсендә укыту методы буларак уен XX гасырның 70 нче елларында киң тарала. Укыту процессында уен технологиясе максатчан, булуы белән гомуми уен эшчәнлегеннән аерылып тора. Хәзерге көндә мәктәпләрдә уку-укыту процессын активлаштыру һәм интенсивлаштыру максатыннан уен эшчәнлеге түбәндәге очракларда файдаланыла:

1) фәнне өйрәнүдә мөстәкыйль технология;

2) нинди дә булса технологиянең бер состав өлеше;

3) дәрес яки аның бер этабы (кереш өлеше, яңа теманы аңлату яки ныгыту, күнегүләр эшләү яки контроль эш һ.б.);

4) дәрестән тыш эшләр технологиясе.

Дәресләрдә уен технологиясе уенга корылган төрле ситуацияләр аша тормышка ашырыла һәм уку эшчәнлегендә кызыксындыру, эшкә дәртләндерү чарасы буларак файдаланыла. Уен технологиясе укучыларның танып белү активлыгын үстерә, акыл үсешен активлаштыра, аларда яңа сыйфатлар булдыруга ярдәм итә. Уен вакытында фән белән кызыксыну көчәя, мөстәкыйльлек, ихтыяр көче, игътибарлылык арта, хәтер яхшыра, уйлау күнекмәләре камилләшә.

Укытучы педагогик уенның төп асылын аңлаганда гына уку белән уенны аралаштыру процессы уку-укыту эшчәнлегендә уңай нәтиҗәләргә китерә. Уен аша укытучы укыту һәм тәрбия бурычларын уңайлы хәл итеп кенә калмый, ә укучы белән аралашу-

ны да җайга сала. Балалар коллективын берләштерүдә, туплауда, дусларча мөгамәлә урнаштыруда да уенның әһәмияте зур.

Беренче чиратта уеннарны эшчәнлек төре буенча берничә зур төркемгә бүлеп карарга кирәк: хәрәкәтле уеннар, интеллектуаль уеннар, психологик уеннар, иҗтимагый уеннар.

Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә түбәндәге уен төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин: дидактик уеннар (бу төр уеннар укучыларда белем-күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып-белү эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлтелгән), тәрбияви уеннар, иҗади уеннар, коммуникатив уеннар.

Үткәрү методикасы буенча уеннар бик күп төрләргә бүленә: предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.

Төрле фәннәргә бәйле рәвештә уеннар берничә төргә бүленә: математик уеннар, химик уеннар, физик уеннар, экологик уеннар, музыкаль уеннар, әдәби уеннар, спорт уеннары һ.б.

Уеннар яңа теманы үзләштерү, белемнәрне ныгыту, гомумуку күнекмәләрен формалаштыру, иҗади сәләтләрен үстерүдә куелган бурычларны уңай хәл итүдә зур мөмкинлекләргә ия.

Башлангыч сыйныфларда уен – татар теле дәресләрендә уку эшчәнлеген оештыруның югары нәтиҗәле чарасы. Аны белем бирүнең барлык этапларында да кулланып була. Ул әзерләнгән һәм әзерләнмәгән сөйләмне формалаштыру һәм үстерү өчен уңай шартлар тудыра, кыенлыкларны җиңү шатлыгын тоярга булыша, коллекивизм рухы тәрбияли. Уен балаларның фикерләвен, сөйләмен һәм хәтерен үстерә.

Башлангыч сыйныфларда укучылар предметлы уеннарны, әкият геройларына бәйле булган рольле уеннарны теләп башкаралар. Ә урта һәм югары мәктәп укучылары тарафыннан тормышкөнкүреш темаларына аралашуга багышланган рольле уеннар, хезмәт эшчәнлеген чагылдыра торган һөнәри (эшлекле) рольле уеннар уңышлы башкарыла.

*Рольле уеннарның* өйрәтү мөмкинлекләре зур. Уеннарны парлап та, төркемләп тә үткәрергә мөмкин. Мондый уеннарны үткәрү өчен пьеса формасында уенның моделе төзелә. Укучыларга рольләрнең сүзләре бүлеп бирелә. Уен вакытында катнашучылар бер-берсе белән аралашалар, аларның табигый рәвештә

нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау, әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа. Бу уеннар берничә этаптан тора: *әзерләнү этабы* (сценарий төзү, уен өчен кирәкле материалларны әзерләү, үткәрү планын төзү, максат-бурычларны билгеләү, уен кагыйдәләрен ачыклау, рольләрне бүлешү, төркемнәргә бүленү, консультацияләр үткәрү һ.б.) *уенны үткәрү этабы* (кирәкле чыганаклар белән эшләү, төркемнәрнең чыгышы, дискуссияләр үткәрү, экспертларның эшләре һ.б.) *йомгаклау этабы* (уенга анализ ясау; бәяләү; нәтиҗә ясау, киңәшләр бирү һ.б.) . Рольле уеннар төрле тип дәресләрдә дә уңышлы кулланылалар. Уенны оештырганда түбәндәге максатларны күз алдында тоту мөһим:

1. Укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыру.
2. Сөйләм эшчәнлеге дәрәҗәсенең төрле булуын истә тотып, рольләрне дөрес бүлү.
3. Тормышта укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрдән файдалану.
4. Үзара ярдәмләшү, телдән дөрес актив аралашу мохиты булдыру.

*“Күренекле шәхесләр” уены.* Һәрбер укучы бер күренекле кешене сайлап ала һәм беренче заттан аның турында сөйләргә тиеш була. “Күренекле шәхес” укытучы өстәле янына чыга, ә калган укучылар аңа сораулар бирәләр. Ролен тиз танытмас өчен, бу уенчы сорауларга турыдан-туры ачык итеп җавап бирми. Әгәр төркемдәге укучылар бу шәхесне танысалар, фамилиясен кәгазьгә язып, укытучыга бирәләр. Берничә дөрес җавап табылганнан соң, укытучы уенны туктата һәм җиңүчене билгели.

*“Күршеләр” уены*. 1.Иң башта укучылар үзләренең күршеләре турында сөйлиләр. Укытучы укучылардан күршеләре белән ничек яшәүләрен сораштыра: күршеләре аларны борчымыймы, бигрәк тә нәрсә аларга комачаулый (кирәкле-кирәксез шакылдау, көчле тавыш белән телевизор карау, музыка тыңлау һ.б.). Күршеләрдән канәгатьсезлек сәбәпләре тактага язылып куела. Шуннан соң төркем парларга бүленә, биремнәр таратыла. Һәрбер пар күрсәтелгән сәбәпләрнең берсен сайлап ала, диалог төзеп, аны уйнап күрсәтә. Аннан соң парлар яңадан төркемнәргә берләшәләр һәм күршеләр белән яхшы яшәү кагыйдәләрен төзиләр. 2. Бу уен мәгълүмат җыюга нигезләнеп төзелә. Уен-

да катнашучылар бәйрәм табыны янына чакырыла. Табын янында күрше утыручалар арасында әңгәмә оештырыла, алар кайчандыр бер-берсен күргән кебек, ләкин кайчан, ничек очрашулары турында хәтерли алмыйлар. Уенчыларның төп максаты – шул очрашуны ачыклау. Сөйләшү барышында кунаклар бер-берсе белән танышалар, кайда яшәүләре, кайда укулары турында һ.б. сорашалар.

Уен технологиясен уку-укыту процессында куллана башлаганчы, иң башта кайсы темаларны уен аша өйрәнү максатчан булуын ачыкларга кирәк. Уенны оештырганда вакыт бүленешен төгәл билгеләргә кирәк, чөнки ял вакытларында уен кагыйдәләре бозылырга һәм уенның нәтиҗәлелегә түбән булырга мөмкин. Рус балаларына татар телен өйрәтүдә уен технологиясе куллану бигрәк тә нәтиҗәле. Уеннар куллану балаларга тел материалын гамәли эшчәнлектә үзләштерергә булыша.

## ДӘРЕС-ЭШЛЕКЛЕ УЕН “ТАТАР ТЕЛЕН ЯРАТУЧЫЛАР КЛУБЫ” УТЫРЫШЫ

**Дәреснең темасы:** “Сыйфат” темасын гомумиләштереп кабатлау.

**Максат:**

1.“Сыйфат” темасы буенча белемнәрне системалаштыру, гомумиләштерү. Сыйфатларның сөйләмдә кулланылышын активлаштыру.

2. Укучыларны чагыштырырга, нәтиҗә ясарга өйрәтү, төркемнәрдә эшли белү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

3. Татар теленә, туган якка мәхәббәт тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Компьютер, интерактив такта, перфокарталар, кроссворд, текстлар.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

– Исәнмесез, хөрмәтле татар телен яратучылар! Без бүген йомгаклау утырышына җыелдык. Без ике төркемгә бүленеп эшләрбез. Һәрбер төркемнән бер укучы актив катнашучыларны исәпкә алып барыр. Җиңүчеләребезгә бүләкләребез

булыр. Көн тәртибендә түбәндәге мәсьәләләрне ачыкларбыз.

1. Сыйфатның нинди сүз төркеме булуын ачыклау.
2. Сыйфат дәрәҗәләрен күрсәтү.
3. Сыйфатларның төзелешен билгеләү.
4. Синоним һәм атоним сыйфатларны табу.
5. Сыйфатларның сөйләмдәге ролен ачыклау.
6. Йомгаклау.

Көн тәртибе буенча сорауларыгыз юкмы? Көн тәртибен раслыйбыз (*клуб әгъзалары кулларын күтәреп, көн тәртибен раслыйлар*).

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**

– Беренче көн тәртибе буенча, сыйфатның нинди сүз төркеме булуын ачыклыйк. Моның өчен әңгәмә корып алабыз. Әңгәмә өчен сораулар:

1.Сыйфат нәрсәне белдерә? Мисаллар белән дәлилләгез.
2.Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?
3.Сыйфат җөмләдә нәрсә булып килә?
4.Сыйфатны ачыклап килгән исем ничек атала?
5.Сыйфатның ничә дәрәҗәсе бар?
6.Сыйфатлар төзелеше ягыннан нинди төркемнәргә бүленә?

(*Җаваплар тыңланыла. Дөрес җавапны әйткән саен, тактада бер хәреф ачыла бара һәм "Сыйфат" сүзе килеп чыга.*).

**III. Белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру.**

**1. Перфокарталар буенча эш.**

– Икенче көн тәртибе буенча, сыйфат дәрәҗәләренә киңрәк тукталабыз. Бирелгән сүзләрне перфокарталарда дөрес итеп билгеләгез (*төркемнәргә карточкалар бирелә*).

1 нче карточка. Нәфис, ак, саргылт, матуррак, яшькелт, сусыл, акыллы, иң яхшы, зәңгәрсу, чип-чиста.

2 нче карточка. Күксел, иң биек, әчкелтем, җып-җылы, тирәнрәк, күңелсез, тырыш, карасу, түгәрәк, юеш.

(*Ике төркем эшләрен бетергәч, бер-берсе белән перфокарталарын алышалар. Интерактив тактада бирелгән җавалар буенча эшләрен тикшерәләр*).

**Җаваплар:**

1нче перфокарта.

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гади дәрәҗә | х | х | | | | | х | | | |
| Чагыштыру дәрәҗәсе | | | | х | | | | | | |
| Артыклык дәрәҗәсе | | | | | | | | х | | х |
| Кимлек дәрәҗәсе | | | х | | х | х | | | х | |

2 нче перфокарта.

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гади дәрәҗә | | | | | | х | х | | х | х |
| Чагыштыру дәрәҗәсе | | | | | х | | | | | |
| Артыклык дәрәҗәсе | | х | | х | | | | | | |
| Кимлек дәрәҗәсе | х | | х | | | | | х | | |

– Ә хәзер төркемнәрдән берәр укучы такта янына чыга.

*Бирем.* Бирелгән сыйфатларны төрле дәрәҗәдә язарга кирәк.

Кызыл – кызылрак, кып-кызыл, кызгылт.

Тәмле – тәмлерәк, бик тәмле.

Зур – ...

Җылы – ...

Сирәк – ...

Ал – ...

*(Бу эшләрдән соң укучылар нәтиҗә чыгаралар. Гади дәрәҗәдәге сыйфатлардан ничек башка дәрәҗәдәге сыйфат ясалуын дәлилләп аңлаталар, асыл сыйфатларның гына төрле дәрәҗәдә килүе әйтелә. Бәяләү*).

2. Кроссворд чишү. Сыйфатларның төзелешен ачыклау.

(*Укытучы сыйфатлар әйтә укучылар сүзнең төзелешен ачыклап, кроссворд шакмакларын тутыралар*).

Батыр. 2. Белемле. 3. Зифа буйлы. 4. Искиткеч. 5. Аллы-гөлле.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Т | А | М | Ы | Р | | |
| Я | С | А | Л | М | А | |
| | | Т | Е | З | М | Ә |
| | К | У | Ш | М | А | |
| П | А | Р | Л | Ы | | |

*(Нәтиҗә чыгару. Белемнәрне бәяләү).*

**3. Физкультминут**.

**4. Синоним һәм антоним сыйфатларны билгеләү.**

1 нче төркемгә бирем.

Сыйфатларның синоним парларын языгыз.

Матур, эшчән, түземле, зур, эссе, чиста, яхшы, сәламәт, арзан. **Сайлап алу өчен сүзләр:** уңган, сабыр, күркәм, дәү, таза, кызу, шәп, әйбәт, юнь, сылу, очсыз, кайнар, өлкән, олы, саф, ару.

2 нче төркемгә бирем.

Сыйфатларның антоним парларын языгыз.

Тырыш, куркак, файдалы, йомшак, ямьсез, яхшы, салкын, сирәк, җиңел, тирән. **Сайлап алу өчен сүзләр:** каты, ялкау, матур, начар, җылы, сай, авыр, еш, батыр, зарарлы.

(*Белемнәрне бәяләү*).

**5. Сыйфатларның сөйләмдәге ролен ачыклау.**

*(Төркемнәргә текст язылган карточкалар бирелә. Укучылар текстка сыйфатлар өстәп язалар. Укчылар текстларны чагыштырып, нәтиҗә ясыйлар. Төркем җитәкчеләре белемнәрне бәялиләр).*

Туган ягыма кыш килде.

... көз китүгә, таягына таянып, ... кыш кунакка килде. Ул ... җир өстенә ... кар яудыра башлады. ... кар бөртекләре, җемелдәшеп, ... җиргә коелдылар. Җир өсте ... юрган ябынды. Елгалар, күлләр ... боз белән капланды. ... каеннар Кар кызлары кебек басып торалар.

Ял көнне без, чаңгылар киеп, ... урманга киттек. ... урман бик тын. ...кошлар сайрамый. ... карда җәнлек эзләре күренә. ... табигать бик матур.

**IV. Йомгаклау.**

– Утырышыбызның соңгы көн тәртибенә җиттек. Утырыш карарын чыгарабыз.

Утырыш карары:

1.Сыйфат предметның төсен, тәмен, исен, тышкы кыяфәтен, формасын, күләм-үлчәмен, кешеләргә характерлы сыйфатларны белдерә.

2.Сыйфатлар 4 дәрәҗәгә ия булалар: гади дәрәҗә, чагыштыру дәрәҗәсе, артыклык дәрәҗәсе, кимлек дәрәҗәсе.

3.Сыйфатлар төзелешләре буенча тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә була.

4.Сөйләмдә төрле сыйфатларны уңышлы куллану фикерне ачык аңлатып бирүгә ярдәм итә, сөйләмне матурлый.

(*Клуб әгъзалары карарны кул күтәреп раслыйлар*).

**V. Билгеләр кую. Җиңүчеләргә бүләкләр тапшыру.**

**VI. Өй эше бирү.** Әдәби әсәрдән өзек күчереп алырга, өзектәге сыйфатлар белән сыйфатланмышларның астына сызарга. Әсәрнең авторын, исемен күрсәтергә.

### 1.2.2. АРАЛАШУГА ӨЙРӘТҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

Аралашуга өйрәтү технологиясе, ягъни коммуникатив технология А.С.Пушкин исемендәге Мәскәү лингвистика институты (М.Н. Вятютнев, А.А. Леонтьев, В.Г. Костомаров, О.Д. Митрофанова һ.б.), Липецкидагы чит ил культурасына коммуникатив методика нигезендә укыту үзәге (Е.И.Пассов, В.П. Кузовлев, В.Б. Царьков) хезмәтләренә нигезләнә.

Аралашуга өйрәтү технологиясе буенча оештырылган дәресләрдә күнегүләр системасы аралашуга корылган булырга тиеш. Е.И.Пассов ике төр күнегүне аерып күрсәтә: шартлы тел күнегүләре һәм тел күнегүләре. Шартлы тел күнегүләре күнекмәләр үстерү максатыннан махсус оештырыла. Бу күнегүләр бер типтагы лексик берәмлекләрнең кабатлануына нигезләнә. Тел күнегүләре аша лексика һәм грамматиканы күпләп өйрәнү мөмкинлеге тормышка ашырыла. Күнегүләр эшләү барышында хаталарны төзәтү эше дә оештырыла. Фонетик хаталарны төзәтү максатыннан һәр дәрестә фонетик күнегүләр планлаштырыла. Татар теленә генә хас булган нинди дә булса аваз алына һәм 1-2 атна дәвамында шул авазны дөрес әйтү өстендә күнегүләр эшләнелә. Ә грамматик хаталарны төзәтүгә барлык укучыларның игътибарын тарту мөһим, ләкин кагыйдәләрне аңлату озакка сузылырга тиеш түгел.

Коммуникатив технологиянең өстенлеге укыту процессында сөйләм материалын барлык балаларның да үзләштерә алуы өчен шартлар булдыруда. Коммуниктив технология нигезендә укыту цикллылыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның

эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик катлаулылыгына, текстның күләменә бәйле.

Методик әдәбиятта күрсәтелгәнчә, текстны өйрәнү өч этаптан тора: текст алды, текст өстендә эшләү этабы, тексттан соңгы этап. Беренче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнәләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр – лексик күнекмәләр һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛКФ, ГКФ). Бу дәресләрнең эчтәлеге турыдан-туры текст эчтәлеге белән бәйле.

Укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнгәч, текстның үзен укуга күчәргә мөмкин. Бу дәрестә текстны уку, текст өстендә эшләү буенча күнегүләр системасы өстенлек итә. Дәрес тибы буенча бу дәресләр – лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре (ЛГКК, ЛКК, ГКК).

Тексттан соңгы этапта текст буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу, ягъни диалогик-монологик сөйләм үстерү дәресләре оештырыла.

Коммуникатив метод лексик берәмлекләрне һәм аларның грамматик формаларын билгеле бер ситуацияләргә бәйләп өйрәтүне таләп итә. чынбарлыкта кешеләр, аралашу сферасыннан чыгып, бер-берсе белән хәбәрләшәләр һәм моның өчен кирәкле тел берәмлекләреннән файдаланалар. Шуңа күрә дә икенче телне өйрәнгәндә, аралашу ситуацияләренә бәйле репликаларны истә калдыру телне гамәли үзләштерүне җиңеләйтә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыра. Татар теле дәресләрендә төрле кызыклы ситуацияләр куллану һәм аларга нигезләнеп, укучыларның аралашу осталыгын үстерүгә игътибарны арттыру мөһим. Аралашу ситуацияләреннән чыгып, укучылар төрле социаль рольләрне башкарырга һәм кирәкле репликаларны дөрес кулланырга күнегә алалар. Мәсәлән, исәнләшү, сораштыру, тәкъдим итү, ризалашу, риза булмау, гаҗәпләнү, шикләнү һ.б.

**Коммуникатив биремнәр**

1.К тебе пришел твой друг. Как ты представишь его своим родителям?

– Әти, әни! Бу минем иң якын дустым Артур!

Ты уезжаешь к своим друзьям в деревню, как ты об этом сообщишь бабушке?

– Әбием, мин авылга үземнең дусларым янына китәм.

Сегодня в школе состоится концерт. Уточни у Саши, будет ли он участвовать.

– Саша, син бүген мәктәптә буласы концертта катнашасыңмы?

Вы пришли на осенний бал. Сделай комплимент подруге о том, что у нее красивое платье.

– Дустым Алия, синең күлмәгең шундый матур!

Сегодня был открытый урок по литературе в 5 Б классе. Поинтересуйся, как звали мальчика, который выразительно читал стихи.

– Бүген дәрестә шигырьне сәнгатьле укучы малайның исеме ничек?

На уроке биологии вы получили советы по правильному питанию. Сообщи подруге, что по утрам до еды нужно пить стакан воды.

– Дустым, иртәнге ашка кадәр бер стакан су эчәргә кирәк.

Ты занимаешься легкой атлетикой. Сообщи классному руководителю о том, что завтра тебе нужно ехать на соревнование.

– Венера Хәсәновна, миңа иртәгә ярышка китәргә кирәк.

2. Спроси у друга о том,

– пойдет ли он сегодня в городскую библиотеку;

– какую книгу он читал на каникулах;

– пригласит ли он друзей на день рождения;

– как он собирается провести выходные;

– как он готовиться к экзаменам;

–в каком учебном заведении учится его сестра;

– какие спортивные мероприятия проводятся в городе

Сообщи о том,

– что завтра будет родительское собрание;

– что вы вчера ходили в кино;
– что они были в гостях;
– что завтра в городе будет кросс;
– что ученики 10 класса хорошо провели праздник;
– что вам нравится этот урок;
– что сегодня у тебя день рождения;
– что вчера из Казани приехала твоя сестра;
– что на каникулах вы уедете в деревню;
– что природу нужно беречь, так как она дает нам пищу, одежду;
– что каждый человек должен позаботиться о своем здоровье.

Посоветуй подруге,
– чтобы она не опаздывала на урок;
– чтобы она прочитала книги татарских пистелей;
– чтобы она сходила в музей;
– тобы она каждый день готовилась к урокам.

Поинтересуйся у друга:
– как у него дела;
– будет ли он участвовать в соревнованиях;
–интересна ли эта книга;
– нравится ли ему волшебные сказки;
– какой фильм идет в кинотеатре;
– куда он собирается поступить после окончания школы;

Предложи подруге:
– бегать по утрам;
–пойти в лес;
– поиграть в лото;
– сходить в кукольный театр.

Узнай у друга:
– где находится аптека;
– когда он придет к тебе;
– выписывают ли они газеты-журналы;
– почему он отсутствовал сегодня на уроке;
– понравилось ли ему в городском музее.

Убеди друга:
– пойти с тобой на дискотеку;

– слушать музыку;
– вместе сделать уроки;
– поехать летом в деревню.

Аралашуга корылган дәресләрдә коммуникатив уеннар куллану да отышлы. Уйнаганда балалар үзләре хыялланган күз алдына китергән хәлләрне, вакыйгаларны җанландыра. Коммуникатив уеннар текстны рольләргә бүлеп уку яки хикәяне сәхнәләштерү генә түгел, ә проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү һәм аларны чишү дә. Коммуникатив уеннарны оештыру өчен башта укытучы балаларның нәрсә белән кызыксынуын, яшь үзенчәлекләрен, уйнау сәләтләрен өйрәнергә тиеш. Уен вакытында бер бала да белем алам дип уйламый. Коммуникатив уеннар өйрәнелгән лексиканы, грамматиканы төрле шартларда гамәли куллану мөмкинлеген арттыра. Мондый уеннарның тәрбияви әһәмияте дә зур: укучыларда игътибарлылык, ярдәмчеллек сыйфатлары, үз уңышларына шатлану хисе тәрбияләнә.

**Коммуникатив уеннар “Парыңны тап” уены**

1. Уен башланыр алдыннан һәр укучы нинди дә булса мәгълүматның бер өлеше язылган карточкалар ала һәм икенче өлешен (ягъни үзенең парын) табарга тиеш була. Мондый уеннарны җөмләләр, диалоглар, хикәяләр төзегәндә актив кулланырга мөмкин.

2. Төркемдә һәр укучының пары бар, ләкин парлар билгеле түгел. Һәр укучы бер-берсенә сораулар биреп парын табарга тиеш. Укытучы уенда катнашучыларга, билгеле бер вакытта сәяхәткә җыенырга тәкъдим итә. Моның өчен билгеле бер шартларны үтәргә кирәк. Катнашучыларның бурычы – үзеңә юлдаш табу. Шул максаттан чыгып, һәр укучы бер-берсе янына киләләр һәм бергә сәяхәткә чыгарга тәкъдим ясыйлар, аларның планнарын сораштыралар, үзләренең сәяхәт шартлары белән таныштыралар. Уенчылар үзләренең парларын тапканчы, шулай бер-берсе белән аралашалар.

3. Уенга катнашучылар икешәр карточка алалар. Беренче карточкага кызыксыну өлкәсе, гадәтләр, ә икенчесенә – тапшыраласы бүләк исеме языла. Бүләк дөрес тапшырылсын өчен, бер-береңнең гадәтен, нәрсә белән кызыксынуын яхшырак белергә

кирәк. Моны үзара аралашу вакытында гына ачыкларга мөмкин.

*“Интервью алу”.* Интервью уздыру өчен иң мөһиме сораулар төзергә кирәк, аны таблица, схема формасында да тәкъдим итәргә мөмкин.

1. Иң башта интервью алына торган кеше турында барлык мәгълүматны белергә кирәк.

2. Кем? Нәрсә? Кайда? Кайчан? Ни өчен? Ничек? кебек сораулар кулланылырга тиеш. “Әйе”, “юк” кебек җавап бирә торган сораулар кулланылмасын.

3. Сорауларны әзерләгәндә, тыңлаучыларның фикерләрен дә исәпкә алырга кирәк.

4. Әгәр әңгәмәдәшең сорауны аңламаса, сораууга ачыклык кертелә.

5. Соңгы сорау йомгаклау характерында булырга тиеш. Иң соңыннан әңгәмәдәшеңнең тыңлаучыларга нәрсә әйтергә теләвен ачыкларга кирәк. Сораштыруны түбәндәгечә оештырырга мөмкин:

4-5 укучы такта янына чыга, сораууга җавапны алар, акбур ярдәмендә рәсем ясап, тактага төшерергә тиеш булалар. Башка уенчылар да үзләренең рәсемнәрен төшерәләр. Аннан соң төркемнәргә берләшеп, нинди ситуациядә үзләрен ничек тотулары турында әңгәмә коралар.

**Диалог төзү өчен схемалар**

| Схемалар | Диалог үрнәкләре |
|---|---|
| – сорау;<br>– җавап. | – Сез музейларда булдыгызмы?<br>– Әйе, без шәһәр музейларында булдык. |
| – сорау;<br>– каршы сорау;<br>– җавап. | – Синең дустыңның исеме ничек?<br>– Кайсы дустымның?<br>– Иң якын дустыңның. |
| – чакыру;<br>– ризасызлык белдерү. | – Әйдә, Алсу, урманга гөмбәгә барыйк әле!<br>– Юк, бара алмыйм. Иртәгә абыем Мәскәүдән кайта. |
| – чакыру;<br>– ризасызлык белдерү;<br>– үгетләү, ышандыру:<br>– килешү. | – Әйдә Чыршы бәйрәменә барабыз!<br>– Юк, бармыйм, вакытым юк.<br>– Анда кызык булачак, яңа тамаша куялар!<br>– Ярый, барырга тырышырмын. |

| | |
|---|---|
| – хәбәр итү;<br>– раслау. | – Айрат, бүген дәрестән соң чаңгы ярышлары булачак!<br>– Әйе, дустым, беләм, белдерүне укыдым. |
| – сорау (үтенү);<br>– ризалык белдерү. | – Әлфия, зинһар өчен, математикадан мәсьәлә чишәргә булыш әле.<br>– Ярый, бик теләп булышам. |
| – чакыру;<br>– рәхмәт белдерү, килешү | – Дустым, мин сине Туган көн бәйрәменә чакырам.<br>– Рәхмәт, мин риза, килермен. |
| – тәкъдим;<br>– килешү, каршы тәкъдим. | – Руслан, рус теленнән дәресләрне бергә әзерлик әле.<br>– Ярый. Караңгы төшкәнче, шугалакта шуып килик, аннан соң дәрес әзерләрбез. |
| – сәламләү;<br>– каршы сәламләү;<br>– сорау;<br>– җавап. | – Исәнме, Рузана!<br>– Хәерле көн, Марат!<br>– Син кая ашыгасың?<br>– Кибеткә яңа татар китаплары алып кайтканнар. |

### Коммуникатив технологиягә нигезләнеп төзелгән дәрес үрнәкләре

Коммуниктив технология нигезендә укыту цикллылыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Мәсәлән, Г.К. Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” текстын өйрәнү тематик планда түбәндәгечә күрсәтелә.

| | Дәреснең темасы | Предмет | Дәрес тибы | Лексика | Грамматика | Укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” әкияте.<br>Яңа лексиканы өйрәнү. | Татар теле | Лексик күнекмәләр формалаштыру | Томшык<br>Сукмак<br>Җан ияләре<br>Кадак<br>Кәүсә<br>Кага | Хәл фигыль | Тәржемә эше. |
| 2. | Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” әкияте.<br>Күнегүләр эшләү. | Татар теле | Лексик-грамматик күнекмәләр формалаштыру | Тукыл<br>дый<br>Күбәй<br>гән | Хәл фигыль | План төзү.<br>Әкият эчтәлеге буенча рәсем ясау. |
| 3-4 | Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” әкияте.<br>Сөйләмгә чыгу.<br>(2 дәрес) | Әдәбият | Сөйләм телен үстерү | Яшәргән<br>Купшы<br>ланган | | Сүзлек диктанты.<br>Диалог төзү.<br>Сәхнәләштерү.<br>Альбом төзү. |

## Шәфкать һәм Тукран

Борын-борын заманда түгел, ә безнең көннәрдә, ерак-ерак җирләрдә түгел, ә безнең арабызда яшәгән ди, булган ди Шәфкать исемле малай.

Аның исеме генә түгел, ә йөрәге дә шәфкатьле булган. Якын-тирәдәге барлык җан ияләре дә аны яратканнар. Өйсез этләр һәм песиләр малайны күргәч, шатлыктан койрыкларын болгый башлаганнар, карт кешеләр яратып “оныгыбыз” дип йөрткәннәр.

Шәфкать һәркемгә дә кирәк вакытта җылы сүзен әйткән, кирәк вакытта ярдәм кулын сузган. Ул урман җәнлекләрен дә онытмаган, алар янына еш барып йөргән хәлләрен белгән. Бигрәк тә кышкы салкыннарда ярдәм итәргә тырышкан.

Беркөнне Шәфкать таныш сукмак буенча тагын урманга киткән. Барып җитсә, ни күрсен: юл читендә аны Тукран көтеп утыра икән.

– Исәнме, Тукран. Нигә монда утырасың, нигә тукылдамыйсың? Әллә урманда сиңа эш беттеме? – дип сораган малай.

– Эш бетмәде, ләкин минем хәлләр яхшы түгел, шуңа күрә сине көтеп утырам. Кемдер каен кәүсәсенә кадаклар кагып киткән. Көн саен каен җилдә елый да елый. Мин аңа ярдәм итәргә уйладым: томшыгым белән шул кадакларны берсе артыннан икенчесен тартып чыгара башладым. Ләкин кадаклар бик зур иде, минем томшыгым чатнады. Хәзер ул бик авырта һәм мин эшли алмыйм. Урманда көннән-көн зарарлы бөҗәкләр күбәя, ә мин агачларга берничек тә ярдәм итә алмыйм.

– Кайгырма, Тукран. Күрше авылда Тимерче яши, сиңа ярдәм итсә, ул гына ярдәм итәр. Әйдә, хәзер үк шунда барабыз, – дигән Шәфкать.

Тимерче Тукранның томшыгын элеккесеннән дә яхшырак итеп ясаган. Шул көннән башлап, урманда яңадан көне буе “тук” та “тук” Тукран тавышы ишетелә башлаган. Урман көннән-көн яшәргән, яшелләнгән, купшыланган.

Монда җиләкләр гөмбәләр һәм матур чәчәкләр күбәйгән. Тиздән бу урманда Тукранга эш тә беткән. Ул күрше урманга ярдәм итәргә очып киткән.

## 1 НЧЕ ДӘРЕС

**Дәреснең темасы:** Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” әкияте. Яңа лексиканы өйрәнү.

**Дәреснең тибы:** Лексик күнекмәләр формалаштыру.

**Максат:** 1. *Шәфкатьле, җан ияләре, томшык, сукмак, йөрәк, кәүсә, кадак, чатный, купшыланган, яшәргән, тукылдый, күбәя* сүзләрен өйрәнү.

2. Татар теленә генә хас авазларны дөрес язу һәм уку күнекмәләрен үстерү, хәл фигыльне (*-ып,-еп,-п,-гач,-гәч,-кач,-кәч* формаларын) сөйләмдә ныгыту.

3. Табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү, аңа карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Рәсемнәр, урман сурәтләнгән картина, “Фигыль төркемчәләре” таблицасы.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

– Исәнмесез! Хәерле көн!

**II. Тел күнегүләре.**

– Бүген ничәнче число?

– Атнаның нинди көне?

– Татар теле ничәнче дәрес?

– Хәзер кайсы ел вакыты?

– Көз җиткәч, табигать нинди? *һ. б. шундый сораулар бирелә, эчтәлегендә хәл фигыль булган ситутив күнегүләр эшләнелә.*

– Сообщи другу, когда наступает осень, птицы улетают на юг.

– Спроси у Оли, что она делала вчера, сделав уроки.

– Узнай у подруги, сегодня, выйдя на улицу, кого он увидел?

**III. Өй эшен тикшерү** (*хәл фигыль кулланып төзелгән сорау җөмләләрне уку*).

**IV. Яңа тема өйрәнү.**

(*Укучыларга дәреснең максатын җиткерү, эш барышын аңлату, тактада бирелгән яңа сүзләр белән танышу, өйрәнү. Сүзләрне башта укытучы укый. Аннан соң укучылар белән укып, дөрес әйтелеш өстендә эшлиләр*).

Тактада түбәндәге сүзләр бирелгән:
Тукран [тукъран]
Томшык [томшокъ]
Тукылда [тукъылда]
Сукмак [сукъмакъ]
Җан ияләре [җаᵒнийәләрэ]
Кадак [къаᵒдакъ]
Кага [къаᵒга]
Кәүсә [кәwсә]
Купшыланган [къупшылангъан]
Күбәйгән [күбәйгән]
Яшәргән [йәшәргән]

(*Һәрбер сүз аерым өйрәнелә, төрле ысуллар ярдәмендә яңа лексика тәкъдим ителә, белемнәрне беренчел ныгыту өчен күнегүләр эшләнелә*).

**Тукран.**

Укытучы (*тукран рәсемен күрсәтеп*). Тукран – файдалы кош. Бу җөмләне русчага тәрҗемә итегез әле.

Укучылар. Дятел – полезная птица.

Укытучы. *Дятел* татарча *тукран (укучылар бу сүзне берничә тапкыр кабатлыйлар).* Сүзтезмәләр төзибез.(*укучылар сүзтезмәләр төзиләр*: матур тукран, зур тукран, кечкенә тукран, чуар тукран, файдалы тукран һ.б.). Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзибез (*Укучылар сүзтезмәләр белән җөмләләр төзиләр:* Урманда зур тукраннар яши. Файдалы тукран урманны саклый.*)*

Коммуникатив биремнәр.

Алена, спроси у Артура, дятел какая птица *(Артур, тукран нинди кош?)*

Собщите друзьям, что полезный дятел живет в лесу *(Дусларым, урманда файдалы тукран яши.)*

**Томшык.**

Укытучы. Тукранның томшыгы озын (*укытучы кошның томшыгына күрсәтә, укучылар* томшык *сүзенең русчасын (клюв) әйтәләр).* Тәрҗемә итегез: длинный клюв (озын томшык), его клюв (аның томшыгы), клюв птицы (кошның томшыгы), длинный клюв птицы (кошның озын томшыгы). Сүзтезмәләр белән

җөмләләр уйлагыз.

Укучылар.Кошның томшыгы озын. Кошның озын томшыгы бик уңайлы. Тукран озын томшыгы белән кортлар җыя.

**Тукылда.**

Укытучы (*рәсемгә күрсәтеп*). Тукран агачта тукылдый. Тукран нишли?

Укучылар. Дятел стучит. Стучит – тукылдый.

Укытучы. Тукран ничек тукылдый?

Укучылар. Тукран еш тукылдый. Тукран каты тукылдый. Тукран озак тукылдый.

Укытучы. Тукран кайда тукылдый?

Укучылар.Тукран урманда тукылдый. Тукран агачта тукылдый.

Укытучы. Тукылда фигыленнән хәл фигыль ясыйк, җөмләләр төзик.

Укучылар. Тукылда – тукылдап, тукылдагач.

Коммуникатив биремнәр.

Сообщи друзьям о том, что дятел стучит, и собирает вредных насекомых. (Тукран тукылдап, зарарлы кортларны җыя).

Сообщи друзьям о том, когда дятел стучит, в лесу весело. (Тукран тукылдагач, урманда күңелле).

*(Башка сүзләр дә шул рәвешле өйрәнелә, сүзләр сүзлек дәфтәренә язылa).*

**V. Ял итү.**

**VI. Белемнәрне ныгыту.**

**Аудирование** *(Укытучы текстны 2 тапкыр укый, укучылар сорауларга җавап бирәләр)*

Җәй җиткәч, без урманга киттек. Җәйге урман искиткеч матур. Ул яшелләнгән, купшыланган. Урманда бик күп җан ияләре яши. Төз каеннар үсеп утыра. Аларның кәүсәләре ап-ак.

Менә урман сукмагы. Биек агачта тукран тукылдый. Әнә куркак куян йөгереп үтте. Урманда шундый күңелле! Аны сакларга кирәк. Урман – кыргый җан ияләренең туган йорты.

**Текст буенча сораулар.** 1. Текстта сүз нәрсә турында барды? 2. Урманда нәрсәләр яши? Урман нәрсәләрнең туган йорты? Безнең якта нинди урманнар бар?

**Ситуатив күнегүләр.**

– Вы в лесу. Вам здесь хорошо. Сообщите об этом друзьям.

– Дусларым, җәйге урманда шундый рәхәт!

– Сообщи о том, что ежик лежит на тропинке.

– Керпе сукмакта ята.

– Позови подругу посмотреть ежика.

– Рузана, сукмакта керпе ята, карарга кил!

– Скажи другу, что белоствольные березы очень красивые.

– Марат, ак кәүсәле каеннар бик матур!

**VII. Йомгаклау. Кире информация.**

1. “Мин-тәрҗемәче” уенын уйнау *(беренче төркемдәге укучылар бу дәрестә өйрәнелгән сүзләрне әйтә, ә икенче төркем укучылары сүзнең дөрес тәрҗемәсен әйтергә тиеш, шул рәвешле өйрәнелгән сүзләр тагын бер тапкыр хәтердә яңартыла)*.

2. Рәсемнәр буенча сораулар бирү.

– Бу нинди кош? Тукран нишли? Ул кайда тукылдый? Тукран ничек тукылдый? Урман сукмагы нинди? Урманда нәрсәләр яши? Урманда нинди агачлар үсә? Каен кәүсәсе нинди төстә? Урман язын нишли? һ.б.

**VIII. Билге кую. Өй эше бирү** (*өйрәнелгән сүзләрне ятларга, “Кошларга ярдәм кирәк” дигән темага диалог төзергә*).

## 2 НЧЕ ДӘРЕС

**Дәреснең темасы:** Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” тексты өстендә эш. Күнегүләр эшләү.

**Дәреснең тибы:** Лексик-грамматик күнекмәләр камилләштерү.

**Максат:**

1.Өйрәнелгән лексиканы, хәл фигыльне (*-ып,-еп,-п,-гач,-гәч,-кач,-кәч* формаларын) сөйләмдә активлаштыру.

2. Укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен, төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү.

3. Табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү, аңа карата сакчыл караш тәрбияләү, кешелеклелек, шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Биремле карточкалар, рәсемнәр, урман сурәтләнгән картина, “Фигыль төркемчәләре” таблицасы.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

**II. Тел күнегүләре** (сорауларга җавап бирү, төрле ситуатив күнегүләр эшләү).

**III. Өй эшен тикшерү.**

**IV. Белемнәрне актуальлаштерү.**

(*Укучыларга дәреснең максатын җиткерү, эш барышы белән таныштыру*).

**Тәрҗемә эше.**

**Т-Р** (*татарчадан русчага тәрҗемә*).

Ярдәм ит, ярдәм итәргә, ярдәм итәргә уйладык, ярдәм кулы, ярдәм кулын сузган; барып җиттеләр, барып җиттеләрме? барып җиткәннәрме? эшли башлар, эшли башлады, еш барып йөргән, көтеп утыра.

**Р-Т** (*русчадан татарчага тәрҗемә*).

Среди нас, недалеко от нас, милосердие, милосердный, живые существа, бездомные собаки и кошки, старался помочь, увидев мальчика, забить гвозди, клюв раскололся, слышится стук дятла, лес помолодел, позеленел; соседний лес, полетел соседний лес.

**V. Текст өстендә эш.**

**Текстны уку.**

1. Укытучы текстны укый.
2. Аңлашылмаган сүзләр өстендә эш.
3. Укучылар текстны укыйлар (*текстны укыр алдыннан сорау бирелә. Мәсәлән: Әсәрдә нинди геройлар бар?*)
4. Рольләргә бүлеп уку.

**Абзацларга исем кушу.**

1. Шәфкатьле Шәфкать
2. Урманда булган хәл.
3. Тукранның яхшылыгы.
4. Тимерченең ярдәме.

**Төп фикерне белдерүче җөмләләрне язып алу.**

1. Шәфкать һәркемгә дә кирәк вакытта җылы сүзен әйткән, кирәк вакытта ярдәм кулын сузган.
2. Кемдер каен кәүсәсенә кадаклар кагып киткән.
3. Мин аңа ярдәм итәргә уйладым: томшыгым белән шул

кадакларны берсе артыннан икенчесен тартып чыгара башладым. Ләкин кадаклар бик зур иде, минем томшыгым чатнады.

4. Тимерче Тукранның томшыгын элеккесеннән дә яхшырак итеп ясаган.

**Текстан хәл фигыльләрне табу, алар белән җөмләләр төзү.**

Күргәч, яратып, барып, көтеп, кагып, тартып, башлап, очып.

Мәсәлән: Дусларымны күргәч, мин бик шатландым. Күптән көтеп алган бәйрәм җитте.

**VI. Ял итү.**

**VII. Төркемнәрдә эш.**

**Җөмләләрне сюжет эзлеклелегендә урнаштырырга** (*текстtан 10 җөмлә алына, укучылар бу җөмләләрне сюжет эзлеклелегендә урнаштырырга тиеш, эшнең дөреслеге тактада бирелгән җавап буенча тикшерелә*).

**Бирелгән җөмләләрдәге фикерләр белән килешәсезме?**

**1 нче карточка.**

1. Якын-тирәдәге җан ияләре Шәфкатьне яратканнар.
2. Тукран каен агачына булышкан.
3. Тимерче Тукранга булышмаган.

**2 нче карточка.**

1. Өйсез этләр һәм песиләр малайны күреп качканнар.
2. Малай урманда Тукранны очратмаган.
3. Каен көн дә җилдә елый да елый икән.

**3 нче карточка.**

1. Шәфкать урман җәнлекләрен онытмаган.
2. Тукран каенга булышмаган.
3. Урманда бөҗәкләр күбәйгән.

**VIII. Йомгаклау. Билге кую.**

**IX. Өй эше бирү.**

1. Текстка план төзергә.
2. Азацлар эчтәлеге буенча рәсем ясарга.

## 3 НЧЕ ДӘРЕС

**Дәреснең темасы:** Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран”тексты. Сөйләмгә чыгу.

**Дәреснең тибы:** Сөйләм телен үстерү.

**Максат:**

1. Өйрәнелгән лексиканы, хәл фигыльне (*ып,-еп,-п,-гач,-гәч,-кач,-кәч* формаларын) сөйләмдә активлаштыру.

2. Бирелгән информация аша укучыларның сөйләм телен, мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү.

3. Табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү, аңа карата сакчыл караш тәрбияләү, кешелеклелек, шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Кош рәсемнәре, урман сурәтләнгән картина, “Фигыль төркемчәләре” таблицасы, мәкальләр язылган плакатлар.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.**

**II. Тел күнегүләре.**

**III. Сүзлек диктанты (***укучылар сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең тәрҗемәсен язалар, җаваплар буенча үзара тикшерү оештырыла*).

Его клюв, большой клюв, клюв раскололся, лесная тропинка, часто стучит, полезный дятел, ствола березы, помолодел, позеленел, ждал сидя, забил гвозди, увидев, твое сердце, живые существа.

**IV. Белемнәрне актуальләштерү.**

(*Укчыларга дәреснең максатын җиткерү, эш барышы белән таныштыру*).

**Рәсемнәр әкиятнең кайсы өлешенә туры килә?**

(*Тактага әкиятнең эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр эленә, укучылар рәсемнәр буенча эшлиләр*)

**Сорауларга җавап бирү.**

– Шәфкать нинди малай? Ни өчен? Ул кемнәргә ярдәм иткән? Әсәрдә тагын кем шәфкатьле? Ни өчен? Сез тагын нинди файдалы кошларны беләсез?

(*Рәсемнәр буенча кошларны тану, безнең якта кышлаучы кошларны билгеләү оештырыла).* Каен ни өчен елый? Кем агачка кадак кагып киткән? Ул нинди кеше? Бу әкияттә тагын бер шәфкатьле кеше бар. Ул кем? Нинди кешеләр бер-берсенә булышалар? Нәрсә ул дуслык? Сез аны ничек аңлыйсыз?

**Төркемнәрдә эш.**

1. Нәрсә ул дуслык? Дуслыкның нинди төрләрен беләсез? (*Мәсәлән: халыклар дуслыгы, малай белән кыз дуслыгы, ...*)

2. Дусларың күп булсын өчен нинди булырга кирәк? (*шәфкатьле игътибарлы, киң күңелле ...*)

3. Шәфкатьле булу өчен үзеңне ничек тәрбияләргә кирәк? (*китаплар укырга, дусларга булышырга, ...*)

**Хәл фигыльләр кулланып диалоглар төзегез.**

1. Кышкы урманга соклану.
2. Кошларны күзәтү.
3. Кошлар белән сөйләшү.

**Диалог үрнәкләре.**

1. – Ак кар яугач, урман купшыланган.

– Әйе, кояшта кар бөртекләре җем-җем итә.

– Каенның кәүсәсе бигрәк ак күренә.

– Каен, кыш җиткәч, бик матур ак шәл ябынган.

2. –Кара әле, Катя, нинди матур кош! Томшыгы нинди зур!

– Әйе, ул бит тукран. Тукран – бик файдалы кош. Ул бөҗәкләрне ашап, агачларга ярдәм итә.

3. –Тукран дус, кыш салкын булгач, кошларга авырмы?

– Әйе, кошларга азык табуы авыр.

– Ә син азыкны ничек табасың?

– Минем томшыгым зур булгач, агач кәүсәсе эченнән кортларны чүпләргә уңайлы.

**“Шәфкать һәм Тукран” текстын сәхнәләштерү.**

**Бирелгән мәкальләрдән текстка эпиграф сайлау.**

Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

Чын дус-җанлы хәзинә.

Изгелек кешене бизи.

**V. Йомгаклау. Кире информация.**

Сорауларга җавап бирү.

1. Без нинди әкият өйрәндек?
2. Әкияттә нинди геройлар бар?
3. Сезгә кайсы герой күбрәк ошады? Ни өчен?
4. Сез дуслыкны ничек аңлыйсыз? һ.б.

**VI. Өй эше бирү. Билгеләр кую.**

(*Өй эше укучыларның шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып, вариантлап бирелә*).

1. “Урманның шәфкатьле дуслары”дигән темага хикәя язарга.

2. Дуслык турында бер җыр, биш мәкаль күчереп язып алып килергә.

3. Әгәр дә Тукранга Тимерче булышмаса, әкиятнең сюжеты ничек үзгәрер иде? (*Әкиятне үзгәртеп язарга*).

4. Кошлар, аларның файдасы турында кызыклы мәгълүматлар җыярга.

## 4 НЧЕ ДӘРЕС

**Дәреснең темасы:** “Кошлар безнең дусларыбыз”. Г.Егорованың “Шәфкать һәм Тукран” тексты буенча сөйләм телен үстерү дәресе.

**Дәреснең тибы:** Сөйләм телен үстерү.

**Максат:**

1. Өйрәнелгән текстка нигезләнеп, укучыларның сөйләм телен үстерү, кошлар турында белемнәрен тирәнәйтү.

2.Укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү, фикерләрен дәлилли белергә өйрәтү.

3.Укучыларда игътибарлылык, җаваплылык, кайгыртучанлык, кошларга табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Кош рәсемнәре, урман сурәтләнгән картина, “Фигыль төркемчәләре” таблицасы, мәкальләр язылган плакатлар, магнитофон, компьютер.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше.**

**II. Тел күнегүләре.**

– Укучылар, бездә бүген бик күп кунаклар бар. Кунаклар килгәч, кәефләрегез ничек? Кунаклар сезгә еш киләме? Сез аларны еш каршылыйсызмы? Нәрсәләр пешереп сыйлыйсыз? Безнең дә бүген кунакларыбызга сыйларыбыз күп булыр. Дәресне башлыйбыз. Без бүген табигать, кошлар турында сөйләшербез.

**III. Белемнәрне актуальләштерү.**

**“Кыш” картинасы буенча әңгәмә.**

– Хәзер кайсы ел вакыты? Кыш көне көннәр нинди була? Укучылар, рәсемгә карагыз әле. Бу рәсемдә нәрсә сурәтләнгән? Күк йөзе аязмы, болытлымы? Агачлар нәрсә белән капланган? Урманда нинди агачлар үсә? Рәсемдә нинди җәнлекләрне күрәсез? Урманда кыш көне нинди кошлар яши? Сезнең кышкы урманда булганыгыз бармы? Безнең шәһәребез тирәсендә нинди урманнар бар?

**Өйрәнелгән лексиканы кабатлау.**

– Без сезнең белән нинди кош турында әкият укыдык? Әкият ничек атала?Ә хәзер шул әкиятне искә төшереп алыйк. Дәрес өчен кирәкле булган лексиканы кабатлыйбыз.

**Т-Р** (*татарчадан русчага тәрҗемә*).

Ярдәм ит – ярдәм итәргә – ярдәм итәргә тырыша – ярдәм кулын сузган, барып җиттеләр – барып җиткәннәрме, эшли башлады – эшли башлар – эшли башладымы? еш барып йөргән, көтеп утыра икән, кадаклар кагып киткән.

**Р-Т** *(русчадан татарчага тәрҗемә*).

Среди нас, милосердие – милосердный, живые существа, бездомные собаки и кошки, старался помочь, увидев мальчика, забить гвозди, клюв раскололся, лес помолодел – соседний лес – полетел в соседний лес.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

**Текстка анализ ясау.**

– Әсәрне без ничә өлешкә бүлдек? (*Өч өлешкә бүлдек*).

– Беренче бүлеккә нинди исем бирдек? (*Шәфкать – шәфкатьле малай*).

– Тактада бирелгән сүзтезмәләрне кулланып әкиятнең эчтәлеген сөйлибез. (*Ерак-ерак җирләрдә, безнең арабызда, җан ияләре, койрыкларын болгый башлаганнар, җылы сүз*).

– Икенче бүлекнең исеме ничек? (*Тукран белән очрашу*)

(*Укучылар бу өлешне сәхнәләштереп күрсәтәләр*)

– Өченче бүлек ничек атала? (*Тукранның ярдәме*)

– Тукран кемгә ярдәм иткән?

– Ул ничек ярдәм иткән?

– Әкият ничек тәмамлана?

– Ни өчен әкият “Шәфкать һәм Тукран” дип атала?

– Шәфкать нинди малай? Ни өчен?

– Бу әкияттә тагын кем шәфкатьле?

– Шәфкать белән Тукран дуслармы?

– Тагын кемнәр дуслар? (*Шәфкать – Тукран, Шәфкать – Тимерче, Шәфкать – Тимерче –Тукран, Тукран – урман, Шәфкать – Тукран – урман*)

– Бу әкияттә кем начар?

– Каенга кадаклар кагып киткән кеше начар.

– Укучылар, ә сезнең арада андыйлар юкмы?

– Кошларны яратасызмы? Урманны пычратмыйсызмы? Агачларны сындырмыйсызмы?

– Кыш көне кошларга нинди яхшылыклар эшлисез?

**Әкиятнең үзгәртелгән вариантын уку**. (*Укучылар өйдә язып килгән сочинениеләрен укыйлар*)

**“Син дусларыңны танышсыңмы?”уены.**

– Укучылар, сез кошларның дусларымы?

– Ә сез дусларыгызны таныйсызмы? (*1. Магнитофон язмасыннан укучылар кошлар тавышларын тыңлыйлар һәм нинди кош тавышы икәнен әйтеп баралар. 2. Компьютер экранында “Табигать” бүлегеннән кош рәсемнәре ачыла бара, укучылар кошларның исемнәрен атыйлар*)

**V. “Бу – кызыклы” рубрикасы. (***Укучылар кошлар турында мәкальләр, шигырьләр, кызыклы мәгълүматлар укыйлар, җырлар җырлыйлар*).

**VI. Йомгаклау. Билгеләр кую.**

**VII. Өй эше.** “Кошлар һәм аларның файдасы” яки “Кошлар турында кызыклы мәгълүматлар” дигән альбом төзергә.

## 1.3.УКУ-УКЫТУ ПРОЦЕССЫНДА ИНТЕГРАЛЬЛӘШТЕРҮ

Уку-укыту процессында интегральләштерү – заман таләбе. Уку дәвамында укучы төрле фәннәрдән билгеле бер күләмдә мәгълүмат ала, ләкин һәрвакытта да алган белемнәрен тормышта куллана алмый, килеп туган ситуациядән чыгу юлларын таба алмый. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә төп игътибар белем туплауга бирелә, шәхес тәрбияләү әле белем алу белән генә чикләнми. Укучының дөньяны тулаем күзаллавы, танып белүе

таләп ителә.

Фәннәрне укытуга интеграль якын килү укытучыга бер предмет чикләрен үтеп, укучыларда алда торган проблемаларны чишү өчен кирәк булган белем-күнекмәләрне формалаштыруга ярдәм итә. Укыту процессында интегральләштерү укучыны тормышка әзерләүгә, тормышта үз юлын табарга, һөнәрен дөрес сайларга ярдәм итә; аралашу осталыгын, фикер йөртү үсешен тәэмин итә. Интеграль дәрес мәктәп курсында традицион булмаган интерактив метод-алымнар куллану мөмкинлеге буларак та уңышлы санала.

Дәресләрне интегральләштерүнең төп *максаты* – укучыларда яңа заман кешесенә хас булган фәнни фикерләү сәләтен үстерүгә, дөньяны яңача күзаллавына йогынты ясау. *Бурычлары*: 1.Уку сыйфатын яхшырту. 2. Укуны мәгълүматлы итү. 3. Уку предметлары арасында охшаш якларны билгеләү. 4. Дәрестә эшчәнлекнең яңа формасын тәмин итү (ике предмет укытучысының үзара хезмәттәшлеге). 5. Укучыларның танып белү активлыгын арттыру. 6. Татар теленә, әдәбиятка һәм башка предметларга карата кызыксыну уяту.

Хәзерге вакытта мәктәпләрдә төрле предметлар интегральләштерелә Укучыны шәхес буларак төрле яклап үстерүне күздә тоткан педагог өчен бу бик мөһим. Һөнәри осталыгын күтәрү максатыннан яңа технологияләрне кулланып эшләү – укытучы өчен бик отышлы алым.

Уку-укытуны интегральләштерү ул – укучыларда предметларны үзара бәйләнештә өйрәнүләре аша дөньяга караш тәрбияләү.

Уку предметларын интегральләштерүнең *төп шартлары*:

1. Предметара бәйләнешне тәэмин итү, төшенчәләрне системалаштыру. 2. Төп максат-бурычларны билгеләү. 3. Укыту планын төзү, аны тормышка ашыруның төп юлларын билгеләү.

*Интегральләштерелгән дәрес* – төрле фәннәр буенча белемнәрне берләштерү һәм нинди дә булса проблеманы чишү өчен махсус оештырылган дәрес. Мондый дәресләр укучыларга файдалы. Алган белемнәрне системага салырга мөмкинлек бирә, фәнгә карата кызыксыну уята. Дәрес барышында укучы-

лар белән индивидуаль эшләргә, хаталарны вакытында төзәтергә мөмкинлек туа. Эш төрләренең чиратлашуы укучыларның игътибарлылыгына, активлыкларына уңай йогынты ясый.

*Интеграль дәресләр структурасы.* Интеграль дәрес структурасы төгәллеге, дәрес материалының эзлеклелеге, предметларның үзара бәйләнеше, мәгълүматлылыгы буенча традицион дәрестән аерылып тора. Мондый типтагы дәресләрне оештыру өчен укытучы төп максатны билгели, максатка ярашлы материал сайлап ала.

*Интеграль дәресләрне үткәрү методикасы.*

1. *Әзерлек этабы.* Укытучы максатны билгели, танып-белү бурычларын, дәресне үткәрү формасын, метод-алымнарны билгели, әдәбият сайлап ала.

Укучылар белән әзерлек эшләре үткәрелә. Төркемнәргә бүленә, темалар бирелә. Һәркем бер-ике атна үз темасы өстендә эшли. Интеграль дәресләрне үткәрүгә әзерлек этабында төрле материал кулланыла. Коллектив укыту методлары зур роль уйный. Группаларда эш укучыны шәхес буларак формалаштыра.Укытучы җыелган материалның эчтәлеген карый, коррекцияли, кирәк дип санаса, терәк конспект әзерләргә тәкъдим итә.

2. *Дәресне үткәрү.* Укытучы эшне төркемнәрдә оештыра. Төркемнәр бер-бер артлы чыгыш ясыйлар. Материалны фәнни, эзлекле сөйләүгә игътибар ителә. Төп теманы аерып алу, чыгышны эксперимент белән бәйләп алып бару, күрсәтмәлелектән файдалану уңышлы санала. Төркемнәр чыгышында укучылар актив катнаша, һәр укучы чыгышыннан төркемнең эшчәнлеге бәяләнә. Эшне диалог формасында оештырырга мөмкин. Төркемнәрнең эшен сыйныфтан билгеләп куелган бер җитәкче укучы контрольдә тота.

3. *Дәресне йомгаклау.* Интегральләштерелгән материал гомумиләштерелә. Укучылар ике яки берничә предметтан белем алалар. Җыелган материал тапшырыла.

Интеграль дәресләрне оештырганда, түбәндәге формаларны куллану нәтиҗәле: лекция, әңгәмә, конференция, семинар һ.б. Күбесенчә конференция, семинар дәресләр еш үткәрелә. Фәнни-популяр әдәбият белән эшләү, таблиацалар, схемалар төзү укучыларда анализлау, гомумиләштерү, системалаштыру сәләтен

үстерә. Дәрес барышында укучылар яңа материалны үзләренең белемнәре белән чагыштыралар, шуңа күрә мондый укыту нәтиҗәле була.

Интеграль дәресләрнең уңышлылыгы әзерлек этабының сыйфатына бәйле. Дәрес материалын ныклап тикшереп карап алырга кирәк. Кирәкле материалны дөрес сайлау өчен укытучы үз предметын яхшы белергә тиеш. Иҗади эшләүче укытучы мондый вакытта метод алымнарның уңышлы кулланыла торганнарын сайлап ала. Дәресләрне нәтиҗәле үткәрү өчен өйрәнү объектын һәм кирәкле материалны дөрес сайлау; дәреснең барлык этапларында да укучыларның фикерләү эшчәнлеген активлаштыра торган проблемалы укыту методларын куллану; укытучыларның югары һөнәри осталыгы таләп ителә.

Төрле фән укытучыларының иҗади дуслыгы укучыларның фәннәрне үзләштерүенә уңай йогынты ясый, чөнки бер предметны өйрәнгәндә кулланыла торган метод алымнар интегральләштерү нәтиҗәсендә икенче предметны укыту методикасына да күчә, уңышлы кулланыла башлый.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр мәктәпләр алдына мөстәкыйль фикерләүче иҗади шәхес тәрбияләү бурычын куя. Хәзерге вакытта мәктәпкә куелган вазифа укучыга ниндидер бер күләмдә белем бирү белән генә чикләнми, һәрвакыт белемгә омтылучы, мәктәпне тәмамлаганнан соң да үз эшчәнлеген дөрес оештыра белүче шәхес тәрбияләү күздә тотыла. Интегральләшкән дәресләр укучыны актив танып-белү эшчәнлегенә этәрә, һәр укучыга нинди дә булса бер өлкәдә үзен күрсәтергә мөмкинлекләр киңрәк ачыла. Укучы алган белемнәренең кайсы өлкәдә куллана алачагын тулырак күзаллый.

Укыту нинди төрдә булса да, ул яшь буынга кешелек тарафыннан тупланган белем хәзинәсен тапшыру процессы буларак кабул ителә. Кешелек үсешенең төрле чорларында белем бирү эчтәлеге төрлечә булуы мәгълүм, ләкин аларның барысы да шәхес үсешен үзәккә куя.

Фәннең барлык өлкәләре дә үзара тыгыз бәйләнештә тора, шуңа күрә мәктәптә өйрәнелә торган фәннәр дә бер-берсенә белән бәйле.

Предметара бәйләнешне тормышка ашыру белемнәрне тирәнтен өйрәнүгә, фәнни терминнарның формалашуына, укыту-тәрбия процессының камилләшүенә уңай йогынты ясый. Интеграль дәресләр предметара бәйләнешне тәэмин итүнең бер чарасы булып тора, укытуның фәннилеген арттыра, белемнәрне системалаштырырга, логик фикерләү сәләтен үстерүгә, укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүгә ярдәм итә. Гади дәресләргә караганда интегральләшкән дәресләрнең эстетик кыйммәте дә зур.

Укыту процессында интегральләштерү берничә функция башкара: методологик функция – укучыларда өйрәнелә торган фәннәргә заманча караш формалаштыру; белем бирү функциясе – танып белү процессында системалылык, аерым кисәкләрнең бербөтен хасил итеп бәйләнешен аңлау; үстерү функциясе – танып белү активлыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү, белемнәрен арттыру; конструктив функция – уку материалының эчтәлеген, укыту методларын һәм алымнарын камилләштерү.

Интегральләштерүне горизонталь, вертикаль төрләргә бүлеп карарга була. Горизонталь интегральләштерү вакытында мәктәп программасы буенча укытыла торган предметлар интегральләштерелә. Вертикаль интегральләштерү бер предметның төрле елларда өйрәнелгән материалын үз эченә ала.

Интегральләштереп укытуның практик әһәмияте зур. Укучылар алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәнәләр. Укытучы да үзенең предметын яңача күзаллый башлый, башка предметлар белән бәйләнешен тирәнрәк аңлый. Интеграль дәресләрнең уңышлылыгы төрле шартларга бәйле.

Мәктәптә интеграль дәресләрне оештыруда кыенлыклар килеп туарга мөмкин. Дәресләр расписаниесен җайлау, охшаш темаларның бервакытта үткәрелүе, методик ярдәмлекләрнең аз булуы һәм башка шундый мәсьәләләр интеграль дәресләрне үткәрүдә нинди дер проблемалар китереп чыгарырга мөмкин.

Уку-укыту процессында интегральләштерү төрле формада булырга мөмкин. Мәсәлән, 5нче сыйныф укучыларына куелган таләпләр башлангыч сыйныфтагы таләпләрдән аерыла. Шулай ук төрле предмет укытучысының таләпләре бер-берсеннән бик нык аерылырга мөмкин. Шуңа күрә башлангыч сыйныф

укучысы 5 сыйныфка күчкәч, килеп туган үзгәрешләрне авыр кичерә, югалып кала. Аның укуга кызыксынуы кими, уку сыйфаты төшә. Мондый ситуациядән чыгу өчен, укыту процессын интегральләштерү мөһим. Дәфтәрләргә куелган таләпләрне генә алсак та, һәрбер предмет укытучысы укучыга үз таләпләрен куя. Укытучылар алдан ук киңәшләшеп, укучының дәфтәр тотышына, эшне башкаруга кагылышлы мәсьәләләрне алдан ук билгеләп куйсалар, киңәшләшеп эшләсәләр, нәтиҗә күзгә күренеп яхшырачак. Мондый эшне беренчел дәрәҗәдә интегральләштерү дип атарга мөмкин. Иң киң кулланылышта икенче, өченче дәрәҗәдә интегральләштерү. Төшенчәләр формалаштыру, мәгълүмат алу чараларын берләштерүне шартлы рәвештә икенчел дәрәҗәдә интегралләштерү дип карарга була. Ул нинди дә булса мәгълүматны, даталарны яхшы истә калдыру, кабатлау, дәрескә яңа материал кертү һ.б. максатлардан чыгып оештырыла. Шуны истә тотарга кирәк: алынган белемнәр программаны интегральләштерү нәтиҗәсеме. Өченчел дәрәҗәдә интегральләштерү материалны чагыштырма характерда өйрәнү белән бәйле һәм укучыларда чагыштыра белү, анализлау күнекмәләрен үстерүгә нигезләнгән. Әгәр бу дәресне бер генә укытучы үткәрсә, дәреснең дәвамы буларак, бу дәрестә кузгатылган проблемалар, фактлар анализлана. Шуңа күрә педагогик эшчәнлектәге хаталарны төзәтү өчен укытучыларның бер-берсенең дәресләренә йөрүләре дә мөһим. Дүртенчел дәрәҗәдә интегральләштерү укучыларның актив эшчәнлекләрен үз эченә ала. Укучылар мөстәкыйль рәвештә анализлый алалар, үзләренең алган белемнәрен нәтиҗәле файдаланалар. Бу этапта укучыларның фикерләү дәрәҗәсен контрольдә тотарга кирәк, бигрәк тә укытучыга укучыларның фикер йөртүгә ихтыяҗы тууын аңлау мөһим. Эшнең нәтиҗәсен күрү, башкарылган эшнең уңышлы булуы турында сөйли.

*Интеграль дәрес төрләре.* Интеграль дәресне бер генә укытучы да үткәрә ала. Икенче предмет укытучысы интеграль дәресләр системасын төзүдә, максат-бурычларны билгеләүдә, дәрес өчен материал туплауда катнаша. Яңа материал өйрәнү дәресләрен генә түгел, белем-күнекмәләрне системалаштыру, кабатлау дәресләрен интеграль итеп үткәрү дә отышлы. Дәресләрне

зачет, иҗади проект яклау формасында үткәрергә була. Интеграль дәресләр ике яки берничә укытучының актив эшчәнлеген тәэмин итә. Укытучыларның роле дәреснең формасына карап үзгәрә. Бер дәресне берничә укытучы алып барырга мөмкин. Интеграль дәресләр төрле формада була. Күбесенчә стандарт булмаган дәресләр үткәрелә. Яңа мәгълүмат хәбәр итү дәресләрендә укучылар төркемнәрдә эшлиләр.Һәр укучы үзенең темасы буенча төркем алдында чыгыш ясый.

Иҗади эзләнү дәресләрендә укучылар куелган мөстәкыйль рәвештә проблеманы чишү юлларын эзлиләр. Эзләнү алымнары алдан әзерләнеп куела. Мондый дәресләр уңышлы һәм әһәмиятле.

Газета яки фәнни альманах чыгару. Укучыларга аерым темаларга эзләнү характерындагы эшләр бүлеп бирелә. Шул эшләрнең нәтиҗәсе буларак газета яки альманах чыгарыла.

Контроль дәресләр иҗади проектлар яклау яки зачет тибында үткәрелергә мөмкин. Зачет-олимпиада, зачет-экзамен зачет-конкурс, зачет-аукцион үткәрү кызыклырак һәм уңышлырак санала.

Интеграль укытуга төп таләп укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенең югары булуы, интегральләштерү башка предметлар хисабына өйрәнеләсе материалның тематикасын киңәйтә, тирәнтен анализлауны таләп итә.Укучылар тикшеренү, эзләнү методлары белән эшли алсалар, вакытларын дөрес файдалана белсәләр генә бу юнәлештә эшли алачаклар.

Уку планнары һәрбер предметны аерым өйрәнүгә корылган. Интеграль дәресләрне даими оештыру өчен фәннәрне интегральлштерүнең билгеле бер системасын булдырырга кирәк. Предметлар буенча уку планнарын килешенеп төзү, гомуми төшенчәләрне, охшаш темаларны аерып алу, аларны өйрәнүнең бер вакытын билгеләү, бергәләп консультацияләр үткәрү һ.б. Аннан соң интеграль дәресләрнең планын, конспектын төзү.

Интеграль дәрес укытучыдан зур тырышлык, осталык, иҗади активлык таләп итә. Укучылар арасында анкета-сораштырулар үткәрү мондый дәресләрнең алар өчен кызыклы булуын, дәрес материалының җиңел үзләштерелүен, укучыларда укуга карата уңай мотивация барлыкка килүен күрсәтә.

Татар телен татар әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, чит тел,

тарих , география, музыка һ.б. фәннәр белән интегральләштерергә мөмкин.

Инглиз теле белән татар теле һәм әдәбиятын интегральләштерү психологик, педагогик һәм эстетик яктан да үзен аклый. Чит ил әдәбияты, культурасы, гореф-гадәтләре укытучы өчен дә, укучы өчен дә бай материал тупларга мөмкинлек бирә, башка халыкларның мәдәниятына, теленә, гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияли. Чит ил мәдәнияте бөтендөнья мәдәниятенең бер өлешен тәшкил итә. Чыгарылыш сыйныф укучысының бер чит телдә иркен сөйләшә алуын тәэмин итү юнәлешендә дә инглиз теле белән татар теле һәм әдәбияты дәресләрен интегральләштерү бик мөһим.

Татар теле белән татар әдәбиятын уңышлы интегральләштерергә мөмкин. Әдәбият дәресләрендә татар теленнән алган белемнәрне кабатлау, сисистемалаштыру эшен оештырырга мөмкин. Татар теле дәресләрендә татар язучыларының әсәрләреннән файдалану, шигырҗләрне сәнгатҗле уку; грамматик категорияләрне кабатлаганда мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, җырларны файдаланырга була.

Татар теле белән рус телен, татар әдәбияты белән рус әдәбиятын интегральләштерү күп мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына, рус балаларына татар телен өйрәтүдә мондый дәресләр алыштыргысыз, чөнки грамматик категорияләрне чагыштырма характерда аңлату укучыларның материалны җиңел үзләштерүенә китерә. Язучыларның биографиясен, әдәби әсәрләрне өйрәнү дәресләрендә темасы, стиле буенча туры килгән әсәрләрне татар һәм рус телләрендә чагыштырып өйрәнү дәресләрне нәтиҗәле, кызыклы үтүен тәэмин итә.

# ТАТАР ТЕЛЕ – ИНГЛИЗ ТЕЛЕ
## (интеграль дәрес, 4 сыйныф)

**Камаева Рима Бижановна,**
Яр Чаллы шәһәре 7 урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
**Камаева Рузана Равилевна,**
Яр Чаллы шәһәре 7 урта мәктәбенең
инглиз теле укытучысы

**Дәреснең темасы**: “Гаилә” темасы буенча сөйләм телен үстерү.

**Дәреснең тибы**: Сөйләм телен үстерү.

**Максат:**

1.“Гаилә” темасы буенча үтелгән лексиканы (татар һәм инглиз телләрендә) сөйләмдә активлаштыру, белемнәрне ныгыту, системалаштыру.

2. Татар теленә генә хас авазларны дөрес әйтү күнекмәләрен камилләштерү, ,“Гаилә” темасы буенча өйрәнелгән лексиканы татар һәм инглиз телләрендә сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү, танып-белү эшчәнлеген, сәхнә культурасын, аралашу күнекмәләрен үстерү.

3.Гаилә әгъзаләренә ихтирамлы булырга өйрәтү, укучыларда үз гаиләләре белән горурлану хисләре уяту; игътибарлылык, ярдәмчеллек, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү, татар һәм инглиз телләрен өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**Дәресне җиһазлау:** Проектор, “Гаилә” темасына рәсемнәр, фотосурәтләр, алфавит, авазлар язылган карточкалар.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру.**

1. Исәнләшү.

– Исәнмесез, укучылар. Хәерле иртә.

– Кәефләрегез ничек? (*Укучыларның җаваплары*)

Greeting.

– Good morning, boys and girls!

– I’m glad to see you! Sit down, please.

– Who is on duty today?
– Who is absent today?
– What day of the week is it today?
– What date is it today?

**II. Фонетик зарядка.**

Татар һәм инглиз телләре өчен уртак булган [h], [w], [ә], [ң] авазларын кабатлау.

– Прослушайте и назовите слова со звуком [ә] (*укытучы укучыларның* [ә] *авазын ишетеп аңлауларын контрольгә ала*).

Кием, әни, киңәш, көн, көндез, әби, бүлмә, ишек, әти, бабай, тәрәзә, өстәл, гаилә.

– Прослушайте и назовите слова со звуком [w] (*укытучы укучыларның* [w] *авазын ишетеп аңлауларын контрольгә ала*).

Вакыт, Вәли, вагон, савыт, тау, гөрләвек, веранда, кавын.

– Сүзләрне дөрес укыгыз (*укытучы* [ң] *авазы әйтелешен контрольгә ала*).

Чана, чаңгы, борын, күңелле, бәрәнге, көндезге, киңәш, нигез, урман, иген, уңыш, идән, аның, көн, төн, үлән, мин, миң.

– Сүзләрне дөрес укыгыз (*укытучы* [h] *авазы әйтелешен контрольгә ала*).

Шәһәр, халык, һәм, хат, һава, хәбәр, хәл, илһам, сәхнә, һәйкәл, хезмәт,зинһар,

– Children, do you remember English sounds? Repeat after me, please.

[ə] capital, have, bag, grandpa, grandma, family.
[w] window, will, week, windy.
[h] hat, horse, hand, house.
[ŋ] living room, spring, angry, monkey.

*(Укытучы укучыларга авазлар язылган карточкалар күрсәтә, укучылар авазны кабатлыйлар, шул аваз кергән сүзләр әйтәләр).*

**III. Белемнәрне актуальләштерү һәм системалаштыру.**

1.“Гаилә” темасына өйрәнелгән лексиканы кабатлау**.**

Татарчадан-русчага тәрҗемә итү (*укытучы сүзләрне әйтә, укучылар тәрҗемә итәләр, тәрҗемә өчен сүзләр кечкенә*

*төркемнәрдә, ягъни блоклап бирелә*).

Әни – минем әнием, синең әниең, әнигә, әнигә бүләк, әнигә бүләк алам.

Әти – синең әтиең, аның әтисе, әтидән, әтидән сорыйм, мин әтидән сорыйм.

Абый – минем абыем, аның абыйсы, абыйның китабы, абыйның китабы өстәлдә ята.

Апа – безнең апабыз, сезнең апагыз, апаны, апаны чакыра, апаны урамга чакыра.

Русчадан-татарчага тәрҗемә итү.

Бабушка – моя бабушка, к бабушке, поеду к бабушке, летом поеду к бабушке.

Дедушка – твой дедушка, дедушку, от дедушки, письмо от дедушки.

Семья – моя семья, твоя семья, в семье, в семье живет.

2. Сәнгатьле уку күнегүләре. Шигырьләр уку.

(*Экранда шигырьләр күрсәтелә, укучылар сәнгатьле итеп укыйлар, тагын бер тапкыр өйрәнелгән лексиканы хәтердә яңарталар*)

Г. Тукай “Безнең гаилә”,
Ә. Бикчәнтәева “Дәү әни”,
Р. Вәлиева. “Дәү әнигә барабыз”
Р. Миннуллин “Кем соң минем әби?”,
Н. Мадьяров “Әби күзлеген эзли”,
Р. Фәйзуллин “Минем әти” һ.б.
My dear Mummy.
Good night.
I love my dear mummy.
This is my mother.
This is my family.
I have got a mother.

| | | |
|---|---|---|
| **My dear Mummy**<br>My dear, dear Mummy!<br>I love you very much.<br>I want you to be happy<br>On the eighth of March!<br>Be happy, be happy<br>On the eighth of March!<br><br>**I have got a mother**<br>I have got a mother,<br>I have got a father,<br>I have got a brother<br>Paul.<br>I have got an aunt,<br>I have got an uncle,<br>How I love them all. | **Good night**<br>Good night mother,<br>Good night father,<br>Kiss your little son.<br>Good night sister,<br>Good night brother,<br>Good night everyone.<br><br>**This is my mother**<br>This is my mother,<br>This is my father,<br>This is my brother<br>Paul.<br>This is my sister, this is my cousin.<br>How I love them all. | **I love my dear mummy**<br>I love my dear mummy,<br>I love her very much.<br>And do you love your mummy?<br>Of course, and very much!<br><br>**My family**<br>This is daddy,<br>This is mummy,<br>This is sister,<br>This is brother,<br>This is me, me, me,<br>And my whole family. |

| | | |
|---|---|---|
| **Әби күзлеген эзли**<br>Әби күзлеген эзли,<br>Кайда икәнен белми.<br>Күзлеге бит кулында,<br>Әмма ул аны сизми.<br><br>– Әби, әби, – дим аңа,<br>Каршысына ук килеп,<br>Җайлы булыр эзләргә,<br>Күзлегеңне ки элек.<br><br>Әби күзлеген кия,<br>Үзе елмаеп көлә.<br>–Рәхмәт, табып бирдең, – ди,<br>Аркамнан сөя-сөя.<br>Н.Мадьяров | **Малайлар сөйләшә**<br>Мин үскәч абый булам,<br>Аннары бабай булам!<br>Ә мин бабай булгач та<br>Гел әйбәт малай булам!<br><br>Мин үзем әти булам!<br>Ә мин дәү әти булам!<br>Үскәч кем буласымны<br>Мин әле әйтми торам!<br>Мин батыр солдат булам!<br>Ә мин космонавт булам!<br>Ә мин Третьяк булам, | **Әни сүзе**<br>“Әни” диеп язып куйдым<br>Яңа яуган ак карга.<br>Таптамагыз!<br>Һич ярамый<br>“Әни” сүзен таптарга.<br>З.Туфайлова<br>**Әни кирәк**<br>Көннәр якты булсын өчен,<br>Йокы татлы булсын өчен<br>Әни кирәк, әни кирәк.<br>Йокы татлы булсын өчен<br>Әни кирәк!<br>Җил-яңгырдан саклар өчен,<br>Усаллардан яклар өчен<br>Әни кирәк, әни кирәк.<br>Усаллардан яклар өчен<br>Әни кирәк!<br>Р.Миңнуллин |

| | | |
|---|---|---|
| | Капкада сакта торам!<br>Р.Миңнуллин<br>**Җирдә миңа ни кирәк?**<br>Җирдә миңа ни кирәк?<br>Әти дә әни кирәк!<br>Җирдә миңа ни кирәк?<br>Без яшәгән өй кирәк!<br>Әти дә әни кирәк!<br>Без яшәгән өй кирәк!<br>Ш.Галиев | |

3. “Минем гаиләм” темасына сөйләү. *(Укучылар өйләреннән алып килгән гаилә фотолары буенча үз гаиләләре белән таныштыралар. 2-3 укучы сөйли).*

*Минем гаиләм*

Минем гаиләм зур. Әти, әни, апа, абый, бабай, әби һәм мин. Без гаиләдә җиде кеше яшибез.. Әтиемнең исеме – ... . Әниемнең исеме – ... . Әти машина йөртә. Әни банкта эшли. Апам һәм абыем мәктәптә укыйлар. Апам 5 нче сыйныфта укый. Абыем 7 нче сыйныфта укый. Әбиемә алтмыш яшь. Аның исеме –...Бабама 65 яшь. Без тату, дус яшибез.

Минем гаиләм зур. Әти, әни, апа, абый, бабай, әби һәм мин. Әби белән бабай авылда яшиләр. Әти, әни һәм мин шәһәрдә яшибез. Әти заводта эшли. Әни – сатучы. Мин 3 нче сыйныфта укыйм. Җәй көне без дә авылга кайтабыз. Безнең гаиләбез күңелле, дус яши.

(*Фотолар төрле булырга мөмкин. Нинди сүрәт булуына карап, монологның эчтәлеге үзгәрә).*

My family

Hello! My name is…. I m 10.I m a pupil. I live in Russian.

I have got a family. I have got a father, a mother (a sister, a brother). My father’s name is … He is … My mother’s name is … She is … (My brother’s name is … He is … My sister’s name is … She is … )

I love my family.

4. Рәсемнәр буенча диалоглар төзү. Парлап эшләү. *(Укучыларга төрле ситуацияләрдә гаилә әгъзалары сурәтләнгән рәсемнәр бирелә, укучылар бер-берсенә сораулар биреп, ике телдә диалог төзиләр*).

*Үрнәк.*

– Бу кем? – Бу минем абыем.

– Аның исеме ничек? –Аның исеме Марат.

– Аңа ничә яшь? –Аңа ундүрт яшь.

– Ул ничәнче сыйныфта укый? –Ул җиденче сыйныфта укый.

– Ул нишли? –Ул хат яза.

*Example.*

– Who is this? –This is my sister.

– What is her name? –Her name is Arina.

– How old is she? –She is fifteen.

– What class does she learn in? – She studies in eight classes.

– What does she do? – She reads books.

5. “Әбиләрдә кунакта”. Сәхнәләштерелгән күренеш. Төркемнәрдә эш (*Укучылар ике төркемгә бүленәләр, тема буенча ике телдә диалог төзиләр, уйнап күрсәтәләр*).

**IV. Йомгаклау. Билгеләр кую**.

**V. Өй эше бирү.** (*Ике телдә шигырьләр ятларга бирелә*)

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ –ТАТАР ТЕЛЕ (ИНТЕГРАЛЬ ДӘРЕС, 7 СЫЙНЫФ)

**Камаева Рима Биҗановна,**
Яр Чаллы шәһәре 7 урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәреснең темасы:** Габдулла Тукайның “Су анасы” әкияте. Затланышлы фигыльләрне кабатлау.

**Дәреснең тибы:** белемнәрне ныгыту, гомумиләштерү, системалаштыру.

**Максат:**

1. Г. Тукайның “Су анасы” әкиятенең эчтәлеген үзләштерү.

Затланышлы фигыльләр буенча алган белемнәрне кабатлау, системага салу.

2. Укучыларның тәрҗемә итү күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү, өйрәнелгән лексиканы, затланышлы фигыльләрне сөйләмдә активлаштыру, затланышлы фигыльләрнең төркемчәләрен аера белү күнекмәләре булдыру.

3.Укучыларны шагыйрь иҗаты белән кызыксындыру, әсәрләре аша уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** Шагыйрь иҗаты буенча күргәзмә, әсәрләренә иллюстрацияләр, “Фигыль төркемчәләре” таблицасы, биремле карточкалар, җөмләләр салынган конверт.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Фонетик зарядка.**

– Прослушайте отрывок, назовите слова со звуком [ә], [ө].

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.
Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
«Шык!» та «шык!» кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.

**III. Тел күнегүләре.**

– Бүген ничәнче число?

– Атнаның нинди көне?

– Татар теле ничәнче дәрес?

– Хәзер кайсы ел вакыты?

– Бүген көн нинди?

– Саша, позови друга на улицу. Докажи, что там хорошо. *(Дустым, әйдә урамга чыгабыз. Анда бик күңелле, кояш җылыта. Язгы кояш сәламәтлек өчен файдалы).*

– Артур, как скажешь, что на деревьях появляются зеленые листья. *(Агачларда яшел яфраклар чыга башлады).*

– Вика, яз айларын сана әле *(Яз айлары: март, апрель, май).*

– Апрель аенда нинди күренекле шагыйрь туган? *(Апрель аенда татар халкының күренекле шагыйре Габдулла Тукай туган).*

**III. Белемнәрне актуальләштерү.**

– Г.Тукайның "Су анасы" әсәрен өйрәнүне дәвам итәрбез, фигыль төркемчәләрен кабатларбыз. Шагыйрьнең без өйрәнгән шигырьләрен искә төшерик.

**1. Викторина** *(Шигырьләреннән өзекләр бирелә, укучылар шигырьнең исемен әйтәләр. Дөрес җавап белән чагыштырып тикшерәләр).*

1. "Иң элек бу тел белән
әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
әбкәм хикәят сөйләгән".
2. "Урамнарда күңелсезлек, авылда сизелә кайгы,
Терлекләр вә шау-шулар, кызыклар кайда ул җәйге!"
3. "Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас – менә бәхете аның шунда".
4. "Мин туганга тик ике айлап
Булыр йә өч кенә"
5. "Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар".
6. "Ап-ак булып кайтып килә безнең Бабай...".
7. "Яшь балаларны ашап китте Бүре,
Бик усал ерткычтыр ул, муркыргыры".
8. "Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен "тавыклары җырлай" диләр".
9. "Куркам үзем әллә нидән, юк янымда юлдашым."
10. "И, сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә - эш..."
11."Шунда аңа бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңа кып-кызыл алма бирде Алмагач."

*Җаваплар:*

1. "Туган тел".
2. "Мәктәптә".
3. "Бәхетле бала".
4. "Кызыклы шәкерт".
5. "Көз".
6. "Ак бабай".
7. "Бичара куян".

8. “Шүрәле”.

9. “Су анасы”.

10. “Эшкә өндәү”.

11. “Эш беткәч уйнарга ярый”.

**2. Рәсемнәр белән эш** *(Шагыйрьнең әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр тәкъдим ителә, укучылар нинди шигырьгә ясалуын әйтәләр)*

**3. Таблицаны тутыру.**

| Боерык фигыль | Хәзерге заман хикәя фигыль | Үткән заман хикәя фигыль | Киләчәк заман хикәя фигыль | Шарт фигыль |
|---|---|---|---|---|
| ... | су коена | ... | ... | ... |
| утыр | ... | утырган | ... | |
| ташла | ташлый | ... | ... | ташласа |
| ... | шакый | ... | шакыр | ... |
| чум | ... | чумды | ... | ... |

**IV. Белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру. Г. Тукайның “Су анасы” әкияте буенча эш.**

***1. Русчадан татарчага тәрҗемә итү*** *(укучылар тәрҗемәне тексттан табып укыйлар).*

Летний день, купаюсь, быстро оделся, смотрю: сидит страшная женщина, боюсь чего-то, стою под густыми деревьями и т.д.

***2. План буенча эш*** *(алдагы дәрестә төзелгән планга туры килгән өлешләрне укып күрсәтәләр).*

План.

1. Җәйге эссе көндә малай елгада су коена.
2. Су анасы басмада утыра.
3. Малай, алтын таракны алып авылга чаба.
4. Су анасы малай артыннан йөгерә.
5. Авыл этләре Су анасын куркыталар.
6. Малай таракны әнисенә бирә.
7. Төнлә кемднр тәрәзә шакый.
8. Су анасы белән сөйләшү.
9. Алтын таракны әнисе тәрәзәдән ташлый.
10. Әнисе улын ачулана.

***3. Текстны рольләргә бүлеп уку.***

***4. 1нче бүлектән затланышлы фигыльләрне табып***

***язу, русчага тәрҗемә итү.*** Коенам – купаюсь, йөзәм – плаваю, чәчрәтәм – ..., уйныйм – ..., чумам –..., сөзәм – ... , тирләмәм – ..., йөгереп чыктым – ... , киендем – ... , куркам – ... , китәм – ... , төште – ... , карасам – ... , утырган – ... , ялтырый – ..., сикерде – ... , чабам – ... ,, ашыгам – ... , тирлим – ... , пешәм – ... , янам – ....

(*Күнегүне эшләгәч, бу фигыльләр белән сүзтезмәләр төзергә мөмкин, аннан соң нәтиҗә ясала*)

***5. Әсәр эчтәлеге буенча әңгәмә.***

*Әңгәмә өчен сораулар:*

1. Әсәрдә нинди геройлар бар?

2. Су анасының портреты ничек бирелә? (*Укучылар әсәрдән су анасының портретын табып укыйлар*)

3. Малай нинди? Ул нинди начарлык эшли?

4. Әнисе малайны ачуланамы?

**V. Төркемнәрдә эш** *(Укучылар ике төркемгә аерыла. Аларга әсәрдән ике иллюстрация, җөмләләр салынган конверт бирелә. Укучылар конверттан рәсем эчтәлегенә туры килгән җөмләләрне сайлап алып, текст төзиләр.)*

**VI. Өй эше бирү. Йомгаклау. Билге кую.**

Дәрес ахырында укучылар Г.Тукай шигырьләренә иҗат ителгән җырларны тыңлыйлар, кушылып җырлыйлар (“Туган тел”, “Бәйрәм бүген” җырлары).

## ТАТАР ТЕЛЕ – ӘДӘБИ УКУ (ИНТЕГРАЛЬ ДӘРЕС, 2 СЫЙНЫФ)

**Мөлекова Р.М.,**
Яр Чаллы шәһәре 7 урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәреснең темасы:** Г.Тукай әсәрләре аша сүз төркемнәрен кабатлау.

**Максат:** Сүз төркемнәре турында булган белемнәрне системалаштыру. Сүз байлыгын арттыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен һәм сөйләм телен үстерү. Г.Тукай әсәрләре аша укучыларда тырышлык, дуслык сыйфатлары тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре:**

*Шәхси УУГ:* әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу; укуның кирәклеген аңлау.

*Регулятив УУГ:* укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү; үз эшеңне бәяли белү.

*Танып-белү УУГ:* өйрәнелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү; укытучы биргән сорауларга тулы җавап бирә белү.

*Коммуникатив УУГ:* программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу; әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру; үз фикереңне төгәл аңлаешлы әйтә белү.

**Дәреснең тибы:** Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

**Дәресне җиһазлау:** Компьютер, проектор, Г. Тукай портреты, шагыйрьнең китапларыннан төзелгән күргәзмә; таратма материал, дәреслек.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру**, **уңай психологик халәт тудыру.**

1. Исәнләшү.

– Исәнмесез, укучылар! – Исәнмесез.

– Хәлләрегез ничек? – Кояшлы көн кебек.

– Ни өчен килдегез? – Татар телен, туган телне өйрәнергә дип килдек.

2. Дежур укучы чыгышы.

**II. Актуальләштерү**.

1. –Хәзер апрель ае. Апрельдә нинди истәлекле даталар бар? (Г. Тукайның туган көне).

– Быел уку дәресендә без шагыйрьнең нинди әсәрләрен өйрәндек? (“Иртә”, “Ташбака белән куян”)

– Сез аның тагын нинди әсәрләрен беләсез? (“Гали белән кәҗә”, “Су анасы”, “Шүрәле” һ.б.)

2. Өй эшен тикшерү.

– Өйдә кемнәр аның шигырьләрен яттан өйрәнде? (2-3 укучыны тыңлау)

– Кем иҗади эш башкарды, рәсем ясады? Бу рәсем Г.

Тукайның кайсы әсәренә?

3.Татар мультфильмнарыннан өзекләр карау (видеоязма). *(Укучылар әсәрнең исемен әйтәләр).*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

1. Экранда һәм конверт тышларында тарак, балта, капчык рәсемнәре.

– Бу әйберләр Тукай әкиятләрендәге кайсы геройларныкы? (Су анасы, Былтыр, Кәҗә белән Сарык). Аларны хуҗаларына кайтарып бирергә кирәк. Ләкин моның өчен конвертлардагы биремнәрне эшләргә кирәк Бу биремнәрне үтәгәнче, искә төшереп, сорауларга җавап бирегез әле.

**IV. Уку мәсьәләсен чишү.**

Әңгәмә өчен сораулар.

– Исем (сыйфат, фигыль) нинди сорауларга җавап бирә?

– Нәрсәне белдерә?

– Мисаллар.

(җаваплар тыңлана һәм слайдта күрсәтелә)

2) Конвертлардагы биремнәрне эшләү. (Биремнәрне төркемнәрдә эшлиләр).

**1нче бирем.** Бирелгән өзек кайсы әсәрдән? Шушы өзектән исемнәрне табарга.

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү: безнең, песи – җиденчесе.
Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

**2нче бирем**. Бирелгән өзектән сыйфатларны табарга.

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр
килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.

**3нче бирем.** Бирелгән өзектән фигыльләрне табарга.

Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

(*җаваплар тыңлана һәм слайдтагы дөрес җаваплар белән чагыштырыла*)

– Бик яхшы эшләдегез, укучылар. Әйберләр хуҗаларына кайтарылды..

3) Дәрес темасын ачыклау.

– Димәк, бүген без дәрестә нәрсә турында сөйләшәбез? (исем, сыйфат, фигыль турында)

– Бер сүз белән әйтсәк, сүз төркемнәре турында.

4) *Физкультминутка***.** Укытучы предмет исемнәрен әйтә, укучылар шуңа хәрәкәтне белдергән сүз әйтәләр һәм күрсәтәләр. (кош оча, туп ..., балык ..., җил ..., куян...)

**V. Йомгаклау, рефлексия**.

**“Сүз уены”** (Кем күбрәк сүз таба?)

– Г. Тукай яз көне туган. Әйдәгез әле яз фасылы турында сүзтезмәләр төзик (*төркемнәргә эш бирелә).*

**1 бирем.** Бирелгән исемнәргә сыйфатлар уйлап язарга**.**

*... яз ... кояш ... көн ... үлән ... яңгыр*

**2 бирем.** Бирелгән исемнәргә фигыльләр уйлап язарга**.**

*Кошлар ... Кар ... Үлән ... Кояш ... Тамчы ...*

**3 бирем.** Бирелгән сыйфатларга исемнәр уйлап язарга.

*Матур ... Җылы ... Яшел ... Көчмә ... Кояшлы ...*

Төзелгән сүзтезмәләрне кулланып***, яз турында телдән хикәя*** төзү.

– Бүген дәрестә нәрсәләр белдегез? (*укучыларның җаваплары*) Сезгә дәрес ошадымы?

**VI. Өй эше:** 1. 5 исем, 5 сыйфат, 5 фигыль язарга. (17 слайд)

2. Дәрестә язган сүзтезмәләрне кулланып, “Яз җитте” дигән темага хикәя язарга, рәсем ясарга.

**VII. Билгеләр кую**: *(Төрле түгәрәкләр күрсәтелә)* “5”ле – кызыл түгәрәк, “4”ле – зәңгәр түгәрәк, “3”ле – яшел түгәрәк. Аудиоязмадан Г. Тукай сүзләренә язылган “Туган тел” җыры яңгырый, дәрес тәмамлана.

## 1.4.УКЫТУ ПРОЦЕССЫНДА КЕЙС МЕТОДЫН КУЛЛАНУ

Уку-укыту процессында интерактив алымнар куллану укучыларның танып белү активлыгын арттыруга, аралашу осталыгын үстерүгә, төркемнәрдә, коллективта эшли белү күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итә.

Билгеле бер проблемалы ситуацияләрне анализлау (case

study – кейс методы, инглиз теленнән алынган, *case ‘очрак, хәл, ситуация’* мәгънәсендә*, “кейс”* төшенчәсе *“кәгазьләр, документлар салып куя торган кечкенә чемодан”* мәгънәсендә) күнекмәләрне камилләштерү, төрле өлкәләрдә тәҗрибә туплауны конкрет бер ситуациядә бирелгән проблеманы тану, күрә белү, аны чишү юлларын билгеләү, анализлау, һәм нәтиҗә чыгаруны үз эченә ала; төркемнәрдә эшләү, үз фикереңне әйтү, дәлилли белә күнекмәләрен камилләштерә.

Кейс методы чит илдә киң кулланылышта, беренче тапкыр Гарвард университетының (1920 елда) бизнес мәктәбендә кертелә башлый. Бүгенге көндә бу метод безнең илдә дә актив кулланылышка кереп бара һәм актуаль мәсьәләләрдән санала. Чөнки бүгенге көндә мәктәпләр алдына куелган бурычлар белем бирүгә яңача караш, интерактив алымнар куллануны таләп итә.

Кейс методы нигезендә уку-укыту процессын нәтиҗәле оештыру өчен яхшы кейслар һәм аларны дөрес куллану методикасы таләп ителә. *Кейс* – ул дәресләрдә анализлау өчен тормыштан алынган хәлләргә нигезләнгән проблемалы ситуацияләр. Ситуацияләрне анализлау укучылардан Анализ вакытында укучылар төркемнәрдә эшләргә, нәтиҗә чыгарырга, дөрес карар кабул итәргә өйрәнәләр. Методик яктан дөрес төзелгән, мәгълүмати характердагы кейс-биремнәр укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерә, интерактив метод буларак укучыларда укуга уңай караш тәрбияли, укыту процессында тормыш белән бәйләнеш тудыра. Кейс методы укытучыга да яңача фикер йөртергә ярдәм итә, иҗади эшчәнлекне тәэмин итә.

*Кейсны төзүгә таләпләр:*

1) төгәл, ачык максат куелу;
2) теманың актуаль булуы;
3) фикерләү сәләтен үстерүгә йогынты ясавы;
4) дисскуссиягә китерүе;
5) чишелешнең берничә булуы.
6) эшнең төркемнәрдә алып барылуы;
7) информация (төрле чыганаклардан алынган материал, текстлар, сүзлекләр, сораулар язылган карточкалар һ.б.) салынган “кейс”әзерләү.

*Кейсның төрләре:*

1) гамәли кейслар (тормыштан алынган реаль вакыйгаларны үз эченә ала)

2) өйрәтү характерындагы кейслар (уку материалын үз эченә ала)

3) фәнни-тикшеренү кейслары (эзләнү-тикшеренү эшчәнлеген үз эченә ала).

*Кейс методының төп вазыйфасы* – укучыларны катлаулы проблемаларны чишәргә өйрәтү, танып-белү активлыгын арттыру, аралашу осталыгын үстерү.

Кейс методының белем бирүнең традицион формаларыннан аермасы:

1) “укыту” стиле “өйрәтү” белән алмашына;

2) укучыларда иҗади эшчәнлек сыйфатлары калыплаштырыла, аңлы рәвештә белем алуга китерә;

3) укытучы сайлаган проблемалрны укучылар мөстәкыйль чишәләр, үзләштерелгән белем-күнекмәләрен файдаланып эшлиләр;

4) командада эшләү күнекмәләре камилләштерелә;

5) төрле кейс биремнәрен анализлап, укучы алдагы тормышына төрле ситуацияләрдән чыгу юлларының әзер схемаларын туплый, катлаулырак проблемаларны чишәргә күнекмәләре формалаша.

Кейс методын мөстәкыйль эшчәнлеккә әзер укучылар белән эшләгәндә генә кулланырга мөмкин. Укуга мотивация булмау кейсларны өстән генә карап чыгу белән чикләнергә мөмкин. Кейс методы башка методлар белән чиратлашып алып барыла.

Кейсларны төрле формада бирергә мөмкин: видео-кейс, мультимедиа-кейс, язма кейс. Күләме ягыннан да кейслар төрлечә булырга мөмкин: бер бит язма материалдан алып берничә язма биткә кадәр. Ләкин зур күләмле кейслар укучыларга кабул итү өчен авыррак. Кейс методы белән эшләгәндә әзерләнгән кейслар белән бергә аларны куллану буенча методик тәкъдимнәр дә булырга тиеш.

*Кейс методы куллану дәресләрен оештыруның якынча планы:*

1. Әзерлек этабы. Укытучы ситуацияләр, өстәмә материал

әзерли. Дәресне урынын, бурычларын билгели.

2. Таныштыру этабы.

Бу этапта укучыларны ситуация белән таныштырыла (ситуация, өстәмә материал, глоссарий)

3. Төп этап.

Укытучының кереш сүзе, укучыларны төркемнәргә бүлү, төркемнәрнең эшләрен оештыру (укучыларның укылган материалны төркемдә сөйләүләре, материал буенча фикер алышу, проблемаларны билгеләү, доклад ясаучыларны билгеләү). Дискуссия оештыру. 1.Төркемнәрдә дискуссия оештыру, проблемаларны тикшерү, чишү юлларын эзләү. 2. Гомуми дискуссия. Анализ нәтиҗәләре белән таныштыру, чишелешне билгеләү, йомгаклау.

4. Йомгаклау этабы.

Анализланган проблема нәтиҗәләрен презентацияләү. Берничә юл (чишелеш) булырга мөмкин. Укытучы чыгышы. Бәяләү.

*Кейс төзү өчен методик тәкъдимнәр:*

1. Кейсның темасын ачыклау (класс, бүлек, тема).
2. Кейсның максатын, бурычларын билгеләү.
3. Кейс өчен төп элементларны билгеләү (терминнар, төп төшенчәләр, презентация һ.б.).
4. Кейс төзү, дәреснең технологик моделен төзү.
5. Укучыларның тикшеренү эшчәлеген оештыру өчен бирем әзерләү (сүзлек-глоссарий, өстәмә мәгълүмат чыганакларын әзерләргә мөмкин).
6. Кейсны куллану буенча тәкъдимнәр әзерләү.

## Татар әдәбиятыннан кейслар

**Тема:**

Л.Васильева-Гангнусның “Язгы каникул” текстын өйрәнү.

**Сыйныф:** 5 сыйныф (67-68 дәресләр).

**Кейс №1.**

1. Дәреслек: Хайдарова Р.З., Ахметзянова Г.М. Татарский язык(Күңелле татар теле). 5 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке(для изучающих татарский язык). – Казань: Татар-

мульфильм, 2014. – 128 с.

2. Сүзлек: Татарча-русча сүзлек: 25 000 сүз / И.Г. Габдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Юнәлиева; Ф.Ә. Ганиев ред. – 5-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 524 б. = Татарско-русский словарь: 25 000 слов / И.А. Абдуллин, Ф.А. Ганиев, М.Г. Мухамадиев, Р.А. Юналеева; под ред. Ф.А. Ганиева. – 5-е изд. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. – 524 с.

3. Әсәргә иллюстрацияләр.

4. Сорау язылган карточка.

Ни өчен Галигә өйдә күңелсез?

**Кейс №2**

1. Дәреслек: Хайдарова Р.З., Ахметзянова Г.М. Татарский язык (Күңелле татар теле). 5 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке(для изучающих татарский язык). – Казань: Татармульфильм, 2014. – 128 с.

2. Сүзлек: Татарча-русча сүзлек: 25 000 сүз / И.Г. Габдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Юнәлиева; Ф.Ә. Ганиев ред. – 5-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 524 б.

3. Русча-татарча сүзлек: 47 000 чамасы сүз / Ә.М. Ахунҗанов, Р.С. Газизов, Ф.Ә. Ганиев һ.б.; Ф.Ә. Ганиев ред. – Төз. 4-нче басма. – М.: Инсан, 1997. – 720 б.

4. Әсәргә иллюстрацияләр.

5. Биремле карточка.

1) Әсәрдәге төп персонажларны билгеләргә.

2) Персонажларның эш-гамәлләре аша аларга характерлы сыйфатларны ачыкларга.

**Тема:**

Р.Вәливаның “Туган көндә” текстын өйрәнү.

**Сыйныф:** 3 сыйныф (57-59 дәресләр).

**Кейс.** *“Кешенең тышкы матурлыгын гына түгел, эчке матурлыгын да күрә белергә кирәк”*

1. Дәреслек: Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина. Күңелле татар теле: Дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3нче сыйныф рус балалары өчен татар теле һәм уку дәреслеге (ике кисәктә). – Казань: Татармульфильм, 2013. – 128 б.

2. Сүзлек: Татарча-русча сүзлек: 25 000 сүз / И.Г. Габдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Юнәлиева; Ф.Ә. Ганиев ред.– 5-нче басма.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 524 б.

3. Русча-татарча сүзлек: 47 000 чамасы сүз / Ә.М. Ахунҗанов, Р.С. Газизов, Ф.Ә. Ганиев һ.б.; Ф.Ә. Ганиев ред. – Төз. 4-нче басма. – М.: Инсан, 1997. – 720 б.

4. Әсәргә иллюстрацияләр.

5. Биремле карточка.

**Тема:**

Зыя Мансурның “Таңсылу” әкиятен өйрәнү.

**Сыйныф:** 7 сыйныф.

**Кейс.** *Әсәрнең төп темасын, проблемасын ачыкларга.*

1. Дәреслек: Татар әдәбияты: Рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 7 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) /Ф.М.Мусин, Ә.М.Закирҗанов, И.Г.Гыйләҗев, Р.С.Шәвәлиева. – Яңадан эшләнелгән 4 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2010. –199 б.

2. Биремле карточка.

1) геройларны билгеләргә, образлар системасын төзергә;

2) эш-гамәлләре аша характерды сыйфатларын ачыкларга;

3) цитаталар белән эшләү.

**Тема:** Дару үләннәре.

**Сыйныф:** 6 сыйныф.

**Кейс.** *Даша шәһәрдән әбисенә кунакка кайтты. Иптәш кызлары белән ул урманга барды. Кызлар төрле файдалы үләннәр җыя башладылар. Ә Даша үләннәрне танымый. Сез кызга ничек булышырсыз?*

1. Дару үләннәре төшерелгән рәсемнәр.

2. Дару үләннәр энциклопедиясе.

3. Текстлар “Шифалы үләннәр”, “Кура җиләге”.

4. Сүзлек: Татарча-русча сүзлек: 25 000 сүз / И.Г. Габдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Юнәлиева; Ф.Ә. Ганиев ред. – 5-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 524 б.

5. Русча-татарча сүзлек: 47 000 чамасы сүз / Ә.М. Ахунҗанов, Р.С. Газизов, Ф.Ә. Ганиев һ.б.; Ф.Ә. Ганиев ред. — Төз. 4-нче басма. — М.: Инсан, 1997. – 720 б.

6. Биремле карточка.

# II БҮЛЕК.

## ЭЛЕКТИВ КУРС ПРОГРАММАЛАРЫ

## 2.1. ӘДӘПЛЕЛЕК – МАТУР ГАДӘТ

**Аңлатма язуы**

Халыкның әхлакый тәртип кагыйдәләре, рухи мәдәнияты бик борынгы заманнарда барлыкка килгән.

Татар халкы элек-электән үзенең әдәп-әхлак нормаларын камилләштерә килгән. Кешеләрне рухи яктан сафландыручы күптөрле гореф-гадәтләр, йолалар буыннан-буынга күчеп, безнең көннәргә килеп җиткән. Шулай итеп, алмашка килгән һәр буын үзләштерергә тиешле яшәү кагыйдәләре, әдәп-әхлак идеаллары формалашкан. Тик татар халкына борынгыдан хас булган бу әдәп-әхлак сыйфатлары хәзерге яшьләрдә сизелерлек кимеде. Бүгенге яшьүсмерләр аралашу әдәбен белмиләр, низаглы хәлләрдә югалып калалар, үз бәхетләрен табарга, сакларга, күңелле итеп яшәргә өйрәтелмәгәннәр.

Хәзерге вакытта мәктәп алдында торган төп бурычларның берсе – укучыларда югары әхлак сыйфатлары, әдәплелек тәрбияләү, аралашу серләренә төшендерү.

Татар халкы югары тел культурасына ия булуны элек-электән үк кешенең иң күркәм рухи - әхлакый сыйфатларының берсе итеп санаган. Халыкта “Кеше күрке йөз булыр, йөзнең күрке күз булыр, телнең күрке сүз булыр” дигән мәкаль бар. Сүзне тиешле урында һәм вакытында белеп сөйләү – югары сөйләм культурасына ия булуның аеруча мөһим шарты. Кирәкле сүзне табып тиешле мәгънәсендә файдаланып, чит тел сүзләрен кулланмыйча үз фикереңне әйтә белү – үзара аралашуның да уңышлы чыганагы.

“Әдәплелек – матур гадәт” дип аталган бу махсус курс төп әдәп кагыйдәләрен үз эченә алган; ул укучының шәхес булып формалашуында профессиональ әзерлеген, иҗтимагый активлыгын үстерүдә, эшлекле аралашуга этәрүдә бер баскыч булып торыр.

Программаның төп бурычлары:

1. Укучыларда фәнгә карата кызыксыну, белемгә омтылыш тәрбияләү.

2. Фән буенча алган белемнәрне системага салу, тирәнәйтү.

3. Темаларны үзләштерү барышында сөйләм телен баету.

4. Укучыларда эстетик зәвыклылылык, дөньяга караш тәрбияләү.

5. Алган белемнәргә нигезләнеп, иҗади сәләтләрен үстерү; зыялы, мәдәниятле шәхес тәрбияләү.

**Тематик план**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Кереш. Гадәтнең дә була төрлесе. | 1 |
| 2. | Киенү әдәбе. | 4 |
| 3. | Табын әдәбе. | 4 |
| 4. | Иҗади эшләрне тәкъдим итү, яклау. | 3 |
| | | 12 |

## Программаның эчтәлеге

**I. Кереш. Гадәтнең дә була төрлесе (1сәгать).**

Гадәт төшенчәсен ачыклау.

Уңай һәм тискәре гадәтләр.

Тискәре гадәтләрдән арыну юллары.

Психолог киңәшләре.

*Практик эш*. Анкета тутыру.

**II. Киенү әдәбе (4 сәгать).**

Матурлык төшенчәсен ачыклау.

Эчке һәм тышкы матурлык. Матурлык һәм гадилек.

Зәвыклылык. Зәвыклы киенү серләре.

*Практик эш*. Иллюстрацияләр белән эшләү. Бирелгән ситуацияләр буенча фикер алышу. Тест.

Киенү стиле. Стиль төрләре.

Стильле киенү. Киенүдә үз стилеңне таба белү. “Киемеңә карап каршы алалар...”.

Милли киемнәр. Заманча киемнәрдә милли орнаментлар.

Хатын-кыз һәм ир-атлар фигурасының типологиясе (трапеция, турыпочмаклык, стандарт, “ком сәгате”, “сигезле”, өчпочмак).

Кием формасының аралашуга йогынтысы.

Төсләр җыелмасы. Төсләрнең үзара ярашуы.

“Ел фасыллары” төшенчәсен ачыклау. ( Немец педагогы, төсләр буенча галим Иоханнес Иттен теориясе. Ул кешеләрне 4 төркемгә бүлеп карый: “Яз”,“Җәй”,“Көз”,“Кыш”. Һәрбер ел фасылының үзенә генә хас төсләр җыелмасы бар. Яз – сары, ачык яшел, алсу төсләр. Җәй – зәңгәр (су һәм һава төсе), яшел-зәңгәр, кызыл. Көз – алтынсу, саргылт-көрән, ачык яшел, караңгы кызыл төсләр. Кыш – ап-ак, зәңгәрсу, кызыл, сары, алсу шәмәхә, караңгы зәңгәр, чия кызыл төсләр).

Киенүдә үз төсеңне таба белү.

*Практик эш*. Кием сайлауда бер-береңә киңәшләр бирү, бәяләү, мактау-комплиментлар әйтү.

“Мең дә бер киңәш “ рубрикасы.

(Йолдызлар киңәш итә...).

**III. Табын әдәбе (4 сәгать ).**

Кунакта үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.

Татар халкының борынгыдан килгән кунакчыллыгы һәм кунак итү йолалары.

Халкыбызның кунакка йөрешү йоласының элекке чорда иң отышлы үзенчәлеге. Кунак чакыру. Кунакка бару.

Кунакның да була төрлесе. Чакырылган, чакырылмаган кунак.

*Практик эш*. Төрле ситуацияләр буенча фикер алышу.

Кунак кабул итү кагыйдәләре.

Бәйрәм табыны әзерләү сәнгате.

Аш өстәле бизәү серләре.

Табын хәзерләгәндә савыт-саба һәм кирәк-яракларны дөрес урнаштыру.

Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.

Әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашу.

Әңгәмә кору осталыгы.

*Практик эш.* “Мин башкалар күңеленә хуш киләмме?” Тест.

Бәйрәм уздыру. Гаилә бәйрәмнәре.

Бәйрәмгә чакыруның төрле формалары.

*Практик эш.* Чакыру билетлары әзерләү. Бәйрәм табыны өчен меню төзү, сценарий язу.

**IV. Иҗади эшләрне яклау (3 сәгать ).**

Яклау өчен түбәндәге эш төрләре тәкъдим ителә:

1. Яшь үзенчәлекләреңне исәпкә алып, фигураңның тибын ачыклап, бәйрәм костюмы моделен ясарга.

2. Заманча киемнәрне милли орнаментлар белән зәвыклы итеп бизәргә.

3. Бәйрәм табыны өчен программа, меню төзергә.

4. Үзенчәлекле ризык рецептлары альбомын әзерләргә.

5. Үзегезнең гаилә традицияләре буенча үткәрелә торган бәйрәмгә сценарий язарга.

***Файдалану өчен әдәбият***


1. Безруких М.М. Я и другие, я или правила поведения для всех. – М.: Издательство политической литературы, 1991.
2. Гыймадиева Н. Дәрестә һәм дәрестән соң. – Казан: “Яңалиф” нәшрият йорты, 2004.
3. Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, педагогия колледжлары, училищелары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2003.
4. Курбатов Х. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан, 2002.
5. Көч һәм рух тамырлары. Әдәплелек дәресләре. Хрестоматия 5-11 сыйныфлар өчен. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
6. Макаренков С.М. Энциклопедия этикета. – Москва: “Рипол классик”, 2003.
7. Матвеев В. В мире вежливости. – Москва, 1991.
8. Сафиуллина Ф.С., Ибрагимов Г.Б. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел. – Казан: “Мәгариф”нәшрияты, 1998.
9. Сәүбәнова С. Бәйрәмнәр, туйлар өчен тамаша үрнәкләре. – Казан, 1999.
10. Ходаков М.С. Гадәтнең дә була төрлесе. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1976.

## 2. 2. НӘСЕЛ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ

**Аңлатма язуы**

Җирдәге бөтен тереклекнең башлангычы, чыганагы бар. Кеше өчен бу башлангыч – аның гаиләсе, туган җире. Кешенең туган йорты, туган җире, гаиләсе белән берлеге аңа дөньяда яшәү ныклыгы бирә. Бала гаиләнең гореф-гадәтен, ата-ана шөгылен, үз туган җирен, үз туган телен белми торып, үз Ватанының тугрылыклы вәкиле була алмый. Һәр бала үзенең ата-анасына, әбибабасына, якыннарына, туганнарына ихтирам-хөрмәтле булып үсәргә тиеш. Шуңа күрә һәрбер кеше кечкенәдән үзенең нәсел тарихын белергә, өйрәнергә бурычлы. Һәр баланың бүгеннән үк киләчәктә җәмгыятькә файдалы, хөрмәткә лаеклы кеше булып үсүенә бүгеннән нигез салына.

Татар халкы бик борынгы заманнардан ук нәсел-ыру тарихын язуга, ягъни шәҗәрәләр төзүгә зур әһәмият биргән. Нәсел тарихы булган шәҗәрәләр белән кызыксынуның татар халкында күп гасырлык тарихы бар. Урта гасырларда шәҗәрә милеккә, хакимияткә хокук документы булып саналган. Шәҗәрә якын кардәш-ыру арасында никах мөнәсәбәтләренә керүдән дә саклаган. Һәр мөселман үзенең җиде бабасына кадәрле буынны белеп торырга тиешлеге диндә дә искәртелә. Һәр буын үзеннән соң киләчәк буынга гаилә тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын тапшырып барырга бурычлы. Соңгы елларда гаилә тарихын өйрәнү белән кызыксыну сизелерлек җанланды.

“Нәсел тарихын өйрәнү” дип аталган бу курс буыннар арасындагы бәйләнешне барлау, нәселнең үткәнен, бүгенгесен өйрәнү масатын күздә тота.

Программаның төп бурычлары:

1. Укучыларда үз нәселеңнең килеп чыгышын өйрәнүгә, туган як, туган төбәк кешеләре белән якыннан танышуга кызыксыну уяту.

2. Эзләнү-тикшеренү эше белән шөгыльләнергә өйрәтү, мөстәкыйльлек, дөньяга дөрес караш тәрбияләү.

3. Генеалогия фәненә аңлатма бирү, укучыларны илебез генеалогия тарихыннан белешмәләр белән мәгълуматлы итү.

3. Шәҗәрә төзү буенча гамәли күнекмәләр бирү.

4. Туган телгә мәхәббәт, туганнарга, якыннарга карата ихтирам-хөрмәтле булу, үз халкың, үз нәселең белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Программа 15 сәгатьлек материалны үз эченә алган.

## Тематик план

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Кереш. Генеалогия фәне | 1 |
| 2. | Тарихи генеалогия. Илебез генеалогиясе тарихыннан | 2/2 |
| 3. | Туганлык дәрәҗәләре, туганлык терминнары Нәселне өйрәнүдә исем-фамилияләр | 2/2 |
| 4. | Шәҗәрә – нәсел-ыру тарихы | 4 |
| 5. | Иҗади эшләрне тәкъдим итү, яклау | 2 |

## Программаның эчтәлеге

I. Кереш. Генеалогия фәненә аңлатма (1сәгать).

Генеалогия фәне, аның башка фәннәр белән бәйләнеше.

II. Тарихи генелогия (4 сәгать).

Генеалогиянең барлыкка килүе.

Илебез генеалогиясе тарихыннан. Урта гасыр генеалогиясе. Беренче рус елъязмаларының әһәмияте.

Татар шәҗәрәләре тарихы. Хәлфин материалларына нигезләнеп бастырылган татар шәҗәрәсе. Ш.Мәрҗәни, К.Насыйри, Р.Фәхретдин язмалары.

Россиянең татарлардан чыккан атаклы нәселләре (Бахрушиннар, Юсуповлар).

*Практик эш*. Белешмә материаллар белән эшләү. Тест.

**III. Туганлык дәрәҗәләре, туганлык терминнары. Нәселне өйрәнүдә исем-фамилияләр (4 сәгать).**

Туганлык терминнары. Кан кардәшлек. Никах буенча туганлык.

*Практик эш*. Тест “Туганлык терминнары”.

Шәхси исемнәрнең үзенчәлекләре. Татар исемнәренең килеп чыгышы, төзелеше.

*Практик эш*. Гаилә архивын барлау.

Гаиләдәге ир-ат һәм хатын-кыз исемнәрен барлау, мәгънәләрен ачыклау. Фамилияләрнең этимологиясен аңлату.

**IV. Шәҗәрә – нәсел-ыру тарихы (4 сәгать).**

Гаилә архивы, аны тәртипкә китерү, документларны саклау тәртибе. Көндәлекләр, рәсемнәр, истәлекле әйберләр. Гаилә елъязмалары.

*Практик эш.* Гаилә архивының картотекасын төзү. Гаилә документларын саклау турындагы кагыйдәләрне язып алу. Гаилә альбомын өйрәнү.

Шәҗәрә сүзенә аңлатма бирү. Шәҗәрә үрнәкләрен карау. Шәҗәрә төзү кагыйдәләре.

*Практик эш.* Үз нәселеңнең шәҗәрәсен төзү, бизәү.

**V. Иҗади эшләрне яклау (3 сәгать ).**

Яклау өчен түбәндәге эш төрләре тәкъдим ителә:

1. Нәсел шәҗәрәсен төзү һәм яклау.

2. “Гаиләмдә – күренекле шәхесләр” дигән темага чыгыш әзерләү.

3. Күренекле шәхесләрнең шәҗәрәләрен төзү.

4.Гаилә архивыннан кызыклы материаллар белән таныштыру.

**Файдалану өчен әдәбият**


1. Биктимерова Т. Шәҗәрә төзи беләсезме? // Мәгариф. – 2009. – №1. – Б. 71–72 .
2. Введение в генеалогию (родоведение). Учеб. пособие для ст. кл.. общеобразоват. учреждений / авт.-сост. И.Ю. Протащук. – Казан: Хэтер, 2009. – 192 б.
3. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1981. – 256 б.

# III БҮЛЕК.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРДА УНИВЕРСАЛЬ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ

Яңа федераль дәүләт стандартларының мөһим юнәлеше – укучыларда универсаль уку гамәлләрен формалаштыру. Универсаль уку гамәлләренең нигезен Л.С. Выготский, Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдов, Д.И. Фельдштейн, Л.Кольберг, Э.Эриксон, Л.И.Божович, А.К.Маркова, Я.Д. Пономарёв, Д.Л. Венгер, Г.Д. Цукерман һәм башка педагогларның хезмәтләре тәшкил итә.

Укучыларның универсаль уку гамәлләрен формалаштыру программасы 4 блоктан тора (А.Г. Асмолов буенча).

*1. Шәхси (әхлакый) универсаль уку гамәлләре.* Шәхес буларак үзеңне формалаштыру, тормышка яраклашу, һөнәреңне дөрес сайлау. Җәмгыятьтә үз урыныңны табу. Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. Укуның кирәклеген аңлау. Гомумкешелек кыймматләренә уңай мөнәсәбәт формалаштыруга юнәлтелгән гамәлләрне үзләштерү.

*2. Регулятив универсаль уку гамәлләре.* Уку эшчәнлеген аңлап оештыру. Максат кую, планлаштыру, уку эшчәнлегендә эзлеклелек булдыру. Үз эшеңә контроль ясый, кирәкле урыннарда төзәтмәләр кертеп, бәя бирә белү.

*3. Танып белү универсаль уку гамәлләре.* Танып-белү максатын мөстәкыйль билгеләү, эзләнү методларын куллану (шул исәптән компьютер белән эшли торган интерактив методлар). Аңлап, телдән, язма сөйләм оештыру. Уку эшчәнлегенә нәтиҗә ясау, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзбәя куя белү. Проблемалар кую, иҗади һәм эзләнү характерындагы мәсьәләләрне мөстәкыйль чишү юлларын табу. Укуның төрләрен дөрес сайлау. Укылган текст буенча кирәкле мәгълүматны аерып ала белү, төрле тип текстларны аера белү. Укылган текстны кыскача, структурасын бозмыйча сөйләү. Вакытлы матбугат телен аңлау. Гомумиләштерү, чагыштыру, классификацияләү, анализлау. Төшенчәләр формалаштыру, дәлилләү.

*4. Коммуникатив универсаль уку гамәлләре.* Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра алу, тыңлый белү, эш-гамәлләрен контрольгә алу, төзәтүләр кертү, бәяләү. Сорау куя, җавап бирә белү. Аралашу кагыйдәләрен истә тотып, эзлекле, төгәл итеп, сөйли белү, әңгәмә оештыру. Укытучының сөйләмен тыңлау һәм аңлау. Үз фикереңне белдереп сөйләм төзү, әңгәмәдәшеңнең сөйләмен контрольгә алу, төзәтмәләр кертү, бәяләү. Үз фикереңне төгәл, аңлаешлы әйтү. Тел нормаларын саклап диалог, монолог төзи белү, өйрәнелгән материал буенча мәгълүмат бирә алу.

**Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру өчен биремнәр**

*Шәхси* универсаль уку гамәлләрен формалаштыру:

– дәресне йомгаклауда катнашу;

– иҗади биремле күнегүләр эшләү;

– проект эшләре башкару;

–музыка тыңлау һәм кичерешләрне аңлату;

– картина, рәсемнәр буенча күңелдән сөйләү;

– вакыйгаларга үзбәя бирү;

– уңышларны исәпкә алу көндәлеге булдыру һ.б.

*Танып-белү* универсаль уку гамәлләрен формалаштыру:

– картинада, рәсемнәрдә аермалыкларны табу;

– терәк схемалар төзү;

– төрле таблицалар белән эшләү;

– диаграммалар төзү;

– “Нәрсә артык?”, “Тәртипкә сал”, “Текст эзлеклелегендә урнаштыр”, “Чылбыр” тибындагы төрле уеннар үткәрү;

– сүзлекләр белән эшләү.

*Регулятив* универсаль уку гамәлләрен формалаштыру:

– хаталы сүзне табу;

– хаталарны төзәтеп язу;

– өстәмә чыганаклардан мәгълүмат эзләү;

– бер-береңне тикшерү;

– диспут;

– дәрестә материалны ятлау;

– контроль сорауларга җавап бирү.

*Коммуникатив* универсаль уку гамәлләрен формалаштыру өчен биремнәр:

– иптәшеңә сораулар төзү;
– иптәшеңнең эшенә бәяләмә язу;
– төркемнәрдә эш (кроссворд төзү);
– “Бу кем?” уены;
– диалог өчен сораулар төзү;
– хикәя төзү, рәсемнәрне, предметларны телдән сурәтләү.

## Яңа теманы аңлату дәресендә укучылар башкара торган универсаль уку гамәлләре

**1. Ориентлашу-мотивлаштыру этабы** (уку эшчәнлегенә әзерлек, уңай халәт тудыру).

Дәреснең бу этабында укучыны аңлы рәвештә уку эшчәнлегенә тарту максаты белән эш оештырыла.

1) максатны ачыклау (ТБ);

2) иптәшең һәм укытучы белән эшчәнлекне планлаштыру (К).

**2. Белемнәрне актуальләштерү этабы.**

Дәреснең бу этабында укучыны яңа белемнәр алуга әзерләү эше оештырыла, уку гамәлләре башкарыла, килеп туган каршылыклар билгеләнә, түбәндәге эшләр планлаштырыла:

1.Эш-гамәлләрнең өйрәнелгән төрләрен активлаштыру.

2.Фикерләү, танып-белү эшчәнлеген активлаштыру.

3. Эшләп карау, эш-гамәлләрдә үз-үзеңне сынау.

4.Уку гамәлләрен башкаруда барлыкка килгән каршылыкларны билгеләү: 1)анализ, синтез, чагыштыру, гомумиләштерү (ТБ):

2) укылган тексттан кирәле мәгълүматны аерып алу (ТБ);

3) сынап, тикшереп карау(ТБ);

4) төрле билгеләр, символлар куллану (ТБ);

5) аңлап сөйләм төзү (ТБ);

6) төшенчә чыгару (ТБ);

7) эшне башкарып карау (Р);

8) эш вакытында килеп чыккан кыенлыкларны билгеләү (Р);

9) эшне башкарып чыгу өчен үз-үзеңне әзерләү (Р);

10) фикереңне төгәл, ачык әйтеп бирү (К);

11) аралашуда үз фикереңне дәлилләү (К);

12) башкаларның фикерләрен дә исәпкә алу (К);

13) фикерләреңне дәлилләгәндә, төрле кагыйдәләрдән файдалану (К).

**3. Яңа материалны аңлату этабы.**

Бу этапта укучылар алда килеп туган каршылыкларның сәбәбен ачыклыйлар.

Укучылар дәреснең максатын билгелиләр, уку мәсьәләсен куялар, чишү юлларын, вакытын билгелиләр. Эш планын төзиләр. Эш барышы белән укытучы җитәкчелек итә. Укучыларга сораулар ярдәмендә булыша, ә аннан соң, эзләнү методлары ярдәмендә, эшчәнлек оештырыла:

1) анализ, синтез, чагыштыру, гомумиләштерү, үрнәк буенча эшләү (ТБ);

2) төшенчәләр чыгару (ТБ);

3) төп мәгълүматны билгеләү (ТБ);

4) проблемалы сорау кую (ТБ);

5) сөйләм төзү (ТБ);

6) үз фикереңне төгәл, тулы белдерү (К);

7) дәлилләү (К);

8) башкалар фикерен, бәяләвен исәпкә алып, үз сөйләмеңне төзәтү, коррекцияләү (К).

**4. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта укучылар биремнәрне парлап, төркемнәрдә башкаралар. Биремнәрне эшләү барышында укучылар чишелеш юлларын әйтеп баралар. Эшчәнлек түбәндәгечә оештырыла:

1) анализ, синтез, чагыштыру, гомумиләштерү, үрнәк буенча эшләү (ТБ);

2) тексттан кирәкле мәгълүматны алу (ТБ);

3) модельләштерү (ТБ);

4) төрле билгеләр, символлар куллану (ТБ);

5) төшенчәләр чыгару (ТБ);

6) гомуми ысул кулланып, күнегүләр эшләү (ТБ);

7) сөйләм төзү (ТБ);

8) үз фикереңне төгәл, тулы белдерү (К);

9) аралашуда тел чараларыннан урынлы файдалану(К);

10) аралашу вакытында үз фикереңне формалаштыру һәм дәлилләү(К);

11) әңгәмәдәшләреңнең фикерләрен тыңлап, уртак фикергә килү (К);

12) эшне җаваплы, аңлап башкару (Ш).

**5. Үрнәк буенча мөстәкыйль эш башкару этабы.**

Бу этапта эш индивидуаль формада оештырыла. Укучылар яңа тип биремнәрне мөстәкыйль эшлиләр, үрнәк буенча тикшерәләр, хаталарын төзәтәләр, кыенлык тудырган урыннарны билгелиләр:

1) анализ, синтез, чагыштыру, гомумиләштерү, үрнәк буенча эшләү (ТБ);

2) тексттан кирәкле мәгълүматны алу (ТБ);

3) моделъләштерү (ТБ);

4) төрле билгеләр, символлар куллану (ТБ);;

5) төшенчәләр чыгару (ТБ);

6) гомуми ысул кулланып, күнегүләр эшләү (ТБ);

7) сөйләм төзү (ТБ);

8) үз фикереңне төгәл, тулы белдерү (ТБ);

9) дәлилләү (ТБ);

10) тикшерү (Р);

11) төзәтү (Р);

12) үзбәя (Р).

**6. Өйрәнелгән материалны кабатлау этабы.**

Бу этапта укучылар яңа белемнәрне кулланып күнегүләр эшлиләр. Укытучы укучыларга яңа гамәлләр үзләштерү өчен кирәкле булган белемнәрне кабатлау күнегүләре бирә:

1) өйрәнеләсе материал эчтәлеген әхлакый яктан бәяләү (Ш);

2) анализ, синтез, чагыштыру, гомумиләштерү, үрнәк буенча эшләү (ТБ);

3) тексттан кирәкле мәгълүматны алу (ТБ);

4) модельләштерү (ТБ);

5) төрле билгеләр, символлар куллану (ТБ);

6) төшенчәләр чыгару (ТБ);

7) гомуми ысул кулланып, күнегүләр эшләү (ТБ);

8) сөйләм төзү (ТБ);
9) үз фикереңне төгәл, тулы белдерү (ТБ);
10) дәлилләү (ТБ);
11) тикшерү (Р);
12) төзәтү (Р);
13) үзбәя (Р).

**7. Рефлексия, бәяләү этабы.**

Бу этапта укучылар үз уку эшчәнлекләренә бәя бирәләр. Уку мәсьәләсе чишелешен тикшерәләр:

1) ысулларга, эш шартларына анализ (ТБ);
2) эш нәтиҗәләрен бәяләү (ТБ);
3) уңышка ирешү (ирешмәү) дәрәҗәсен аңлау (Ш);
4) билгеләнгән критерийлар буенча үзбәя (Ш);
5) үз фикереңне төгәл, тулы белдерү (ТБ);
6) дәлилләү (ТБ);
7) тикшерү (Р);
8) төзәтү (Р);
9) бәяләү (Р);
9) әхлакый нормаларны үтәү (Ш).

## Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру өчен уенлы биремнәр

*Шәхси (әхлакый) универсаль уку гамәлләрен формалаштыру*

Уку эшчәнлеген дөрес оештыру укучыларда белем алуга кызыксындыру уята. Укучыларга укуның мәгънәсен, кирәклеген аңлату мөһим. Укучылар тарафыннан уку эшчәнлегенә нәтиҗә ясау, аны бәяләү уку-укыту процессының мөһим шарты булып тора. Танып-белү эшчәнлегенә укучыларны мотивлаштыру – төп бурычларның берсе. Төрле характердагы уеннар куллану, укучыларны уку эшчәнлегенә тартырга ярдәм итә. Ләкин кайвакыт бу чараларның чамадан тыш булуы, кире нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Укытучы моны истә тотарга тиеш.

**“Үзанализ. Мин – кем? Мин – нинди?”**

*Максат*: укучының үз эшенә нәтиҗә ясый, бәяли алу дәрәҗәсен билгеләү.

“*Кәефең ничек?”* 6 төскә буялган кәгазь тартмалар куела. Һәр укучы үзенең төсен сайлый, сайланган тартмаларга үзләренең сигнал карточкаларын салалар. Укытучы нәтиҗә ясый, аннан соң нәтиҗәнең дөреслеген укучылардан кәефләрен сорашып белешә.

*“Миңа синең белән аралашу җиңел”.* Уенда катнашучылар түгәрәккә басалар, “Миңа синең белән аралашу җиңел”дип, бер-берсенә кулларын сузалар һәм йомык түгәрәк барлыкка китерәләр.

*“Мин – кем? Мин – нинди?”.* Укучылар сорауларга язмача җавап бирәләр, Мин үземне нинди дип уйлыйм? Башка укучылар мине нинди дип уйлыйлар? Минем нинди буласым килә? Һәр сорауга укучылар 5-10 сүз сайлап алалар (куллану өчен сүзләр бирелә).

*Ягымлы, көчсез, начар, сөйкемле, тупас, намуслы, мактанчык, эшчән, кызыксыз, үткен телле, тапкыр, көчле, саран, хәйләкәр, кызык, түземле, ышанычлы, уйчан, яхшы, сәламәт, әдәпле, тәрбияле, кыюсыз, акылсыз, ялгыз, матур, кискен, иркә, мөлаем, бәйләнчек, алдакчы, зиһенле, тиз аңлаучан.*

**“Чемодан”**

*Максат:* аралашу күнекмәләрен камилләштерү, укучының үзенә хас сыйфатларны аңлавы, классташларына карата ихтирам, игътибарлылык, тәрбияләү.

*Уен барышы:* Бер уенчы класстан чыга, иптәшләре аңа “чемодан” җыя башлыйлар. Алар бу укучының кешеләр белән аралашуга ярдәм итүче, аралашуга комачаулый торган сыйфатларын билгелиләр. Киңәшләшеп, 5-7 характерлы сыйфатны гына калдыралар. Укучы кергәч, язылганнарны аңа укып күрсәтәләр. Аңлашылмаса, бу укучы бер генә сорау бирә ала. Уенны бирелгән вакыт кысаларында, укучылар теләгәнчә, дәвам итәргә була. Уен ахырында үзе турында мәгълүмат алган укучыга сораулар бирелә:

1. Үзең турында нинди яңа мәгълүмат алдың?
2. Башкалар турында нәрсәләр белдең?
3. Син үзеңне кайсы яктан үзгәртер идең?
4. Ничек үзгәрергә телисең?

**“Уку эшчәнлегенә үзбәя”**

*Максат*: уку процессында үз эшчәнлегеңне бәяли белү, “яхшы укучы” ролен аңлау.

*Уен барышы:* Укучыларга ирекле рәвештә сорауларга җавап язарга тәкъдим ителә.

1. Син ничек уйлыйсың, кемне яхшы укучы дип атап була? Яхшы укучыга характерлы сыйфатларны әйт.

2. Син үзеңне яхшы укучы дип саныйсыңмы?

3. Әгәр дә алай уйламыйсың икән, ул вакытта, син яхшы укучыдан нәрсә белән аерыласың?

4. “Мин – яхшы укучы” дип әйтер өчен нинди булырга кирәк?

*Бәяләү критерийлары:* өлгереш, мәктәп тормышында катнашу, укытучы һәм классташларың белән уңай мөнәсәбәттә булу, уку белән кызыксыну.

**“Минем эчке дөньям”**

*Максат:* укучыларның үз ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, уйларын аңлый, бәяли белү.

*Уен барышы:* Укучыларга альбом битенә түгәрәкләр ясарга кушыла – берсе уртага, аның янына сигез түгәрәк. Беренче түгәрәк башкалары белән тоташтырыла. Уртадагы түгәрәккә “Мин” сүзе языла, ә калганнарына бирелгән җөмләләрнең ахыры языла.

1. Минем яраткан шөгылем...
2. Минем якын дустым...
3. Минем яраткан йорт хайваны...
4. Минем яраткан ел фасылы...
5. Минем яраткан әдәби герой..
6. Минем яраткан музыкаль әсәр...
7. Минем яраткан фильм...
8. Мин яраткан төс...

Укучылар үзләренең җавапларын чагыштыралар, фикер алышалар.

*Коммуникатив универсаль уку гамәлләрен формалаштыру*

Укучыларның аралаша белү осталыгын үстерү бик мөһим мәсьәлә. Коммуникатив эшчәнлек ул ике яки берничә кешенең

нинди дә булса эшне башкару өчен аралашулары. Уңышлы аралашуның төп шарты – әңгәмәдәшең белән киңәшләшеп, эшне оештыру. Укучыларда аралашу күнекмәләре формалаштыру дәвамлы эш, күп вакыт таләп итә.

**“Дискуссия”**

*Максат.* Дискуссия оештыруның кагыйдәләрен үзләштерү, күнекмәләр булдыру.

*Уен барышы:* Укытучы җитәкчелегендә *бәхәс* һәм *дискуссия* терминнарына аңлатма бирелә. Алар арасында аерма барлыгы ачыклана. Бәхәс вакытында төп максат – үзеңнең хаклы икәнеңне дәлилләү, ул конкрет вакыйгага нигезләнә. Дискуссия – ул яңа мәгълүматларга нигезләнеп, үзгәреп тора торган процесс, зур проблемалар турында сүз алып барыла.

Укучылар төп кагыйдәләр белән танышалар. Алар 10-12 кешелек төркемнәргә бүленәләр. Һәр төркем икегә бүленә. Фикер алышу өчен тема сайлана. Әңгәмә вакытында катнашучылар ниндидер уртак фикергә килергә тиешләр.

Темалар: “Яшәү кайда яхшырак: чит илдәме, безнең илдәме?” “Әти-әниләр безне дөрес тәрбиялиме, без үз балаларыбызны ничек тәрбияләрбез? “Тормыш кайчан җиңел булган?” “Телеведение безне нәрсәгә өйрәтә? Яхшыгамы? Ямангамы?”

Дискуссияне дөрес оештыру – үзе бер осталык. Әңгәмә кызыклы булсын өчен, кайбер кагыйдәләрне үтәү бик мөһим.

1. Дискуссиянең төп максаты – дөреслекне табу. Сөйләшү вакытында темадан читкә китмичә, төп мәсьәлә буенча гына әңгәмә алып барылырга тиеш. Җиңү яуларга түгел, дөреслеккә омтылырга кирәк.

2. Башкалар фикеренә игътибарлы булырга кирәк. Һәр кешенең үз фикере була. Дөреслек ахырда гына беленергә дә мөмкин.

3. Һәр әйтелгән фикер дәлилләнеп барырга тиеш. “Мин шулай уйлыйм”, “һәрвакыт шулай була иде” кебек сүзләр әле дәлилләү түгел.

4. Әңгәмә вакытында дусларча мөнәсәбәт булырга тиеш.

5. Дискуссия бәхәскә әйләнергә тиеш түгел, моны истә тотарга кирәк.

6. Дискуссиядә башка кеше фикерен аңлый, ихтирам итә белә торган кешеләр генә катнашырга тиеш.

7. Нәрсәгәдер ышанмаган кешене ышандырырга тырышып, вакытны сарыф итәргә кирәк түгел. Ул кешенең характерына бәйле. Кеше характерны әңгәмә вакытында гына үзгәртеп булмый.

**“Компьютер презентациясе”**

*Максат*: Нинди дә булса темага информация тәкъдим итү өчен бергәләп эшләү вакытында аралашу осталыгын камилләштерү.

*Эш барышы:* Төркемдәге укучыларга билгеле бер тема буенча компьютер презентацияләре ясарга тәкъдим ителә. Укучылар киңәшләшеп план төзиләр, слайдларның эзлеклелеген билгелиләр. Парлашып, слайд өчен текст, рәсемнәр әзерлиләр. Эш башка төркемнәргә күрсәтелә һәм бәяләнә.

*Бәяләү критерийлары:*

1) бергә эшләүнең нәтиҗәсе;

2) текст эчтәлегенең аңлаешлы булуы;

3) эш барышындабер-береңне тикшерү һәм ярдәм итү;

4) кызыксынып эшләү; кирәк вакытта гына бер-берең белән аралашу; бер-берең белән килешә алмау.

*Танып-белү универсаль уку гамәлләрен формалаштыру*

Укуга эшчәнлегенә мотивлаштыру, ихтыяҗ тудыру, кызыксындыру максатыннан укучыларны фәнни эшчәнлеккә, проектлар төзү эшенә җәлеп итү зур әһәмияткә ия.

1. Фәнни-эзләнү, проект эшләре укучыларның фән буенча белемнәрен генә үстереп калмый, ә эшчәнлек нәтиҗәсе булып, башкалар өчен дә әһәмиятле булган хезмәт барлыкка килә.

2. Бу эш укучылар үзләре теләгән укытучы белән, үзләре теләгән укучылар белән аралаша алырлык итеп оештырылырга тиеш. Төрле кешеләр белән аралашып, укучы мөстәкыйль эшләү, коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен камилләштерә.

3. Фәнни-эзләнү, проект эшләре укучыны кызыксындыруга яңа мөмкинлекләр ача: фән буенча тирәнтен белем алырга, иҗади эшчәнлекне үстерүгә ярдәм итә.

Тикшеренү эшчәнлеге уңышлы барсын өчен, укучы түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш:

*Проблема кую, проблемалы ситуация тудыру, теманың актуальлеген аңлату.*

1) проблеманы күрә белү (проблеманы чишүгә караганда аны таный алу тикшеренү эшчәнлегендә еш кына авырлыклар китереп чыгара).

2) сорау куя белү (уку текстлары бу күнекмәне кечкенә сыйныфлардан ук формалаштырырга мөмкинлек бирә, укучылар гади текстларны анализлап, проблемалы сораулар бирергә өйрәнәләр);

3) гипотезаларны аерып күрсәтү (проблемаларны чишү өчен вариантлар тәкъдим итү);

4) текстны өлешләргә бүлү (текст белән эшли белү күнекмәләре: текстның төп өлешен аерып ала белү, төп идеясен, вакыйгаларны эзлекле тәртиптә урнаштыру);

5) төрле сурәтләү чаралары белән эшли белү (сүзләр, тәгъбирләрнең күчерелмә мәгънәсен аңлау);

6)төшенчәләргә аңлатма бирә алу.

*Гипотезаны тәкъдим итү, формалаштыру, тикшеренү эшенең төп максатын билгеләү.*

Гипотезаны формалаштыру өчен алынган мәгълүматны анализларга кирәк.

*Тикшеренү (проект) эшләрен планлаштыру.*

Теоретик, эмпирик тикшерү ысуллары куланылырга мөмкин: материал туплау, анализлау, фикер алышу өчен сораулар h.б.

*Проблеманы чишү юлы,эзләнү-тикшеренү (проект эше), анализлау.*

Проблеманы чишү юлларын эзләү, эзләнү-тикшеренү эшен башкару түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) күзәтү;

2) эксперимент үткәрү;

3) нәтиҗәләр ясау;

4) күзәтүне оештыру, планлаштыру, кайбер мәгълүматларны, гипотезаларны тикшерү;

5) төрле чыганаклардан файдалану;

6)алынган нәтиҗәләр буенча фикер алышу, аларны башка ситуацияләрдә куллану.

*Тикшеренү нәтиҗәләрен тәкүдим итү, эшнең төзелешен саклап формалаштыру, яклау.*

Тикшеренү эшнең нәтиҗәсен формалаштырып тәкъдим итү түбәндәгеләрне эченә ала:

1) материалны формалаштыру;

2) фикер алышу, аңлату, дәлилләү, яклау;

3) нәтиҗәләрне бәяләү.

**“Яраткан тапшырулар”**

*Максат:* яраткан телевизион тапшыруларны өйрәнү аша тикшеренү күнекмәләре булдыру.

*Эш барышы:* укучыларга үзләре яраткан телевезион тапшыруларын тикшерү эше йөкләнә. Аннан соң әзерлек этабы үткәрелә. Бу этапта түбәндәге план буенча фикер алышу үткәрелә.

1) һәр укучыга эш бүлеп бирү (мәгълүмат җыючы, сорауларга җавап бирүче, җыелган материалны эшкәртүче һ.б);

2) телевидение тапшыруларының бүгенге көн таләпләренә туры килгәнен сайлап алу;

3) сорауларны тәкъдим итү формаларын билгеләү;

4) тикшеренүнең башка этапларын планлаштыру;

5) эшне башкару, нәтиҗәләр чыгару.

**“Сорау бирергә өйрәнәбез”**

*Максат:* Әдәби әсәрләргә сораулар төзи белү күнекмәләрен формалаштыру.

*Эш барышы:* Укучыларга текстны укырга һәм схемалардан файдаланып, төрле сораулар төзү биреме бирелә.

Сораулар:

1. *Кем? Нишләгән? Бу кайда булган? Кайчан? Ничек?*

2. Вакыйгаларга төгәллек кертү : *Мин дөрес аңлаган булсам, ....?*

3. Вакыйгаларның сәбәпләрен ачыклау: *Ни өчен? Нигә? Шуннан соң нәрсә булган?*

4. Вакыйгаларны үзгәртү мөмкинлекләрен ачыклау: *Әгәр дә...... вакыйгалар ничек үзгәрер иде?*

5. Әдәби геройларның хис-кичерешләрен ачыклау: *Нинди*

*хисләр кичерәсез?*

6. Аларның эш-гамәлләрен, вакыйгаларны бәяләү: *Ул дөрес эшләгәнме? Ни өчен? Бу герой икенче геройдан нинди сыйфатлары белән аерыла?*

7. Укучының әдәби геройларга, вакыйгаларга мөнәсәбәтен ачыклау: *Сезгә бу геройның кайсы яклары ошады? Нинди сыйфатлары ошамады?*

8. Укучының үзен әдәби геройлар роленә куеп каравы: *Бу очракта сез нишләр идегез?*

*Бәяләү критерийлары:*

Укучыларның тулы текстны күз алдына китерерлек итеп сораулар төзи белүләре.

*Регулятив универсаль уку гамәлләрен формалаштыру*

Укучыларны мөстәкыйль тормышка әзерләү бурычы аларның регулятив уку гамәлләрен формалаштыру мәсьәләсен алга куя: укучыларның үзләре алдына максат куеп, шуның ирешү юлларын билгели алулары; вакытларын бушка сарыф итмәүләре; төрле мәсьәләләрне хәл итүләре; үзләренең эшчәнлекләрен бәяли алулары һ.б.

**“Уку эшчәнлеген планлаштыру”**

*Максат:* укучының уку эшчәнлеген планлаштыра алу күнекмәләрен формалаштыру, докладка әзерләнүнең хронокартасын төзү.

*Эш барышы:* докладка әзерләнүнең хронокартасын төзү, вакытның дөрес бүленешен билгеләү. Укучыларга 10 минутлык кечкенә доклад әзерләргә кушыла, вакыты – 60 минут.

*Эш төрләре:* теманы һәм максатны билгеләү, тема буенча әдәбият уку, эчтәлегенә материал сайлау, тезислар язу, ял итү, тикшерү.

Планлаштырганнан соң укучылар эшкә тотыналар һәм күпме выкыт сарыф иткәннәрен язып баралар. Шуннан соң план белән чагыштыралар һәм сорауларга җавап бирәләр:

1) аерма бармы?

2) әгәрдә булса, нинди аерма?

3) кайсы эш өчен вакытны азрак (күбрәк) бүлдегез?

4) яңадан ничек итеп төзер идегез?

**“Вакытны дөрес бүлү”**

*Максат:* укучының үз эшчәнлеген планлаштыра алу күнекмәләрен формалаштыру, мөстәкыйль эшчәлегенең хронокартасын төзү.

*Эш барышы:* укучыларга үзләренең вакытларын ничек бүлүләрен картага төшерергә, вакытның дөрес сарыф ителүенбилгеләргә кирәклеге әйтелә. Укучылар таблица формасында бирелгән хронокартаны тутыралар, соңыннан сорауларга җавап бирәләр:

1. Нәрсәгә күбрәк вакыт сарыф ителде?

2. Нәрсәгә вакыт җитмәде?

3. Вакытны күп алган эш сезнең өчен мөһим эшме?

4. Нинди төр шөгыльләргә сез вакыт бүленешен киметер идегез?

Укучылар кызыл карандаш белән яңадан выкытны бүлеп чыгалар. Укытучы укучыларга икенче көнне карта буенча эш тәртибен алып барырга, планлаштырылган вакыт бүленеше янына фактта күпме булганын язып барырга куша.

5. Төзелгән карта буенча эшне оештыра алдыгызмы? Көнегезне уңышлы үтте дип уйлыйсызмы? Ни өчен? Нәрсә комачаулады? Планлаштыруны башка көннәрдә дә дәвам итәрсезме? Ни өчен? Нәрсә үзгәртергә телисез?

Шул рәвешле укучыларны атналык эшне, уку эшчәнлеген планлаштырырга һәм нәтиҗәсен күзәтергә өйрәтергә мөмкин.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Әсәдуллин А.Ш. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре / А.Ш. Әсәдуллин, Р.А. Юсупов. – Казан: Мәгариф, 1998. – 151 б.

2. Әхмәдуллин А.Г. Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты) Унбереллык урта мәктәпнең 10 сыйныфы өчен дәреслек /А.Г. Әхмәдуллин, М.Х. Хәсәнов, Ф.Г. Галимуллин, И.З. Нуруллин; А.Г. Әхмәдуллин редакциясендә. – Казан: Мәгариф, 1994. – 367 б.

3. Анализ урока: типология, методики, диагностика / авт.-сост. Л.В.Голубева, Т.А. Чегодаева. – Волгоград: Учитель, 2007. – 121с.

4. Безрукова В.С. Всё о современном уроке: проблемы и решения. – М.: Сентябрь, 2004. – 160 с.

5. Вәгыйзов С.Г. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы / С.Г.Вәгыйзов, Р.Г. Вәлитова. – Казан: Мәгариф, 1993. – 415 б.

6. Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиева, Г.Ф.Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 455б.

7.Гайфуллин В. Педагогик технологияләр // Мәгариф, 2000. – № 4. – Б. 7-10.

8. Ганиева Ф.Ә. Әдәбият: Татар урта гомуми белем мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек хрестоматия / Ф.Ә. Ганиева, И.Г.Гыйлаҗев, Ф.Ф.Исламов. – Казан: Мәгариф, 2000.

9. Габдуллин Г.Г. Педагогик сүзлек / Г.Г.Габдуллин, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: КДПУ, 1997. – 190 б.

10.Еники Ә. Хәтердәге төеннәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 139 б.

11. Закирҗанов Ә.М. Рус мәктәбендә татар балаларына әдәбият укыту: 11 сыйныф: Укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2001. –112 б.

12. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият укытуның кайбер мәсьәләләре // Мәгариф. – 2001. – № 5. – Б.14-16.

13. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335б.

14. Исмәгыйлева С.Г. IX класста әдәбият дәресләре: Әдәбият укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 151 б.

15. Исмәгыйлева С.Г. Рус мәктәпләрендә белем алучы татар балаларына ана телен һәм әдәбиятын укыту: Укытучы өчен кулланма. – Ка-

зан: Мәгариф, 1993. – 120 б.
16. Казыйханов В. Әхлак дәресләрен ничек үткәрергә // Мәгариф, 2000. – № 11. – Б. 85-87.
17. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга: АИ КФУ нәшрияты, 2012. – 136 б.
18. Каюмова Г.Ф. Татар теле һәм әдәбиятын укыту тәҗрибәсеннән.– Казан: Яңалиф, 2003. – 104 б.
19. Колеченко А.К. Энциклопедия педагогических технологий: пособие для преподавателей. СПб.: КАРО, 2001.
20. Костомаров В.Г. Методика преподавания русского языка как иностранного/ В.Г. Костомаров, О.Д. Митрофанова.– М.: Рус.яз., 1990.– 158 с.
21. Лернер И.Я. Дидактические основы методов обучения. –М.: Педагогика, 1981. – 186 с.
22. Миңнуллин Р. Күчтәнәч: Балалар өчен шигырьләр. – Казан: Мәгариф, 1995. – 159 б.
23. Миңнуллин Р. Талбишек: Сайланма лирика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 159б.
24. Миңнуллин Р. Алма бабай: Балалар өчен шигырьләр, экиятләр. – Казан: Мәгариф, 1997. – 143 б.
25. Пассов Е.И. Коммуникативный метод обучения иноязычному говорению: Пособие для учителей иностранных языков. – М.: Просвещение, 1985. – 208 с.
26. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары. 1-11 сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2003. – 126 б.
27. Сәмигуллин Г.Х. Укчыларның проект эше белән идарә итү // Мәгариф, 2004. – № 12. – Б. 2-13.
29. Сафин Ф.М. Саташып аткан таң: Роман-трилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 527 б.
30. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Күнегүләр һәм кызыклы материаллар җыентыгы.. – Казан: Татар кит. нәшр., 1992. – 320 б.
31. Современный урок. Часть 1: Научно-практич. Пособие для учителей, методистов, руководителей образовательных учреждений, студентов пед. учеб. заведений, слушателей ИПК. – Ростов-на Дону: Изд-во «Учитель», 2005. – 288с.
32. Селевко Г.К. Опыт системного анализа современных педагогических систем // Школьные технологии. – 1996. – № 3. – С. 72-78.
33. Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 сыйныфлары өчен / Төзүчеләре Ф. Хатипов, А. Әхмәдуллин. – Казан:

Мәгариф, 2005

34. Урманче Ф.И. Роберт Миңнуллин: Шигъри осталык серләре. – Казан: Мәгариф, 2005. – 335 б.

35. Фәтхуллова К. С. Тел аралашу чарасы булсын // Мәгариф, 2009. – № 10. – Б. 21-23.

36. Формирование универсальных учебных действий в основной школе: от действия к мысли. Система заданий: пособие для учителя / [А.Г. Асмолов, Г.В. Бурменская, И.А. Володарская и др.] под ред. А.Г. Асмолова. – 2-е изд. – М.: Просвещение, 2011. – 159 с.

37. Хайдарова Р.З. Научно-педагогические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан. – Набережные Челны, 2006. – 200 с.

38. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

39. Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр / Ф.Харисов, Ч.Харисова // Мәгариф. – Казан, 2002. – № 8. – Б.33-36.

40. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Гомуми педагогика: педагогик уку йортлары, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 1999. – 504 б.

41. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. – 351 б.

42. Чошанов М.А. Гибкая технология проблемно-модульного обучения. – М.: Народное образование, 1996. – 238 с.

43. Яхин А.Г. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1995.– 335б.

44. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

**ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫН ТОРМЫШКА АШЫРУДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫНА ФӘННИ-МЕТОДИК ЯРДӘМ**

Форм.бум. 60x84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times New Roman.
Усл.печ.л. 6,9
Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com